Самарские татары
Самар татарлары
ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР
№ 2 (39), АПРЕЛЬ–ИЮНЬ, 2023
ВЫПУСКАЕТСЯ С 2012 ГОДА



БУДЕМ И ВПРЕДЬ СЛЕДОВАТЬ ВЕРЕ ПРЕДКОВ



«МАКСАТЫМ – ИХЛАСТАН ТУГАН ҖИРЕМӘ ХЕЗМӘТ ИТҮ»

#ҺӘР БАЛА ҮЗ РИЗЫГЫ БЕЛӘН ТУА



# ВАША РЕКЛАМА
# В ТАТАРСКИХ СМИ РЕГИОНА

По вопросам размещения обращаться по телефону 8-917-104-44-45

информационный медиапортал

Самарские татары

Самар татарлары

**samtatnews.ru**

Самарские татарские новости

**Ждем ваших предложений по созданию самарского татарского интернет-телевидения.**



## ЕЖЕКВАРТАЛЬНЫЙ ЖУРНАЛ О ЖИЗНИ САМАРСКИХ ТАТАР

**ПРИОБРЕСТИ НОМЕРА ЖУРНАЛА «САМАР ТАТАРЛАРЫ» МОЖНО ПО СЛЕДУЮЩИМ АДРЕСАМ:**
Самара, ул. Революционная, д. 142
(магазин «Кулинария на Революционной»),
пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),
в Соборной мечети Самары.

Телефон для связи 8-917-104-44-45 **Сайфиев Данияр Ирекович**

Адреса электронной почты – **Samartatarlary@bk.ru, ilyas65@mail.ru**



Самара өлкәсе татарларының
иҗтимагый-сәяси газетасына — 33 яшь!

Заманалар үзгәрә –
**Бердәмлек**
газетасы кала

- 33 ел буе газета өйләрегезгә котлаулар, мәкаләләр, очерклар, яңалыклар китереп тора
- "Бердәмлек"геройлары – сез үзегез, күршеләрегез һәм якташларыгыз!
- "Бердәмлек"не язучылар – сез үзегез, күршеләрегез һәм якташларыгыз!
- "Бердәмлек"– Самара татарлары арасында иң популяр газета!
- "Бердәмлек"кә ел әйләнәсендә почта бүлекләре, "Россия почтасы" сайтындагы онлайн-язылу һәм "Урал-пресс Поволжья" җәмгыяте аша язылырга була

Индексы П4778




## ЕЖЕГОДНЫЙ ТАТАРСКИЙ КАЛЕНДАРЬ

рассказывает о значимых исторических датах в жизни татар Самары и России

# Хөрмәтле дуслар!

Менә ямьле җәйләрне һәм шуның белән бергә “Самар татарлары” журналының икенче санын көтеп алдык.

Биредә күп милләтле регионыбызда апрель аеннан алып узган мөһим вакыйгалар турындагы язмалар урын алды. Бу – Ураза бәйрәме, “Мирас” фестивале һәм башкалар. Әлбәттә, медицина хезмәткәрләренең һөнәри бәйрәмнәре турында да онытмадык һәм алар турында берничә мәкалә әзерләдек.

Басмабызда чыккан язмалар сезне милли мәдәниятебезне, татар телебезне, гореф-гадәтләребезне кадерләп сакларга кирәклеге турында уйланырга мәҗбүр итәр, дип ышанабыз. Чөнки, кызганычка, милләтебезне саклап калу мәсьәләсе актуальләнә генә бара. Сез балаларыгыз, оныкларыгыз белән нинди телдә аралашасыз? Киләчәк буын вәкилләре ана телендә сөйләшерләрме? Татар җырларын җырлармы? Татар шигырьләрен сөйләрләрме? Боларның барысы да һәрберебездән тора. Халкыбызның якты киләчәгенә үз өлешебезне кертүче кешеләрдән булыйк. Үрнәк буларак, журнал битләрендә нәкъ шундый шәхесләр – җәмәгать һәм фән эшлеклеләре, авыл хезмәтчәннәре, сәләтле, иҗади яшьләребез һәм күп балалы татар гаиләләре турындагы мәкаләләрне урнаштырдык.

“Самар татарлары”н укыгыз, безнең белән бергә булыгыз. Ә без киләчәктә дә сез – укучыларыбыз өчен кызыклы һәм файдалы язмалар әзерләргә вәгъдә итеп калабыз.



**Данияр СӘЙФИЕВ,**
*“Самар татарлары” журналы мөхәррире*

# Дорогие друзья!

Вот мы и дождались лета, а вместе с ним и выхода второго в этом году журнала «Самар татарлары». Этот номер включил в себя наиболее яркие события, которые, начиная с апреля, проходили в нашем многонациональном регионе. Это и празднование Ураза-байрама, и красочный татарский фестиваль «Мирас», и многое, многое другое. Не забыли мы и о профессиональном празднике наших медиков, которым посвятили часть наших публикаций.

Как и публикации в предыдущих номерах, цикл статей, надеюсь, заставит вас задуматься о необходимости бережного отношения к национальной культуре, татарскому языку, нашим традициям. Ведь вопрос сохранения нации, к сожалению, с каждым разом становится всё актуальнее и актуальнее. Задумайтесь, на каком языке вы разговариваете со своими детьми, внуками, и получите подтверждение непраздности этой темы. Будут ли наши последующие поколения говорить на родном языке, петь наши народные песни, читать татарские стихи – зависит от каждого из нас. Давайте не будем об этом забывать и делать всё возможное для сохранения нашего народа. Как это делают герои статей этого номера – яркие общественные и научные деятели, многодетные татарские семьи, труженики села, талантливая и творческая молодежь. Познакомьтесь с ними.

Читайте журнал, оставайтесь с нами. А мы, в свою очередь, обещаем, что и впредь будем стараться делать его таким же интересным и полезным.


РЕДАКЦИОННЫЙ СОВЕТ

**Шакуров Ильяс Гумерович –**
президент СОТО «Туган тел»; председатель правления НКО «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», член Общественной палаты г.о. Самара

**Хазиев Артур Ахатович –**
председатель Центра Стратегических Исследований «Платформа XXI»

**Сайфиев Данияр Ирекович –**
гл. редактор журнала «Самар татарлары» («Самарские татары»)

**Нуретдинова Римма Равильевна –**
главный редактор сайта samtatnews.ru

**Вакказов Расих Ахметшамилович**
имам-хатыб мечети «Булгарское наследие»

**Ибятова Ляйсян Замиловна –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Надиров Азат Камилович –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Сафин Иршат Халилович –**
старший имам-хатыб Соборной мечети г. Самары

**Хузин Ривгат Туктарович –**
председатель комиссии Общественного совета при ГУ МВД России по Самарской области

**Мифтахов Искандер Фуадович –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Рамазанова Гюзяль Ибрагимовна –**
директор СОТО «Туган тел»

**Юсупов Рамиль Закрияевич –**
член Совета СОТО «Туган тел»

**Юсупов Фагим Ханифович –**
член Совета СОТО «Туган тел»

РЕДАКЦИОННАЯ КОЛЛЕГИЯ

**Биктаев Наиль Данисович**
**Варфоломеева Эльмира Мугаммаровна**
**Галимов Шамиль Хайдарович**
**Мифтахов Искандер Фуадович**
**Файзуллов Рустам Ильясович**
**Салахова Лилия Акрямовна**
**Ширияздинов Фарид Хамитович**
**Шарипов Руслан Кабирович**

# Содержание:


Мусульмане Самары отметили Ураза-байрам ........ 5
Ифтары единства ........ 6
Будем и впредь следовать вере предков ........ 9
“Туган якларымны сагынам” ........ 11
Милли җанлы җитештерүче ........ 14
Хатын-кыз – ул милләт анасы ........ 22
“Максатым – ихластан туган җиремә хезмәт итү” ........ 23
Ул авылга гашыйк ........ 25
Сәүдә эше үҗәтлек, уңганлык һәм тәвәкәллек таләп итә ........ 27
Ибраһим Нуруллинга – 100 яшь ........ 30
Иске Ярмәк авылы мәктәбе – чемпионнар әзерләүче укыту-тәрбия үзәге ........ 34
Самарцы в Золотой книге Почета Ульяновской области ........ 39
Один из дюжины отважных бойцов ........ 61
Китә кеше – кала эше ........ 72
Этнический анклав – путь к спасению или дорога в никуда? ........ 79
Һәр бала үз ризыгы белән туа ........ 81
“Бәхетле гаиләнең нигезендә сабырлык ята” ........ 84
Главная ценность – семья ........ 87
Ак чәчәкләр ........ 89
“Киләчәктә бик яхшы белгеч булырга хыялланам!” ........ 94
Күргәзмә онытылмаслык вакыйга булып хәтердә калды ........ 100
Россия – родина сионизма ........ 103
Аллаһы, кабул итеп, ярдәм бирсен чын мөселман безгә булырга! ........ 105
“Мирас” Самарның мәдәни тормышында якты вакыйгаларның берсенә әверелде ........ 108
Гомер таулары биек ........ 114
Путешествие этнонимов ........ 116
Нәҗиб Сәйфетдинов: “Ялкынлы яшьлек” ансамбле – милли мәдәниятебез җәүһәре” ........ 118
«Парк дружбы народов» принимает гостей из СГЭУ ........ 121






7 ПРАЗДНИК ДЛЯ ДЕТЕЙ И ИХ РОДИТЕЛЕЙ





12 ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ БУЛСЫН!





52 ПРИШЛО ВРЕМЯ СЛУЖИТЬ НАЦИИ





110 МИДХӘТ ӘМИНОВ: «АЛАР БЕЛӘН МИН УТКА ДА, СУГА ДА КЕРЕРГӘ ӘЗЕР»



## Уважаемые друзья!

***Приобрести журнал «Самар татарлары» можно по следующим адресам:***

- **Самара, ул. Революционная, д. 142 (магазин «Кулинария на Революционной»)**
- **Самара, пр. Кирова, 206 (бывшее здание «ИПОЗЕМбанк»),**
- **Самара, ул. Стара Загора, 54 (в магазине внутри Соборной мечети).**

**Стоимость текущего номера с доставкой – 300 рублей, стоимость номеров за 2022 год – 300 рублей, все предыдущие номера – по 700 рублей.**

**Доставка журналов по Самаре – тел.: 8-937-64-044-77.**



Издатель «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области», адрес: 443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28

**Главный редактор:** САЙФИЕВ Данияр Ирекович
**Корреспонденты:** Миляуша ГАЗИМОВА, Фарид ШИРИЯЗДАНОВ, Шамиль ГАЛИМОВ, Рашид ШАКИРОВ, Нурсина ХАКИМОВА
**Дизайн-макет, верстка:** Александр ГОРБАЧЕВ, Юрий ШВЕЦ
**Фото:** Миляуша ГАЗИМОВА, Аняс МИНГАЛЕЕВ
**Корректоры:** Миляуша ГАЗИМОВА, Вадим ОЛЕНИН

**Адрес редакции:**
443087, Самарская область, г. Самара, пр. Кирова, 206, оф. 28
**Телефон редакции:** 8-917-104-44-45
**Электронная почта:** samartatarlary@bk.ru
**www.samtatnews.ru**

**Отпечатано в ООО «СЛОВО»,**
443070, Самарская область, г. Самара, ул. Песчаная, 1, офис 310, тел. (846) 267-36-82

**Журнал «Самар татарлары»** («Самарские татары»), № 2 (39), апрель–июнь, 2023 г.
**Учредитель:** «Ассоциация содействия татарским предпринимателям Самарской области»
Журнал зарегистрирован Управлением Федеральной службы по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций по Самарской области. Свидетельство о регистрации СМИ: ПИ №ТУ63 – 00628 от 15.10.2013 г.
Дата выхода 28 июня 2023 г.
Тираж 1000 экз. Цена свободная



# В СЕТИ ПОЯВИЛСЯ БЕСПЛАТНЫЙ ТЕСТ, ОЦЕНИВАЮЩИЙ СЛОВАРНЫЙ ЗАПАС ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА

Основатель агентства «Теория», web-дизайнер Ильдар Аюпов, создал новый проект, направленный на популяризацию татарского языка, «Сүз байлыгы».

***business-gazeta.ru***

«Сүз байлыгы» – это бесплатный для пользователей тест на глубину словарного запаса татарского языка, который измеряет примерный объем лексикона человека. Тест рассчитан как на носителей языка, так и на тех, для кого татарский не является родным. База слов взята из национального корпуса татарского языка «Туган тел».

Как рассказал «БИЗНЕС Online» сам Аюпов, цель проекта – дать объективную оценку уровня знаний татарского языка конкретного человека, а также популяризировать в целом татарский язык.

Как отмечают разработчики, тест достаточно прост, но рассчитан на добросовестное выполнение: респонденты могут указать, знают они слово или нет. Чтобы не допускать неаккуратное прохождение теста, в нем присутствуют выдуманные слова-ловушки, которые выглядят и звучат как татарские слова. Также иногда тестируемым предлагается выбрать значение слова, которое они указали как знакомое.

Максимальный объем лексикона в данном тесте – 20 тыс. слов.

# В ТАТАРСТАНЕ ПРЕЗЕНТОВАЛИ ТРУД БУЛГАРСКОГО УЧЕНОГО XII ВЕКА

Древний труд булгарского богослова Сулаймана ас-Саксини является самым древним булгарским произведением, дошедшим до наших дней.

***islamnews.ru***



Оно датировано XII столетием. До сего дня считалось, что наиболее древними являются произведение булгарского средневекового поэта Кул Гали «Кысса-и Йусуф», написанное предположительно в 1233 году, и медицинский трактат булгарского врача Таджаддина ибн-Юнуса «Ат-тирйак ал-кабир» («Большое противоядие»).

Ведущего научного сотрудника ИЯЛИ Азата Ахунова поразили идеи, которые представлены в книге. «Подача материала по исламу отличается от современного ислама, он свободен от наслоений, которые были в последующие века, – уверен Ахунов. – Здесь Аллах всепрощающий и милосердный. Если сравнить с современной подачей нашего духовенства, которое запугивает грехами… Здесь автор говорит, что Аллах всепрощающ, главное – должна быть вера в Аллаха, иман. Самая главная идея, которая проходит через эту книгу, – всегда есть хэппи-энд».

# РДУМСО ОБЪЯВЛЯЕТ ГУМАНИТАРНУЮ АКЦИЮ ДЛЯ ПОДДЕРЖКИ ГРАЖДАН СЕЛА ЮЛДУС, ПОСТРАДАВШИХ ОТ ПОЖАРА

С 30 мая по 30 июня 2023 года ЦРО РДУМ Самарской области проводит гуманитарную акцию по сбору средств для поддержки граждан села Юлдус Курганской области, пострадавших от пожара.



Желающие помочь могут перечислить средства на расчетный счет ЦРО РДУМСО по следующим реквизитам с указанием назначение платежа: Гуманитарная помощь гражданам села Юлдус Курганской области, пострадавшим от пожара.

**Реквизиты для перечисления средств:**

Полное наименование организации: Централизованная религиозная организация «Региональное духовное управление мусульман Самарской области в составе Центрального духовного управления мусульман России».

ИНН: 6319064539, КПП: 631901001, ОКПО: 48149355, ОГРН: 1026300002112

**Банковские реквизиты организации:**

№ 40703810454400001932 в ПОВОЛЖСКОМ БАНКЕ ПАО СБЕРБАНК, БИК: 043601607, кор.счет: 30101810200000000607

**Для перечисления средств также можно воспользоваться QR-кодом**

# В КАМЫШЛЕ С РАЗМАХОМ ОТМЕТИЛИ САБАНТУЙ



10 июня жители и многочисленные гости Камышлинского района весело и с широким размахом отметили народный праздник Сабантуй.

*samtatnews.ru*

Традиционно праздник начался с конных скачек, которые прошли очень зрелищно. В программе фестиваля также были представлены соревнования по национальной борьбе кереш, по поднятию гирь, армрестлингу, лазанию по вертикальному столбу; прошли татарские традиционные национальные игры; работали выставки изделий декоративно-прикладного искусства.

На импровизированной улице национальных подворий гости могли увидеть постройки, отражающие жизнь, быт, культуру и традиции разных народов, продегустировать национальные блюда.

На празднике все гости с удовольствием принимали участие в народных играх: бег с яйцом в ложке или с полными ведрами воды, прыжки в мешках, парные забеги с завязанными ногами, лазание за призом по высокому и гладкому столбу, бои мешками с травой или сеном, которые проходят на скользком неустойчивом бревне. Особый интерес гостей вызвала площадка, организованная в честь биатлониста Эдуарда Латыпова, где каждый желающий мог прикоснуться к медалям, которые привез знаменитый земляк камышлинцев с Олимпийских игр, чемпионатов мира и Европы.

# «ТАТАРКИНО» ТАТАРСТАНДА ТӨШЕРЕЛГӘН 40ТАН АРТЫК ФИЛЬМНЫ АЧЫК ИНТЕРНЕТКА УРНАШТЫРДЫ

«Татаркино» Татарстанда төшерелгән билгеле фильмнарның бер өлешен үзенең рәсми сайтындагы «Онлайн кинотеатр» сәхифәсенә һәм YouTube каналына урнаштырды.




Проект ТАССРда кино төшерү һәм кино прокатының 100 еллыгы уңаеннан тормышка ашырыла, дип хәбәр итә «Татаркино»ның матбугат үзәге. Ул әлеге юбилей датасының киләсе елда булачагын искәртә.

Юбилей уңаеннан оешма республикада төшерелгән кинофильмнарның каталогын әзерли. «Татаркино» җитәкчесе Миләүшә Айтуганова әйтүенчә, фильмнар бигрәк тә Татарстаннан читтә яшәүче бик күп ватандашларның республикада төшерелгән киноларны карарга теләк белдерүе буенча урнаштырылган.

«Заманның трендлары шундый – күпләр фильмнарны өйдә карарга тели», - дигән ул.

Фильмнар жанрлар буенча бүленгән: драма, музыкаль комедия, биография, боевик, мелодрама һәм башкалар. Фильмнарны төшерелгән елы буенча да сайларга мөмкин. Сайттан «Мулла», «Хәлимә», «Бибинур», «Сөмбел», «Әпипә», «Зөләйха», «Дилемма», «Күктау» һәм башка фильмнарны карап була. Фильмнар авторларның һәм хокук ияләренең рөхсәте белән урнаштырылган.

Фильм карау өчен сылтамалар:

# В ШКОЛЕ «ЯКТЫЛЫК» ПРОШЛА ВИКТОРИНА «МИР ИСЛАМСКОЙ КУЛЬТУРЫ»



МБОУ Школа «Яктылык» уделяет большое внимание сохранению национальных татарских традиций и мусульманских устоев. 27 апреля впервые в школе прошла викторина «Мир исламской культуры» для учащихся 4-5 классов.

*samtatnews.ru*

На мероприятии присутствовали почетные гости: муфтий Самарской области Талип хазрат Яруллин, председатель попечительского совета культурно-исторического фонда «Булгарское наследие» Гумар Мулланурович Батыршин, первый председатель общества «Туган тел», доцент Архитектурно-строительного института Самарского государственного технического университета Рашид Фатыхович Абдулов, представители медресе «Нур» – ректор Али хазрат Сулейманов и преподаватель Ринат хазрат Нугманов. Они выразили благодарность администрации школы за достойное воспитание подрастающей татарской молодежи.

Викторина прошла в 2 этапа:

- Чтение сур из Корана и рассказ на татарском языке об истории ислама (прослушивание в каждом классе).
- Торжественное награждение победителей и участников.

Благотворитель подготовил памятные подарки для всех детей.

Приятным подарком для всех присутствующих стало выступление вокальной группы «Мөнәҗәт Нур» (худ. рук. А.Х. Гинятуллина).

# МУСУЛЬМАНЕ САМАРЫ ОТМЕТИЛИ УРАЗА-БАЙРАМ



***21 апреля во всех мечетях Самарской области прошли праздничные молитвы по случаю окончания месяца Рамадан и наступлению Ураза-байрама.***

*Данияр Сайфиев*

В Самаре главным местом празднования стала Самарская Соборная мечеть. На Фаджр (утренний намаз) к 4.30 часа утра собрались несколько тысяч верующих. А в 6 утра начался Гайд намазы. Ему предшествовала праздничная проповедь председателя Регионального духовного управления мусульман Самарской области, муфтия Талипа хазрата Яруллина. Муфтий поздравил всех правоверных мусульман с завершением благословенного Рамадана, отметив, что на протяжении тридцати дней и ночей верующие выполняли один из пяти величайших столпов ислама – соблюдали пост, для того, чтобы путем отказа от еды и питья в светлое время суток и ночных молитв и чтений Корана воспитать свой дух, обуздать свои страсти, научиться еще большей щедрости и отзывчивости.

– Сегодня на совместное поклонение собрались люди разных национальностей. Всех их объединяет вера и богобоязненность. Именно богобоязненность подвигает всех нас на совершение праведных поступков. Если мы будем добропорядочными людьми, жить в мире и согласии, показывать красоту нашей веры, то все это, конечно же, будет принято Всевышним. Хочу пожелать всем вам здоровья и благополучия. Чтобы Аллах принял наши поклонения, простил наши прегрешения. Чтобы дал жизнь нам до следующего Рамадана прожить в благочестии и хороших делах», – отметил в своем поздравлении муфтий Талип хазрат Яруллин.



Талип хазрат зачитал собравшимся поздравление от председателя Центрального духовного управления мусульман, Верховного муфтия России Талгата Таджуддина с завершением благословенного для всех мусульман месяца Рамадан. Также было зачитано поздравление от губернатора Самарской области Дмитрия Игоревича Азарова. Его озвучил вице-губернатор – руководитель департамента внутренней политики Самарской области Дмитрий Валерьевич Кочергин.

«...Правительство Самарской области уделяет большое внимание поддержанию межконфессионального мира, развитию многонациональной культуры в нашей губернии, где исстари в мире и дружбе проживают представители разных национальностей. Мы осуществляем совместные проекты по восстановлении культовых сооружений, памятников истории и культуры, реализуем образовательные проекты. Региональные власти и в дальнейшем будут поддерживать мусульманские религиозные организации и национальные общественные объединения. В этот праздничный день я хотел бы пожелать мусульманам Самарской области, всем нашим землякам здоровья, благополучия, мирного неба над головой и успехов во всех добрых делах и начинаниях на благо родной самарской земли и нашей Родины – великой России!» – говорится в послании губернатора.

На утренний намаз в Самарской соборной мечети на улице Стара-Загора собрались тысячи верующих. Как и в предыдущие годы, Соборная мечеть не смогла вместить всех желающих, поэтому многие совершали молитву на улице, у стен мечети.

Впервые после реконструкции Гайд намазы прошел и в самарской Исторической мечети. Праздничную проповедь здесь провел Наиль хазрат Биктаев. На утреннюю молитву также пришло очень много верующих, часть из них были вынуждены читать праздничную молитву на улице. Впрочем, это никак не сказалось на праздничном настроении пришедших сюда людей. Верующие, как и положено в Ураза-байрам, поздравляли друг друга и желали всем благословенного праздника.





# ИФТАРЫ ЕДИНСТВА

***В священный Рамадан представители мусульманской молодежи Самары при поддержке председателя РДУМСО, муфтия Талипа хазрата Яруллина провели выездные ифтары в Самаре и области.***

***Алсу Зилидинова***

Этот месяц правоверные мусульмане проводят в посте и благих деяниях. Именно поэтому многие в это время стараются опередить друг друга в добрых делах: помогают малоимущим деньгами, продуктами или лекарствами, а также организовывают вечерние разговения для постящихся.



Вот уже в течение нескольких лет с наступлением священного месяца Рамадан активом татаро-башкирской молодежи, а также прихожанами мечетей Самары организовываются массовые ифтары. В этом году они выступили организаторами больших вечерних мероприятий в поселке Угловой, в мечетях сел Абдреево, Мулловка, Елховый Куст, Теплый стан, в мечетях «Имени Хусаина» и «Булгарское наследие» в Самаре. В каждом таком меджлисе приняли участие от 100 до 300 человек.

Одним из главных волонтеров-первооткрывателей выездных ифтаров является Равиль Ахтариев.

«Идея родилась 12 лет назад, – рассказывает Равиль. – Ее мы придумали вместе с друзьями. Первый выездной ифтар-меджлис провели во дворе мечети поселка Угловой (Ялтай) Красноярского района Самарской области. Мы тогда были так воодушевлены этим огромным и значимым событием, что решили продолжать проводить такие объединяющие мероприятия. Ведь они демонстрируют единство татаро-башкирского народа и определяют его духовность и близость».



В этом году к инициативной группе по подготовке ифтаров присоединилось еще больше ребят, которых объединяет стремление сообща делать благие дела и помогать друг другу. Они сообща закупали необходимые продукты, готовили в полевых кухнях, накрывали и убирали столы. Будучи в состоянии поста, ради довольства Всевышнего Аллаха с самого утра до позднего вечера они готовы были бесплатно помогать в проведении разговений. Они работали за саваб от Всевышнего. Ни это ли наивысшая награда?!

# ПРАЗДНИК ДЛЯ ДЕТЕЙ И ИХ РОДИТЕЛЕЙ

*23 апреля на территории Самарской Соборной мечети прошел большой и красочный праздник для детей и их родителей, посвященный завершению Священного месяца Рамадан. Традиционно его организатором выступило Региональное духовное управлением мусульман Самарской области.*

*Данияр Сайфиев*



Праздник изначально планировалось провести днем раньше, но из-за неблагоприятных прогнозов погоды было решено перенести его на воскресенье. И не прогадали. Уже с утра светило яркое и теплое весеннее солнце, также ярко и красочно было и на самой праздничной площадке. Разноцветные батуты, карусели, шоу мыльных пузырей, всевозможные конкурсы, викторины и мастер-классы в сочетании с очередями за воздушной сладкой ватой и хрустящим попкорном и пышными хот-догами – всё это и создавало атмосферу настоящего праздника. Главным же украшением детско-семейного праздника «Ураза-2023» стала передвижная сцена, на которой дети исполняли нашиды и суры из Священного Корана, участвовали в конкурсах на знания основ ислама, за что получали заслуженные «баракатики». Их дети и взрослые могли обменять на развлечения или сладкое угощение. Также праздничную «валюту» можно было приобрести за деньги, тем более что веселый и задорный ведущий праздника Радиф Ахмадиев заранее объявил гостям и участникам праздника, что все вырученные средства пойдут на благотворительность.

Собравшихся с Ураза-байрамом от всей души поздравил председатель Регионального Духовного Управления мусульман Самарской области, муфтий Талип хазрат Яруллин. Он отметил, что в этом году Аллах дал всем нам раннюю погожую весну, и верующим было не так сложно соблюдать пост.












*– Ураза – для всех нас большой праздник. Ваши родители, бабушки и дедушки в течение месяца соблюдали пост, а дети заучивали аяты, чтобы сегодня продемонстрировать нам здесь свои навыки и знания, показать различные сценки для того, чтобы все смогли еще больше проникнуться духом ислама, духом Рамадана. Мы сегодня радуемся тому, что Аллах дал нам возможность соблюсти Священный для каждого из нас пост, и огорчаемся тому, что он так быстро закончился. Ведь это время, когда мусульмане получают большие награды за свои добрые деяния и чистые помыслы. Дай Аллах нам возможность делать как можно больше хороших дел, чтобы к следующему Рамадану мы пришли с еще лучшими знаниями! Я рад, что вы стали активными участниками сегодняшнего нашего мероприятия. Хорошего вам праздника и веселого настроения,* – сказал в своем выступлении Талип хазрат.

Ураза-байрам в формате семейного праздника проводится Региональным духовным управлением мусульман Самарской области в четвертый раз. Каждый год он собирает все большее количество участников. Радует, что дети с каждым разом приходят сюда более подготовленными, становятся более разнообразными викторины и конкурсы, предприниматели и национальные диаспоры активно подключаются к его подготовке, помогают в приобретении призов и подарков, готовят вкусные угощения.

В этом, наверное, и заключается сакральный смысл Ураза-байрама – радоваться самим и дарить добро и радость окружающим, приобщать молодое поколение к истинным ценностям ислама.









# БУДЕМ И ВПРЕДЬ СЛЕДОВАТЬ ВЕРЕ ПРЕДКОВ

## В Соборной мечети прошел VII съезд самарских мусульман

***В работе съезда приняли участие 250 делегатов из разных уголков губернии. Среди них – руководители местных религиозных организаций, национально-культурных объединений, представители бизнеса. На съезд также были приглашены представители духовных управлений Оренбургской, Ульяновской, Пензенской областей.***

***Данияр Сайфиев***



Напомним, что съезд РДУМСО, который проводится один раз в шесть лет, является одним из самых значимых событий мусульманской уммы нашего региона. На нем подводятся итоги проделанной за предыдущий выборный период работы, а также избирается состав руководящих органов Регионального духовного управления мусульман – президиума и контрольно-ревизионной комиссии. При этом должность председателя регионального управления не является выборной: он назначается председателем Центрального духовного управления мусульман России – Верховным муфтием Шейх-уль-Исламом Талгатом Сафа Таджуддином.

По традиции открытие меджлиса началось с чтением аятов Священного Корана. После этого было зачитано приветствие делегатам приветствия губернатора Самарской области Дмитрия Азарова. В своем послании глава региона отметил, что съезд проводится в непростое для нашей страны время, когда необходимо сплочение нашего межнационального и межконфессионального народа для скорейшего достижения мира.

*– Являясь делегатами съезда, вы представляете здесь почти каждый уголок нашего региона, где на протяжении веков мирно живут и трудятся представители разных национальностей и конфессий, носители культурно-исторического и духовного наследия. Региональное духовное управление мусульман Самарской области играет ключевую роль в жизни самарской мусульманской общины. При его содействии строятся и восстанавливаются мечети, реализуются благотворительные проекты, проводится большая работа, направленная на сохранение и обогащение традиций российского ислама, укрепление межконфессионального мира и гражданского со-*

*гласия в обществе, дружбы между народами. Немало мусульман сегодня принимают участие боевых действиях в ходе специальной военной операции. Пусть Всевышний поможет нам вместе справиться со всеми испытаниями,* – говорится в послании Дмитрия Азарова.

По видеосвязи к делегатам съезда обратился председатель ЦДУМ России Талгат Сафа Таджутдин, который высоко оценил деятель-







ность Регионального духовного управления мусульман Самарской области и лично муфтия Талипа хазрата Яруллина в сохранении и продвижении духовно-нравственных ценностей на основе Корана, выразил слова благодарности губернатору Самарской области за постоянную и неоценимую поддержку мусульманской уммы региона и пожелал успешной работы участникам и гостям меджлиса.

После этого делегаты заслушали доклад главного бухгалтера РДУМСО Амины Муртазиной о поступлении и расходовании средств за отчетный период. Выступивший после нее председатель контрольно-ревизионной комиссии Газизжан Сафиуллин, подтвердил, что проведенная проверка не выявила нарушений в экономической деятельности организации и каждая финансовая операция имеет документальное подтверждение.

Конечно же, ключевым событием съезда стал отчетный доклад муфтия Талипа хазрата Яруллина, который подвел итоги шестилетней деятельности регионального духовного управления.

– *Период с 2017 по 2023 год был наполнен большим количеством событий. Мы вместе многого достигли, открывали и реконструировали мечети, пережили сложные и непростые времена пандемии, когда приходилось ради безопасности наших прихожан, закрывать мечети. Мы разделили горечь потери близких и дорогих нам людей. По милости Всевышнего мы двигаемся дальше и развиваемся, продолжая начинания наших аксакалов и помня героические поступки наших товарищей,* – начал свое выступление Талип хазрат.

В своем докладе он отметил, что работа РДУМСО в отчетный период велась по разным направлениям, среди которых религиозная деятельность, социальная, религиозно-просветительская, благотворительная, духовно-нравственная, образовательная, общественная, молодежная и патриотическая работы. За шесть лет было открыто 6 приходов, начато строительство пяти мечетей, еще две реконструированы. Особое внимание уделялось и будет уделяться впредь работе с детьми и молодежью. При медресе «Нур» ежегодно открываются лагеря для детей, организовываются этнокультурные смены с круглосуточным пребыванием детей на базе оздоровительных лагерей Самарской области. Проводится большая работа по организации просветительских, семейных и развлекательных праздников на открытых площадках. РДУМСО был организован сбор средств пострадавшим в результате землетрясений в Турции и Сирии. Дважды проведен сбор средств и закуплены теплые вещи для мобилизованных, участвующих в боевых действиях в рамках специальной военной операции на Украине. По всем направлениям муфтият тесно сотрудничает с органами власти, что безусловно, является важным фактором стабильного развития общества и государства.

Делегаты съезда единогласно приняли отчет муфтия. Также единогласно они проголосовали и за предложенную резолюцию съезда, главный тезис которой заключается в том, что РДУМСО и впредь в своей работе будет основываться на Конституцию Российской Федерации, а в своей религиозно-культовой деятельности будет руководствоваться откровениями Всевышнего Корана, сунны посланника Аллаха Муххамада (да благословит его Аллах и приветствует), нормами исламского права, следовать по пути укрепления веры в мусульманских традициях наших предков – волжских булгар.

# “Туган якларымны сагынам”

***Апрель ахырында Татарстан Республикасы Фәннәр академиясендә тарихчы, ТАССРның атказанган мәдәният хезмәткәре Гомәр Сәлих улы Сабирҗановның «Татар энциклопедиясе: барлыкка килү тарихының кыскача очеркы» дип аталган китабын тәкъдим итү кичәсе булып узды.***

*Эльмира Сәйфуллина*

Китапта Ватан тарихнамәсендә беренче тапкыр Татарстан энциклопедистикасы үсешенең төп этаплары, формалашуы һәм Татар энциклопедиясе институтының 1990 - 2010 елларда үсеше чагыла. Басма киң укучылар даирәсенә адресланган.

Әлеге чара күренекле якташыбызның 90 яшьлек юбилеена багышланган иде. Әйе, якташыбыз. Чөнки Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе, Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институтын оештыручыларның һәм җитәкчеләренең берсе булган Гомәр Сабирҗанов 1933 елның 20 апрелендә хәзерге Самар өлкәсенең Кошки районы Яңа Фәйзулла авылында туган. Ул 1955 елда Ульяновск педагогика институтын тәмамлый һәм Тува автономияле өлкәсенең Кызыл шәһәренә җибәрелә. Анда тарих укытучысы, мәктәп-интернатның уку бүлеге мөдире, шәһәр халык мәгарифе бүлеге инспекторы булып эшли, бераздан шунда ук партия эшенә кереп китә. 1971 елда Мәскәүдәге КПСС каршындагы Иҗтимагый фәннәр академиясен тәмамлагач, Казан шәһәренә эшкә юллама ала һәм ТАССРның Министрлар Советы эшләре идарәсе учреждениеләре бүлеге җитәкчесе итеп билгеләнә. 1980 - 1992 елларда Казан мәдәният һәм сәнгать институтының теория һәм мәдәният тарихы кафедрасы мөдире булып тора. Анда ул «Урта Идел буе халыкларының социаль үсеше һәм мәдәнияте борынгы заманнардан XX гасыр башына кадәр» дигән тулы форматлы махсус курс эшләп чыгара. 1992 елда аңа Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе бүлеге мөдире вазифасын тәкъдим итәләр. Әлеге бүлек нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты карары буенча, 1994 елда Татар энциклопедиясе институты булдырыла. 2011 елдан башлап, бүгенге көнгә кадәр Гомәр Сәлих улы Татар энциклопедиясенең җаваплы мөхәррире һәм баш мөхәррир урынбасары булып тора.

Гомәр Сабирҗанов Татарстан Фәннәр академиясенең Татар энциклопедиясе институтында эшләгән чорда Татар энциклопедик сүзлеген 1999 елда - рус, 2002 елда - татар телендә; рус телендә 6 томлык Татар энциклопедиясе һәм аның 1 - 4 томнары татар телендә басылып чыга. 2013 елда «Татарстан: иллюстрацияле энциклопедия» дип аталган китап дөнья күрә. Якташыбыз әлеге проектның авторы һәм җаваплы редакторы була. Бу китап «2013 елның иң яхшы китабы» конкурсында «Иң яхшы сүзлек-энциклопедия басмасы» номинациясендә Россия китап нәшриятчылары ассоциациясе премиясенә лаек була.

Рус һәм татар телләрендә татар энциклопедик сүзлеген эшләүгә һәм бастыруга керткән өлеше өчен 2005 елда Гомәр әфәнде Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт премиясе белән бүләкләнә. «Почет Билгесе» ордены, медальләр, Татарстан Республикасының Мактау грамотасына лаек була.

Гомәр Сабирҗановның күпсанлы фәнни эшләре арасында «Идел буе татарлары һәм руслары симпатия һәм антипатия көзгесендә», «Урта Идел буе һәм Көньяк Урал халыклары гасырлар панорамасында» кебек китаплар да бар.

Эше искиткеч күп булуга карамастан, Гомәр ага туган якларын, Самар татарларын беркайчан да онытмаган. Якташларының тормышы, көнкүреше белән һәрдаим кызыксынып тора, өлкәдә чыгып килүче массакүләм мәгълүмат чараларында мәкаләләрен бастыра. «Самар татарлары» журналын укучылар аның язмалары белән



бик яхшы таныш. Буш вакыты булганда, Гомәр Салихович туган авылына кунакка да кайта. 2021 елның җәендә Яңа Фәйзулла авылына кайтып киткәннән соң, Гомәр ага, авылының үзгәртеп кору җилләренә нык бирешкәненә бик борчылып: «Туган авылыма сәфәр миндә күңелсез тәэсир калдырды. Казанга кайту юлында Яңа Җүрәемдә күргәннәр турында уйланып, рус язучысы Александр Радищевның «Петербургтан Мәскәүгә сәяхәт» әсәрендәге «Мин тирә-ягымны карадым. Җаным кешелек газаплары белән зарарланды», дигән сүзләре искә төште. Минем җанымны күп газаплар кичергән Россия авыллары һәм туган авылым язмышы бораулады. Ул элек тә бик авыр язмыш юлы үткән, хәзер тагын зур билгесезлек алдында тора», - дип язган иде.

Гомәр Сәлих улы Сабирҗановны олы юбилее белән ихлас күңелдән тәбрик итеп, иң изге һәм матур теләкләребезне җиткерәсебез килә. Сезгә ныклы сәламәтлек, күңел көрлеге, җан тынычлыгы һәм иҗади уңышлар телибез.

# ХӘЕРЛЕ СӘГАТЬТӘ БУЛСЫН!

***Хатын-кызлар, җир йөзенә көтеп алынган нарасыен тудыргач, бәхеттән балкып, елмаеп: "И, сабыем, күз нурым! Аллаһыга шөкер, исән-имин дөньяга килдең. Хәерле сәгатьтә туып, безнең лаеклы дәвамчыбыз булып үсәргә язсын үзеңә, балам!" - дип теләкләр телиләр. Үсә төшкәч, "әнием", "әтием", дип баланың теле ачыла. Шушы матурлык гасырлар буена дәвам иткән. Ләкин, ни кызганыч, соңгы вакытта татар халкының матур, аһәңле теленә куркыныч яный шул. Елдан-ел мәктәпләрдә татар телен укытуга сәгатьләр азрак бирелә башлады. Өстәвенә, күп яшь әти-әниләр өйләрендә балалары белән рус телендә генә сөйләшәләр.***

***Нурсинә Хәкимова.***



Шушы проблемалар турында фикер алышыр өчен, мин Денис авылы мәктәбенә юл тоттым. Биредә мине күп еллардан бирле җитәкче булып эшләүче Рәфыйк Әбрар улы Минһаҗев һәм укытучылар коллективы каршы алды. Мин аларга үземне кызыксындырган сорауларымны бирдем.

***- Рәфыйк Әбрарович, мәктәп тормышы турында сөйләп үтсәгез иде.***

- Уку елы ахырына таба якынлашып килә. Шулай булса да, без эшебезне җиренә җиткереп алып барырга тырышабыз. Укучыларыбызда әлегә арыганлык сизелми, алар зур теләк белән белем туплауны дәвам итәләр.

Мәктәбебездә уку атнасы, Россия әләмен күтәреп, гимн җырлаудан башланып китә. Бу укучыларда ватанпәрвәрлек хисләрен тәрбияләргә ярдәм итә. Җыр дәресен алып баручы Әлфия Минһаҗева балаларны җырларга гына өйрәтми, ә аларда җыр-моңга кызыксыну, мәхәббәт уятыр өчен, төрле кызыклы чаралар, конкурслар да оештыра. Һәм укучыларыбызга бу бик ошый.

Тагын шуны искәртеп үтәсем килә: безнең мәктәптә белем алган Рәүф Хәннанов, Марат Мәннапов бүгенге көндә махсус хәрби операциядә катнашалар. Алар турында бары тик яхшы сүзләр генә ишетелә.

Яшүсмерләребез, волонтёрлар буларак, авылны чүп-чардан арындыруда, чишмәләрне чистартуда катнашалар, ялгыз яшәүче картларга ярдәм итәргә ашкынып торалар.

Уку-укыту һәм тәрбия эшләре буенча минем урынбасарларым - Фәнүзә Фәлахова белән Рузалия Щербакова үз хезмәтләренә зур җаваплылык белән карыйлар, яшь буынны тәрбияләүдә һәм белем бирүдә көчләрен кызганмыйлар.

***– Мәктәптә укучылар саны күпме?***

– Бездә барлыгы 56 укучы белем ала. Шулар арасында Карабикол авылыннан - сигез, Әбдекидән өч бала бар. Аларны автобуста китерәләр, дәресләр тәмамлангач, өйләренә кайтарып куялар.

Бүгенге көндә балалар бакчасында егерме кыз-малай тәрбияләнә. Авылыбызга читтән кайтып урнашкан рус телле балалар хакында биредә русча гына аралашалар.

***- Быел мәктәпне ничә укучы тәмамлаячак? Беренче сыйныфка күпме бала килергә тиеш?***

– Быел мәктәпне дүрт укучы тәмамлаячак. Беренче сыйныфка сигез бала килергә тиеш.

***– Тугызынчы сыйныфтан соң китүчеләр күпме?***

- Әйе, андыйлар да юк түгел. Араларында геолог, нефтьче һөнәрләрен, компьютер технологияләрен үзләштерүчеләр бар.

***- Башка авыллардан килеп укучылар булгач, мәктәптә берәр нинди проблемалар тумыймы?***

- Проблемалар бар шул. Әйтик, Карабикол авылыннан килеп укучылар арасында татарча сөйләшүче балалар юк. Белгәнебезчә, хәзерге вакытта катнаш гаиләләр күбәеп китте. Әти-әниләр үзара рус телендә аралашкач, нарасыйлары да русча гына сөйләшәләр. Андыйларга ияреп, безнең авыл балалары да русча аралаша башладылар. Әле тагын шунысы бар: авылыбызда татарлар гына яшәсә дә, соңгы елларда күп ата-аналар, балаларын алдагы тормышка әзерләү ниятеннән, өйләрендә рус телендә сөйләшүгә карар кабул итәләр. Бу инде бернинди кысаларга да сыймый торган нәрсә. Чөнки укучылар рәтләп татарча да, русча да белмиләр. Мондый балалар белән эшләве бик авыр. Аларны җайга салуы - бик мәшәкатьле хезмәт. Әлеге укучылар, мәктәпне тәмамлап, чит җирләргә чыгып киткәч, русча сөйләшүләрен дәвам итәләр, шулай итеп, ана теле бөтенләй

онытылып кала. Шундый хәлләр кабатланып торса, ата-бабаларыбыздан мирас булып калган туган телебезгә бетү куркынычы янаячак. Телебез бетсә, гореф-гадәтләребез, матур йолаларыбыз да югалачак бит!

Тарих битләренә күз салсаң, Явыз Иван, татарларны көчләп чукындырып, Казан ханлыгын тар-мар итәргә теләсә дә, хәтәр репрессия елларында да татар-мөселман кардәшләребез бирешмәгәннәр, үз телен, динен саклап калырга тырышканнар. Төрмәләрдә газап чиккән милләттәшебез Баһадиршаһ, телен кисеп алсалар да, сатылмаган, ата-баба васыятенә тугры калып, горур килеш мәңгелеккә китеп барган!

Телефон да боза шул хәзер яшьләрне. Бала тәпи атлап китүгә диярлек, әти-әнисе аның кулына телефон тоттыра. Без үскәндә исә кышларын рәхәтләнеп чаңгыда шуа идек, җәйләребез гүзәл табигать кочагында үтә иде. Үсә төшкәч, әти-әниләребезгә йорт хуҗалыгында булыша идек. Ә бүгенге балаларның саф һавада йөрергә теләкләре юк. Һаман шул телефоннарында утыралар. Ичмасам, анда татар телендә мультфильмнар, фильмнар карасалар иде. Хәзер бит интернет челтәрендә, ана телен үзләштерер өчен, күп мөмкинлекләр тудырыла.

Менә шундый аянычлы хәлләр турында сөйләде миңа бөтен гомерен балалар тәрбияләүгә багышлаган Рәфыйк Әбрар улы. Аңардан соң сүзне аның урынбасары Фәнүзә Фәлахова алды:

- Илебездә коронавирус авыруы киң җәелү сәбәпле, күпмедер вакыт безгә укучыларыбызны дистанцион рәвештә укытырга туры килде. Аллаһыга шөкер, хәзер эшләребез әкрен генә җайга салынып килә инде.

Без, укытучылар, даими рәвештә белемебезне үстереп, камилләштереп торабыз, төрле конкурсларда катнашабыз. Шуңа күрә, шөкер, мәктәбебездә укучыларыбызга тиешле дәрәҗәдә белем һәм тәрбия бирелә. Укучыларыбыз да тырышып укыйлар, төрле чараларда һәм бәйгеләрдә бик теләп катнашалар.

Менә, ниһаять, ана теле темасына килеп җиттек. Сүзне татар теле укытучысы Нурсинә Хәмәтшина алды:

– Укучылар беренче сыйныфта “Әлифба”ны үзләштерәләр. Башка сыйныфларда татар теленә сәгатьләр бирелми. Бары тик бер сәгать факультатив буларак кына укытыла. Бишенче сыйныфтан алып, тугызынчы сыйныфка кадәр татар теле атнасына бер керә. Ә шушы факультатив дәресендә әдәбият укытабыз. Шатлыкка, укучылар татар телен яратып үзләштерәләр. Мәсәлән, Камилә Вәлиева, Диләрә Идиятуллина, Алинә Ногманова, Самар шәһәрендә үткәрелгән конкурста, Казанда узган олимпиадада катнашып, призлы урыннарга лаек булдылар. Бу аларга Казан лагерьларында ял итү мөмкинлеге бирде.

Шунысы кызганыч, укучыларыбыз - Диләрә Идиятуллина, Әдилә Әхмәтвәлиева, Алия Гыймранова, Дилә Бикмөхәммәтова, авырып китү сәбәпле, өлкә олимпиадасында катнаша алмыйча калдылар. Хәзер инде менә киләсе елга әзерләнәбез. Әгәр алар өлкә олимпиадасында җиңсәләр, Аллаһы бирсә, Халыкара татар олимпиадасында катнаша алачаклар.

Моннан тыш, укучыларыбыз инглиз телен өйрәнәләр. Нәзирә Зәйнуллина, шушы телне тирәнтен үзләштерер өчен, югары уку йортына керде.

Укытучылар белән аралашкач, мәктәп бинасын карап чыктык, музейга кердек. Әйтергә кирәк, биредә тәртип, чисталык, пөхтәлек хөкем сөрә. Сыйныф бүлмәләре, зал кирәгенчә җиһазландырылган, дәрестә куллана торган стендлар үз урыннарын алганнар.

Ә музейга кергәч, сокланмый мөмкин түгел. Бирелә Бөек Ватан сугышы, тыл, хезмәт ветераннары һәм башка даһи кешеләр турында тулы мәгълүматлар тупланган. Ватан сугышыннан килгән солдат хаты күзгә бәрелеп тора. Гаҗәп хәл! Аллаһының рәхмәтедер инде, аның хәтта кәгазе дә саргаймаган.

Музейның икенче өлешендә, элекке тормышны искә төшереп, төрле эш кораллары, тормыш өчен кирәкле әйберләр урын алган. Бирелә бөтен нәрсә турында сөйләп бетереп тә булмас иде. Татар халкы әйтмешли, кемнәндер ишеткәнче, үз күзең белән күрсәңче.

Ахырдан Рәфыйк Әбрар улы:

- Музеебыз экспонатлар белән тулып килә, чөнки шушы изге эшебезгә авыл халкы да битараф түгел, педагогларыбыз да, балалар да бик тырышалар. Рәхмәт инде аларга!

Киләчәктә безгә тагын бер бүлмә кирәгеп чыгар, дип уйлыйм. Музеебызның бер өлеше авылның Мәдәният йортында урнашкан. Читтән килүче кунакларыбыз, авылдашларыбыз бик яратып, сокланып музейларыбызда сәяхәт итәләр, - дип сөйләде.

Мин, барысы белән дә саубуллашып, кайтыр юлыма кузгалдым. Ә башымда төрле уйлар бөтерелде. Безнең балачакта татар теле һәр көнне укытыла иде. Ә хәзер нибары бер сәгать кенә калган. Ә шулай да, укучыларның уңышлары турында уйласаң, аларның һәм укытучыларның тырышлыгына сокланырлык. Шуның өчен барысына да рәхмәт кенә әйтәсе килә.

Ә кичен, телевизорны кабызып, ял итәргә утырдым. Рәфыйк Әбрар улының сөйләгәннәре турында уйланып утырган вакытта “Татарстан - Яңа Гасыр” каналыннан шатлыклы хәбәр ишетергә туры килде. ”Татармультфильм” берләшмәсе пьеса сюжетын анимациягә күчергән. Халыкка Туфан Миңнуллинның легендар ”Әлдермештән Әлмәндәр“ әсәренә нигезләнгән мультфильм тәкъдим ителәчәк. Әлеге проект татар телен саклау, аны үстерү ниятеннән булдырылды, дип әйтелде.

Менә шушы күтәренке рухта мәкаләмне тәмамлап, хәерле сәгатьтә булсын, дип әйтәсем килә.

# Милли җанлы җитештерүче



**– «Самар татарлары» журналын шаккатып укып чыктым. Башка журнал-газеталардан бик нык аерыла икән, – дип уртаклашты Яр Чаллыда яшәүче эшмәкәр Алия Нәсим кызы Ганиева. – Тирән эчтәлекле, милли темаларга курыкмыйча язалар, тарихи мәкаләләр дә бар. Язучы Айгөл Әхмәтгалиева белән әңгәмәне рәхәтләнеп укыдым («Самар татарлары» журналы, №1, 2023 ел). Аның туган телне саклау, балаларны тәрбияләү турында әйтелгән фикерләре белән тулысынча килешәм, ләкин үземнең дә әйтер сүзем бар.**

**Гөлназ Таипова.**
*Фотолар Алия Ганиева архивыннан.*

– Мин – эшмәкәр, ләкин асылым – миллилектә, – дип ассызыклый Алия Ганиева. – Казанның финанс-икътисад институтын тәмамладым. Җитештерүнең ике ягы бар, дип өйрәттеләр безне. Берсе – акча эшләү. Әлбәттә, бу стимул бирә, минем өчен ул - ягулык, этәргеч. Акча кермәсә, кәеф төшә. Керем һәм кешеләрнең рәхмәт сүзләре күңелне күтәрә. Ләкин җитештерүнең икенче, югарырак торучы максаты да бар, миссия, дип атыйбыз без аны. Минем миссия – милли ризыкларга гашыйк иттерү, татар халык ашларының дәрәҗәсен күтәрү.

Яр Чаллыда Алияне чәкчәк пешерү остасы буларак беләләр. Шулай ук ул талкыш кәләве, гөбәдия, өчпочмак, кыстыбый кебек милли ризыкларны әзерли.

Татар телен үстерүгә үз өлешен кертергә тырыша: социаль челтәрләрдәге аккаунтларын татарча алып бара, җитештергән ризыкларының этикеткаларын да ике телдә яза. Онытылган рецептларны кайтарып, татар халык ашларын популярлаштырырга, милли үзәк ачарга теләге бар аның.

Алия Ганиева шәһәрдә, рус мохитендә үскән.

- Мәктәптә, институтта укыгында милләт, тел турында уйланып йөрмәдем, миллилек соңыннан формалашты, - ди ул.

## Татарлар икәнебезне белеп үстек

– Мин гап-гади гаиләдә тәрбияләндем, өйдә татарча сөйләштек, ләкин беркайчан да: «Без - татарлар, милләтебез белән горурланып яшәргә кирәк!» - ди-

гән сүзләр булмады, – дип аңлата Алия. – Ике яшьтән мине рус балалар бакчасына, соңыннан рус мәктәбенә бирделәр. Әти дә, әни дә һөнәрчеләр иде – бүрек тегүчеләр. Әнинең үз кибете булды. Без бәләкәйдән үк эшләп үстек. Әти белән әнигә ярдәм итәргә кирәк: тире чылатабыз, фетр тегәбез. Яз җитсә – авылга кайтып эшләү. Минем дәрескә әзерләнүне беркем дә тикшереп тормады, ул минем җаваплылыгым иде.

Чит кешеләр белән аралаша башлаганда, алар мине татар теле укытучысы, дип уйлыйлар. Бердән, мин мәктәпкә 1993 елда бардым. Бу – милли хәрәкәтнең җимешләрен татыган вакыт. Мин - шул чорда тәрбияләнеп калган бала. Без татарлар икәнебезне белеп, горурланып үстек. Икенчедән, аңлавымча, безнең сыйныфка шәһәр мәктәпләреннән математикага сәләте булган һәм татар телен яхшы белгән балаларны туплаганнар.

Милли хәрәкәтнең чәчәк аткан вакыты булса да, укытучылар көчле булса да, ул чагында да татар теле дәресләренә ничектер йомшаграк карадык: өй эше эшләнми калса да ярый иде. Бәхетебезгә, татар теле укытучыбыз әйбәт булды, безгә тарихны да өйрәтергә тырышты. Идел буе Болгар дәүләте, Казан ханлыгы турында без татар теле дәресләреннән белдек. Финляндия татарлары турында укытучыбызның кызыклы итеп сөйләгәне истә калган. Татар теле, татар әдәбияты дәресләре күп, укыдык, яздык, грамота җитәрлек, факультатив дәрәҗәдә генә түгел иде. Ләкин шуны да әйтергә кирәк: сыйныфта барыбыз татар булсак та, үзара русча сөйләштек. Хәзер дә очрашуларда русча сөйләшәбез.

Казанда иптәш кызым Гүзәл бар, без институтта таныштык. Ул миңа бервакыт: «Беләсеңме, мин синең белән ничек дуслашырга булдым? Без институт баскычыннан төшә идек, син әниеңә шалтыраттың да аның белән матур итеп татарча сөйләштең. Мин артыңнан тыңлап бардым. Татарча сөйләшүең ошады миңа, шуннан соң синең белән дуслашырга теләдем», - дигән иде. Кешеләр шулай бер-берсенә тартыла бит. Татар теле, татарлык юк иде институтта, төрле төбәкләрдән килгән кешеләр белән укыдык. Бөтен төркемебез русча сөйләшкәндә, без Гүзәл белән татарча аралаштык. Тора-бара, безгә ияреп, калганнар да татарчага күчте. Гүзәл бөтен кешегә «җимеш», дип эндәшә, без дә бер- беребезгә «җимеш», дип әйтә башладык. Бөтен кеше русча сөйләшә дип, татар телен онытмадык, киресенчә, безгә татарча сөйләшү рәхәт иде.



## Нишләп театрга йөрмисез?

– Студент чагымда үк татар театрларына йөрдем. Театрны яратам. Камал театры Чаллыга гастрольгә килгәндә, әти-әниләр белән бара идек. Театр мине шул вакытта ук сихерләде. Әле дә исемдә: «Казан егетләре» спектаклендә Рамил Төхвәтуллин, печән өстенә ятып, бер кызга гашыйк булуы турында сөйли. Шундый матур күренеш иде ул, тәэсирләнеп, сихерләнеп, сокланып караган идем, – дип сөйли Алия. – Хәзер исә мин салкын акыл белән карыйм, кем ничек уйный - барысын контрольдә тотам. Тәҗрибәм дә бар, чөнки театрга еш йөрибез. Күптән түгел ирем белән «Бик сагынсаң әгәр» спектакленә бардык. Бик күңелле, ә залда кеше аз. Нишләп йөрмиләр? Бәлки, тамаша карап, күңел ача торган вакыт түгелдер? Ләкин бит Ф. Тямаев, Ә. Нургалиев, икесе бер юлы Чаллыга килеп, шыгрым тулы заллар җыйдылар. Димәк, кешенең кәеф-сафа корасы килә.

Театрның бинасы яңа, яшь артистлар килде. Әйтер идең – маркетинг эшләми, дип. Юк, социаль челтәрләрдә даими рәвештә эш алып барыла, яшьләр белән эшлиләр, игъланнар чыга, блогерлар белән коллаборацияләр үткәрелә, күргәзмәләр оештырыла. Бер дә тик тормыйлар. Нәрсә ошамый? Аккаунтыма язылган кешеләр арасында сораштыру үткәрдем. Репертуар ошамый, диючеләр бар. Репертуар бай, сайлап була. Миңа да ошамаган спектакльләр бар, ләкин ошаганын табып була. Ярты миллионлык шәһәрдә театр залында 50 кеше утыра. Г. Камал театры Чаллыга килә, аңа билетны ике ай алдан алып бетерәләр.

Без Камал театрының бер спектаклен карадык. Минемчә, сюрреализм, бернәрсә дә аңламадым, ә зал шыгрым тулы иде. Карап, кул чабып кайттык. Нигә Камал театрына йөриләр, ә Гыйләҗев театрына юк? Мине бу мәсьәлә бик борчый. Театрга бару – минем өчен ял. Ләкин уйландыра, тәэсирләндерә торган ял.

## Укыганда каз тәннәре чыга икән, димәк, кызык

Татар китаплары темасын да кузгатты әңгәмәдәшем. Аларны ул ярминкәләрдә, Печән базарында сатып ала. Аеруча «Юлбасма»

нәшрияты бастырган китапларны ошата.

– «Үзем белдем диген» китабын рәхәтләнеп балалар белән укыдык, ул матур рәсемнәре белән аерылып тора. Рәссам – Гөлнара Фәлахова, аның иҗаты үзенчәлекле, – ди Алия ханым. – Китапханәгә йөрибез. Китапханәче Венера апа янына мин икенче сыйныфтан башлап йөрдем. Ул минем таләпләремне белә: җайлы укыла торган китап булсын, ләкин колхоз һәм мескен хатыннар турында түгел. Әмирхан Еники, Аяз Гыйләҗевны яратып укыйм. Күптән түгел Әнгам Атнабаевны укыдым. Ошады. Яраклашучы кешеләрне яратмыйм мин. Атнабаев яраклашучы кешеләрдән булмаган, теләгәнен сөйләп, теләгәнен язып яшәгән, дип уйлыйм.

Балалары тугач, Алия китапханәгә алар белән бергә йөри башлаган. Өч яшьлек улын җитәкләп, кечкенә кызын слингка салып барган.

– Безне күргәч, Венера апа көлеп үк җибәрде. «Мондый укучыларны күргән юк иде әле», - ди. Балалар бәләкәй чакта Р. Миңнуллин, Л. Лерон, Ә. Бикчәнтаева әсәрләрен укыдык. Хәзер аларга туплар, чәчәкләр, болытлар турында шигырьләр кызык түгел. Нәрсә укытып була 12 яшьлек малайга? – дип борчыла Алия. – Мәктәпкә йөри башлагач, «Денискины рассказы» укыдык. Укырга күңелле, мавыктыргыч, хәрәкәт бар. Ә татар телендә андый хикәяләр юк диярлек. Алар бар, ләкин алай ук кызык түгел. Кайбер китапларның татарчага тәрҗемә ителгәннәрен алам, мәсәлән, «Маугли», «Винни Пух». Җөмләне укый башлыйм, ахырына җиткәнче, буталып бетәм. Шундый авыр тел белән язылган. Ул балаларга түгел, олыларга да укырга авыр. «Гарри Поттер» китапларын мавыгып укыган сыман нәрсәне укып була? Ул китапларның тәрҗемәсе бардырмы, белмим. Ләкин тәрҗемә булган очракта да, ул гади итеп язылган булырга тиеш, зәгыйфь телле татарлар өчен. Катлаулы тел белән язылган китапларның укылуга шансы калмый. Урыслашкан балалар нишләп интегеп утырсыннар?

*Без бит - TikTok, Shorts (кыска видео) караучы, социаль челтәрләрдә актив эшләүче буын. Интернетта басылган язмаларга күз генә йөгертеп алабыз, озаклап карамыйбыз. Безнең игътибарны җәлеп итү өчен, нибары бер-ике секунд бар. Шул вакыт эчендә кызыксындыра алмасаң – карап та тормыйлар.*

Язылдым мин бернечә татар газетасына, ләкин бит алар кызык түгел! Балалар өчен чыккан басмада «лагерьга бардым, мәктәптә концерт үтте», дип язалар, балалар шигырьләрен бастыралар. Башка балаларга кызыкмы аны укырга? Шигырь, триггер булса гына, кызык, аны укыганда сиңа каз тәннәре чыга икән, ул сиңа кагыла икән, миндә дә бит шул булды, мин дә шуны кичердем, диярлек була икән, ул кызык. Журнал, газеталар берничек тә социаль челтәрләр белән конкуренцияне күтәрә алмый.

## Ике телдә язу кирәк

– Китап укыгач, фотосын статуска куям. Ошамаса – «Вакыт әрәм итмәгез. Не тратьте время», ошаса – «Киңәш итәм. Рекомендую», дим. Ике телдә язу кирәк, – дип ассызыклый Алия Ганиева. – Кыска-кыска җөмләләр белән булса да, язсаң – күрәләр, истә кала. Мәгълүматны да ике телдә бирү кирәк. Этикеткаларны ике телдә язу бик авыр, мәшәкатьле, вакытны күп ала, кайчагында сүзләрен дә белеп бетермисең. Мәсәлән, «петрушка» – ничек була әле ул татарча, тиз генә искә төшми бит. СММ-белгечнең дә ике телне камил белүчесе кирәк. Рус телен бик яхшы белүче ярдәмчем бар иде, ләкин ул татарча белми, тәрҗемә итә алмый, миннән сорый. Ә бизнес алып барганда, һәр минут, һәр секунд санаулы.

Статусларны татарча чыгара башлагач, кайбер клиентларым: «Алия, мы не понимаем, нам же тоже интересно», - дип әйтә башладылар. Баштарак, аңламасалар, татарчаны өйрәнсеннәр, диясе килде дә, ә бит икенче яктан, мин аудиториямне югалтам. Минем аккаунтыма язылган кешеләр – минем клиентларым. Әгәр мин сатмасам, эшем туктый, ризыкларым әрәм булса, бозылса, мин минуска китәм. Рус телендә генә сөйләшүчеләр дә аңламыйча чыгып китмәсеннәр, татарлар да, «бу бит әле миңа якын, кадерле, үз телемдә алып барыла торган аккаунт», дип карасыннар. Татарча сөйләргә тырышам, русчага тәрҗемә итәм. Үземне күрсәтү, үз фикеремне белдерү әле күптән түгел генә башланды. Ничектер оялып тора идем. Без, татарлар, гомумән, тыйнак халык. Кая кысыласың инде, дип үзебезне туктатабыз, булганга риза булып, үзеңне алга чыгармыйча яшәргә өйрәнгәнбез. Ныклап үземне белдерү соңгы бер-ике ел гына барадыр, чәкчәк ясарга тотынгач кына, эшемне күрсәтә башладым.



## Бер бардым – өйдек, икенче бардым – кабарттык

Чәкчәк пешерүгә Алия, кияүгә чыгып, балалары тугач кына тотынган. Аңа кадәр банкта эшләгән.

– Декреттан соң да банкка чыгармын, дип уйлаган идем. Эшкә чыксам, балаларны бакчага илтергә, алып кайтырга кирәк. Әнинең үз бизнесы, иремнең эше бар, ул командировкаларга еш йөри. Балаларны каршы алучы булыр әле, дип салынып кешем юк иде. Өйдә озак утырганлыктан, минем кешегә кирәкле, дәрәҗәле буласым, акча табасым килде. Башта үзем өчен тортлар пешердем, тора-бара танышлар заказ ясый башлады. Әниемнең апасы Гөлназ – чәкчәк пешерүче. Бер көнне ул миңа: «Заказлар күп, клиентларны кире бордым, җитешмим. Килеп ярдәм итә аласыңмы?» - диде. Бер бардым – өйдек, икенче бардым – кабарттык. Өйгә кайттым да, бүген үзем чәкчәк пешерәм, дип тотындым. Шкафны ачсам – тишекле чүмечем да юк, маем да әз калган. Икенче көнне май, чүмеч алдым, беренче чыгымнарым шул булды. Кәбестә тозлый торган таз бар иде, шунда пешердем. Тортка килгән кешеләргә кучтәнәч итеп чәкчәк җибәрдем. Заказлар ясый башладылар. Заказ бар икән – аны үтәргә кирәк. Моны шанс буларак кабул иттем, – дип сөйли Алия. - Чәкчәк пешерә башлаганда балаларны әнигә калдыра идем. Мин - бик җаваплы кеше, үз өстемә алганны ничек тә булса башкарып чыгам, төнлә булса да эшлим. Балалар да күнекте: заказ бар икән – миңа комачауларга ярамый. Чәкчәкнең бит тагын бер ягы бар – май белән эшлисең, ул чәчри, балалар пешмәсен, дип куркасың. Ә ясагач, кәеф күтәрелә, тәмле булды, дисәләр, тагын да күңеллерәк, канатлар үсә. Акчасы дә кирә. Әкренләп җыйган акчага камыр изгәч, башка кирәк-ярак алдым.

Ике ел элек яңа урынга күчендек. Бер хәләл кафе ябыла, дигән игълан күрдем, шуннан кирәкле җиһазларны алдым. Мин әле дә ул



кешеләргә рәхмәтле. Гаражда бер иске, пәрәвезгә батып беткән духовка ята иде. «Ал, бәлки, чәкчәк пешерерсең», – диде ирем. Очсызга гына алдык, чистарттык, әлхәмдүлилләһ, шуңарда ике елдан артык чәкчәк пешерәбез.

Яңа урынга күченгәч, ничек тотынырга, нәрсәдән башларга белмәдем. Өйдә газда пешердем, ә монда газ юк. Плитә дә, электр таба да алдым. Тегесен, монысын эшләп карыйм – яна, көя, шиңә, килеп чыкмый. Аннан менә шул духовкага җайланып киттем. Беренче айларда бик борчылдым. Мин бит технолог түгел, сораулар күп булды. Соңыннан җиһазны сатып алган абыйга шалтыраттым. Аларның кафелары пандемия вакытында ябылган иде. «Карагыз әле, юри генә алган әйберләрегез белән ничәнче ел эшлим, үсәм», - дидем. Хәзер дә мин даими рәвештә нәрсә булса да алып торам, алыштырам.

## Талкыш ясау үрелеп җитмәстәй биеклектә иде

- Чәкчәктан аермалы буларак, талкыш кәләвә татар халкының элеккедән килгән ризыгы түгел. Казан татарлары аны XIX гасыр ахырында гына ясый башлаган, - ди Алия. 1877 - 1878 еллардагы рус-төрек сугышыннан соң Борһан Сәйфуллин исемле кеше талкыш рецептын Казанга алып кайткан. Сәйфуллинар гаиләсе бу тәм-томны заказга әзерли башлаганнар. Эшне Борһанның уллары һәм кызы Фаһирә дәвам иткән. «Татар халык ашлары» авторы Юныс Әхмәтҗанов, Фаһирә Сәйфуллина белән очрашып, талкышның рецептын язып калган. Шуннан соң бу татлы ризыкны башкалар да ясый башлаган.

Талкыш кәләвәне, күрәсең, Казанның бай кешеләре өчен генә әзерләгәннәр. Ясавы бик катлаулы. Талкыш ясарга тиешле көнне мин бик дулкынланам. Белмим – чыгармы, юкмы. Ясаган саен куркып торабыз, чөнки бөтен әйберне граммына кадәр үлчәп, ничәдер градуска кадәр җылытып (үзебез ясый-ясый таптык градусын да), өч санга хәтле төгәл итеп китерәбез.

Беренче тапкыр талкыш кәләвәсен ясап карарга миңа Гөлназ апа тәкъдим итте. Ул чакта минем өчен талкыш ясау үрелеп җитмәстәй биеклектә иде. Ә безнең күршедәге килен Юныс Әхмәтҗановның ярдәмчесе булган. 70нче елларда Коръән ашын үткәрергә кунакка кайткан, малае белән бергә талкыш сузганнар, минем апага да ашатканнар. Гөлназ апа әле дә: «Синең талкышың дөрес түгел, аларныкы тәмлерәк иде», - ди.

Ясап карарга булдык. Гөлназ апаның пешекчелеккә укыган малае белән өчебез эшкә тотындык. Рецептны Ю. Әхмәтҗанов китабыннан, интернеттан роликлар карап өйрәндек. Суздык, пешердек. Нәрсәдер килеп чыкты инде, мин аны 100 процентлы талкыш, димәс идем. Гөлназ апага: «Мин моны бүтән ясамыйм», - дидем. Ә, шулай да, өйрәнәсе килә бит!

Өйдә декретта утырган вакытым, энергиям күп, вакыт бар. Чәкчәк ясыйм да, вакыт табып, тагын талкыш сузып карыйм. Юк инде, чыкмый.

Очраклы рәвештә бер апа белән таныштым. Ул миңа Казанда талкыш пешерүче Гөлшат Шәрәфет-

динованың телефонын бирде. Мастер-класска бардым. Шуннан соң хатасыз эшли башладым. Ләкин әле дә чыкмый калган чаклар бар. Монда бит әле чимал, коллективтагы микроклимат, кәеф, кул җитезлеге – барысы да тәэсир итә. Ничек тотасың, ничек кулыңны борасың, кешенең буеннан да, кулыннан да тора. Мин сузам, аннан ярдәмчем Альбина белән басабыз, парлап эшлибез. Физик көч кирәк. Тиз-тиз эшләргә, өстәлдә озак тотмаска. Юк кына, вак кына әйбер дә тәэсир итә. Чәкчәк ясаганда



да бар нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Камыр кискәндә һәр кисәген бераз этеп җибәрсәң, авызы ябылып кала, этми калсаң – ачыла. Шулкадәр вак әйберләр, ә ахырда төш матур, өяргә җайлы була.

## Камыр кәефне сизә

– Нәрсәсе бар инде ул халык ашларын пешерүнең, диючеләр бар. Әйе, милли ризыклар гап-гади, барысы да бездә үстерелә торган, бездә җитештерелә торган чималдан эшләнә. Әллә нинди катлаулы җиһаз кирәк түгел. Ләкин нечкәлекләрне күздә тотарга кирәк, – дип аңлата пешекче. – Миңа да яңа кеше килә, мин беләм, дип тотына. Карыйм да: болай ярамый бит, мондый төш дөрес түгел, дим. Син бигрәк бәйләнәсең, диләр. Ә башкача ярамый. Безнең стандартлар бар, минем чәкчәгем шундый булырга тиеш.

*Камыр кәефне сизә, ул аны сеңдереп ала. Әйбәт кәеф белән башламасаң, чәкчәк килеп чыкмый.*

Минем алай булганы бар. Бар нәрсә туры килә, әмма нишләптер уңмый. Ашарга пешергәндә кухняда, коллективта уңай мохит булырга тиеш. Син кулыңны сузганчы, икенче кеше инде тартып алырдай торсын, күз карашыннан аңлап эшләргә кирәк. Минем кызлар рәхәт итеп, шыкы-шыкы көлеп эшли.

Бизнесны үстерәсе килә. Бөтен кешедә бар бит инде ул нәфес. Кайчагында уйланып куям: бу миңа кирәкме соң? Булган урынында булган кешеләрең белән эшлә инде тыныч кына. Ә без, яшәгән фатирыбызны сатып, яңа бина алдык, шунда ремонт ясыйбыз хәзер. Ул бинага керергә күпме чыгым таләп ителә, күчкәч тә, эшен җайларга кирәк бит әле.

## Курку белү юк

Идеялар күп, көннең кыска булуы комачаулый, – дип уртаклаша язмам герое. – Ел ярым элек ярдәмчем барлыкка килде. Яңа ел алдыннан заказлар күп булды. Бәйрәмнәр үтте, эш тынды. Пилмән ясап карыйсы килде – ясадык. Чәкчәк алырга килгән кешеләргә: «Карагыз, пилмән ясадык», - дим. «Бир, Алия, синеке начар булмас», - дип алып китәләр. Кайбер клиентлар, аңлатканны тыңлап та тормыйча, сатып алалар. Котлет ясаганда озак өйрәндек. Башта үзлектән тырыштык, аннан белгечләрне чакырдык. Котлетны өйдә пешерә идем, ләкин өйдә пешергән белән производствода пешерү аерыла. Өйдә өйрәнгән табаң бар, белгән күләм белән эш итәсең. Күпләп ясаганда табасы да зур, уңмаган чаклар да була. «Самонадеянность и отвага», диләр бит. Миндә дә шулай. Курку белү юк һәм үз көчемә ышану бар. «Әйдәгез, каз пешереп карыйк», - дидем кызларга. Алар: «Юк, Алия, булмас, пешмәс ул», - диләр. «Сез бит талкыш сузган хатыннар, каз пешерергә куркып торасызмы? Башкалар пешерә, аларның да ике кулы, ике аягы. Без алардан нишләп ким булырга тиеш?» – дип җавап бирәм.

Сыйфатны, чималны көн саен күзәтеп торырга кирәк, бүген эшләдем дә оныттым, дип булмый. Бөтен кеше дә тәмле пешерә, тәмсез пешерүчеләр юк. Чөнки клиент сайланып кына ала. Үземнең ашказаным бик сизгер, спред, көнбагыш мае кушып ясалган камыр ризыкларын ашасам – чирлим. Ә минем клиентларым чирләргә тиеш түгел. Камыр ризыгы, гомумән, чирләтергә тиеш түгел. Татар халык ризыклары авыр. Чәкчәк майда кыздырыла, өчпочмакта ит, бәрәңге, камыр. Безнең камырларыбыз акмайга, каймакка гына басыла, анда пальма мае, үсемлек мае, трансжирлар юк. Чиста ризык, барысы да хәләл.

Сыйфатны югары дәрәҗәдә саклар өчен, кайбер кешеләр белән аерылырга туры килде. Язгы айларда гына өч кешене өйрәттек, өчесен дә озаттык. Яңа кеше табуы авыр. Кухня кешесе бик җитез булырга тиеш, бер әйберен куйды, икенчесенә тотынды, тиз-тиз җәя, кисә.

## Балансны саклау

Эшмәкәр хатын-кызга иренә дә, балаларына да игътибар-назны тиешенчә бирүе җиңел түгелдер. Алия әйтүенчә, гаилә белән бизнес арасында балансны сакларга кирәк.

– Ирем каршы килми. Ләкин шуны да әйтергә кирәк: мин 8 ел өйдә утырдым. Чиста, ашарга пешерелгән, балалар каралган, кайтып керергә рәхәт. Ә хәзер, әлбәттә, ниндидер уңайсызлыклар туа башлады. Эшли башлаганда максат – балансны табарга. Бәлки, ышанмассыз, ләкин мин көне буе эшләмим, сәгать икегә-өчкә кадәр генә. Эшем бар, йөз эшем йөзгә ярылып кала, эшләп бетерәсе килә, ләкин мин туктыйм да чыгып китәм, – дип сөйли Алия. – Балаларны каршылыйм, шул арада

нидер алам, заказларны кертәм. Баланс менә шулай саклана. Туган көннәрендә балалар белән калам, бик сирәк очракта гына аларны әнигә, иремә калдырам. Кайбер хатыннар, бала тапкач, «мин житешмим», диләр. Мин моны аңламыйм. Аш кайнатырга нәрсә кирәк? Алдан тәвәкәлләргә һәм вакытында газны кушып җибәрергә. Ашыңны куясың, токмач әзерлисең – ашарга әзер.

Балаларына да тиешле тәрбия бирергә тырыша Алия. Туган тел-



не саклау, милли үзаңны үстерү гаиләдән башлана, дигән фикердә ул.

– Үземне гел контрольдә тотам, балалар белән сөйләшкәндә рус сүзләрен кулланмаска тырышам. Алардан да шуны таләп итәм. Татарча сүз кулланып була икән, төзәтәм, әйтеп куям. Белеп, ишетеп торсыннар. Балалар бакчасында татар төркемнәренә йөрделәр. Ул төркемнәрнең исеме генә татар инде. Татарча белмәгән балалар киләләр, һәм тәрбиячеләр кыен хәлдә кала. Кемдер русча сөйләшкән баланы алып килә, ә минем бала татарча гына сөйләшә. Татар мохите булдырырдай балалар бакчасы бик сирәк. Ярар, төркем татарча, ди, ә башкалар бит русча сөйләшә. Шәфкать туташы, музыка житәкчесе, психолог – барысы да рус телендә аралаша. Кызым татар гимназиясендә укый. Улым – шәхси мәктәптә, анда инглиз, кытай телләре бар, ә татар теле юк. Татар телен үзләштерсен өчен, без баланы мәктәптән соң татар теле һәм әдәбияты укытучысы янына йөртәбез.

## Әйтү авыр түгел, әйтмәү авыр

– Без рус мохитендә яшибез, мин - русча укыган кеше, яшеренәсе түгел, телебез артта калган, –дигән фикердә Алия ханым. - Милли университет юк, техник гыйлем рус телендә үсә, ә татар теле үсешләр артыннан житешми. Никадәр генә тырышсаң да, никадәр теләсәң дә, гел татарча гына сөйләшеп булмый. Беркөнне Печән базарыннан алып кайткан татарча сүзлекләрне карап утырдым. Андагы сүзләрнең күбесен мин белеп тә бетермим, Тукай заманындагы сүзләр.

Кайберәүләр никтер русча сөйләшергә тырыша. Бу безнең канга сеңгән. Хәзер дә күрәм: олы яшьтәге апалар минем балаларым белән русча сөйләшә. Үземнән өлкәнрәк кешегә кисәтү ясау кыен, түзеп утырам инде. Каян килгән? Нәрсәдер бар безнең милләттә, ул безнең күңелдә, тирәндә утыра –татар булуыңнан оялу, үз телеңнән тыелу. Аналар нигә балалары белән русча сөйләшәләр? Үз балаң белән русча сөйләшсәң, ул рус булып үсәчәк. Нишләп аңламыйлар, сизмиләр, югалтабыз бит телебезне.

Татар булуың белән горурлану юк. Мәктәптә рус тарихын нечә ел өйрәнәбез. Ә татар тарихын? Бер-ике чирек. Һәм без шуңа риза. Беркем бернәрсә дә әйтми, без шуңа күнеккәнбез.

*Урамда берәр кешене туктатып сорасак, өч рус патшасының исемнәрен ата, дип. Исемен дә әйтәчәк, әһәмиятле эшләрен дә. Ә татар ханнарының исемнәрен беләләрме? Бәлки, ислам динен кабул иткән Алмыш ханны әйтерләр. Без үз тарихыбызны якынча да белмибез.*

Татар университеты дигән платформа ничектер күзәмә чалынды. Татар яшьләре, университет активистлары оештырган. Ике ел элек мин анда регистрация үттем һәм үземә татар тарихына багышланган курс сайладым. Анда модуль буенча укыту бара. Университетның атаклы галимнәре сөйли. Үзем генә эшләгәндә колакчын тыгам да тыңлыйм. Шулай бернечә модуль үттем. Казан ханлыгына барып җиткәч, туктап калдым. Шул платформада эшләүчеләргә дә ярдәм кирәк. Цифровизация - кыйммәтле әйбер. Сайтка керергә, парольне кертергә кирәк. Кергән саен модуль каядыр югалган була, эзлисең. Вакыт күп үтә. А телефоннан керердәй кушымта булса, бастың – туктаган җиреңнән тыңлыйсың. Мин аны вакыт булган саен 10-15 минут булса да тыңлар идем. Төрле темалар бар, ләкин бу платформа турында белүче юк. Андый активистларга финанс ярдәме күрсәтергә кирәк. Һәр баланың телефонында ул йөкләмә булырга тиеш.

Якутлар да зур халык түгел. Алар хәзер кино төшерә, ул фильмнарны кешеләр карый. Телне, миллилекне күрәләр. Татарча сериаллар кирәк. Татарча булмаса, Бразилия сериалларын тәрҗемә итеп күрсәтсеннәр иде. Карамасаң да, колакка кереп кала бит. Мультфильм төшерегез. Контент кирәк.

Рус балаларына татар теле чиксез авыр. Нәрсәгә аларга килешләрне ятлатырга? Өйрәнсеннәр гади җөмләләр белән сөйләшергә, аңларга. Мультфильм күрсәтеп, уйнатып, җырлатып өйрәтсеннәр иде балаларны. Һәр кешенең үзеннән генә тора. Без бит таләп тә итмибез, сорый да, әйтә дә белмибез, без шулхәтле толерант... Холкыбыз, табигатебез шундый. Без сугышчылар түгел, игенчеләр. Безгә азмы-күпме үзебезнең фикерне әйтә белергә кирәк. Бәлки, ишетерләр, шул ук тарихны өйрәнүгә игътибар бирерләр.

Мин милләтче түгел, татарлар башка халыклардан өстен, димим.

Ләкин без дә төшеп калганнардан түгел. Без дә шул ук хокукларга ия. Без дә үз телебездә сөйләшә алабыз. Нишләп бездә курку бар?

Бер мисал. Улымны татарча сөйләшкән өчен үртәделәр. Ничек шулай булырга мөмкин? Татарстанда, үз җиребездә синең татарлыгыңнан дусларың көлсен. Гомумән, башка телләрдән көләргә ярамый. Бу бит - коточкыч хәл. Ә мин нәрсә эшләдем? Бармадым, туздырып кайтмадым. Ярар инде, дибез. Минем апа да: «Әйтү авыр түгел, әйтмәү авыр», - ди. Ә, бәлки, кайчак әйтергә кирәктер. Кешене рәнҗетергә ярамый, дибез. Ә үзеңне рәнҗеттерергә ярыймы?

Сүз үзең турында гына түгел, гомумән, милләтнең киләчәге турында. Без әйтмибез, балалары белән русча сөйләшкән ата-аналар аңламыйлар. Ә кем әйтергә тиеш алайса? Аны уйламыйбыз.

Татар зыялылары да юк дәрәҗәсендә. Каядыр университетта утыралар инде алар, тел белгечләре бар, язучылар. Ә күпчелегебез - урысчалы-татарчалы, ипилек-тозлык кына кухня телендә сөйләшүчеләр.

## Зыялы блогерлар бар

Кайбер блогерлар матур, дөрес итеп татарча сөйләшә, яшьләрнең игътибарын җәлеп итә ала, дип билгеләде Алия Ганиева. – Бар нәрсә дә нәтиҗә бирергә тиеш. Мин, эшмәкәр буларак, саныйм: күпме чыкты, күпме керде. 0 яки минуска чыга икән, эшеңнең мәгънәсе юк. Син эшләгән әйберне алмыйлар, димәк, ул кызык түгел, кирәк түгел. Мәсәлән, бездә кыстыбый, пилмән яраталар. Ә мин аның урынына коймак яисә гөмбә пешерәм дә кеше килеп алганын көтеп торам. Ризык ята, алучы юк. Ә мин пешерәм дә пешерәм. Складларымда өелеп ята, кеше алмый...

Матбугат чаралары укылмый, кызык түгел икән, нәрсәдер үзгәртергә кирәк. Кайбер газеталар үз блогларын алып баралар, бу - дөрес юнәлеш, дип саныйм. Электрон форма заманасы икән, шуңа яраклашырга кирәк.

Минем әни бөтен татар блогерларын карый. Һәрберсе турында кайсы районнан, ире кайдан, нәрсә эшлиләр - барысын да сөйләп бирә. Сериал караган сыман карыйлар. Башкалар ничек яшәгәнне карап торуы кызык. Урамнан үткәндә дә кухня тәрәзәсен әләктереп аласы килә бит. Безнең блогерлар, мин шундый кием алдым, шундый аш пешердем, дип сөйлиләр. Кайберсе эчке күлмәктән генә йөри, бөтен тормышын күрсәтә. Миңа кайчак карарга да уңайсыз. Кайда соң сезнең театрга барганыгыз? Нигә ул эмоцияләр белән уртаклашмыйсыз? Кайда сезнең яңа китап алып укыганыгыз? Нинди файдалы эш эшлисез? Ниндидер зыялылык җитми. Зыялы блогерлар күп түгел, ләкин бар. Кайберләрен сокланып укыйм, менә бит, ничек мавыктыргыч итеп язган, ничек дөрес әйтә, дип.



Матур итеп татарча сөйли торган блогерлар бар, мин аларның барысына язылган. Кайбер журналистларны кызыксынып карыйм, мәсәлән, Рәмис Латыйпов, Альберт Шакиров. Алар бик сирәк, ләкин озын, кызыклы итеп язалар.

Юморга килгәндә, аракы эчкән кешедән, женси мөнәсәбәт белән бәйле мәсьәләләрдән һәм татарлыктан көлгәнне яратмыйм. Акцент ясап сөйләшкәннән көлүне яратмыйм. Кайбер блогерлар урысчалы-татарчалы сүз боткасы ясыйлар. Аларның да яшәргә хаклары бар, аларны да карыйлар. Ләкин, әз генә булса да, араларга, мәгънәле мәгълүматны сайларга кирәк. Без бит чипсы белән генә тукланмыйбыз, аш та ашарга кирәк.

## Кайтмыйбыз без авылга

Нинди юнәлешләрнең киләчәге бар? Татар телен ничек саклап була? Бу сорауларга Алиянең үз җаваплары бар.

– Китап кызык түгел, журналны укымыйлар, театрга йөриселәре килми. Шул блогерлар һәм стендап ярдәм итә алыр сыман. Татарча стендапның киләчәге бардыр. Кызык итеп сөйләсәләр, безне борчый торган темаларга чыгыш ясасалар. Кирәк түгел безгә авылга кайту, исерекләр кыланышы турында сөйләргә. Безгә ул якын түгел, хәзер яшьләр аракы эчми. Стендапта безне кызыксындырган темалар була икән, без дә зал тутырыр идек.

Татарча дискотекалар булсын, яшьләргә кызыклы җырлар яңгырасын.

*Күптән түгел татарча радио тыңладым. Өч сәгатьләп булгандыр, шул вакыт эчендә авылга кайтам темасына 4 - 5 җыр булды. Авылга кайтам, авылым миләшләре, авылым каеннары... Кызык түгел ул яшьләргә!*

Без шәһәрдә тудык. Кайтмыйбыз без авылга, сандугач сайраганын тыңламыйбыз. Кайтсак та, дөбер-шатыр музыка акыртып кайтабыз һәм шулай ук музыка акыртып китәбез. Салават абый, Хәния Фәрхи җырларын тыңлыйм мин. Чөнки аларны тыңлыйсың да, бу Салават абый, бу Хәния апа,

дисең, танып була. Ә хәзерге җырчыларның күбесендә үзенчәлек юк диярлек. Аларны ничек аералардыр?

Элек рок заманасы иде, ә хәзер рэп заманасы. Кая соң ул татарча рэп? Мин балаларга «Иттифак» группасын тыңлатам, без аны машинада да тыңлыйбыз, сүзләрен яттан беләбез. Җөмләләре кыска, сүзләре таныш. Яшь буынга шундый җырлар кирәк. Анда социаль тема да, мәхәббәт тә бар. «Gauga» дигән искиткеч рок-группа бар. Кая соң алар? Нишләп радиода уйнатмыйлар? Балалар рәхәтләнеп тыңлар иде.

Формат – не формат, дигән әйбер бар радиоларда. Яхшы, кемгәдер ярамый. Ә кая соң алайса икенче радиостанцияләр? Алар куйсыннар. Хөкүмәт ягыннан да ярдәм кирәктер, бәлки. Ярдәм итсеннәр берәр радиога. Яшьләр өчен программалар кирәк.

Проблема бит нәрсәдә? Без яшьләрне югалтабыз. 90нчы елларны туган буынны югалттык, 2000нче елларда туганнарны югалта барабыз. Хәзер 2010нчы елны туган балаларга да 13 яшь, аларны да югалтабыз бит!

Ә нәрсә белән аларны җәлеп итеп була? TikTok, стендап, социаль челтәрләр, рэп. Аларның бөтен белгәннәре шул.

## Алга бару бала үсү белән бер

– Киләчәктә милли үзәк булдыру хыялым бар. Туристлар килсә, безнең күрсәтер урын юк. Туристка бит карап кайту гына түгел, өйгә дә нәрсәдер алып кайтасы килә. Ашыйсы да килә. Читтән килгән кешегә бар нәрсә дә кызык. Без бәлешкә дә, чәкчәккә дә күнеккән. Мәсәлән, Вологда, Дагыстаннан килгән кунакларга талкыш сузганны, чәкчәк өеп күрсәтсәң, бәлеш пешереп ашатсаң, бик кызык булачак.

Ю. Әхмәтҗановның энисе оста пешекче булган, ул Казанда киленнәр клубын оештырган. Мин дә шул турыда уйлап йөрим. Яшь киленнәр өчен мастер-класслар үткәрәсем килә. Яңа гына тормышка чыккан кызлар итне дә ала белми, итнең кайсы урыны нинди ризыкка яраганын да белми. Мин аның программасын да уйладым инде. Мәсәлән, якшәмбе очрашабыз, ярты көн әзерлибез. Бер көн - аш, бер көн бәлеш, десертлар өйрәнәбез. Токмачны да басып күрсәтергә. Мин дә бит белеп тумадым. Беркем белеп тумый, тәҗрибә белән килә. Әзер тәҗрибә алсаң, үзең ясап карасаң, ул бит кызык. Шундый планнар бар.

Хәзер десертларның нинди төре генә юк! Әйтик, шомыртны тарттырып, төче камырдан урама ясасаң, ул каты, хәзерге десертларга конкурент була алмый. Кем өчендер ул ностальгия, ә минем балаларга ул кирәкми. Милли ризыкларны заманга яраклаштырырга кирәк. Балан бәлешен пешерәсе килә. Кош теле, тутырган тавык һәм башка ризыкларны әзерлисем килә. Онытылган рецептларны кайтарырга иде. Идеялар күп. Вакыт һәм энергия кирәк.

Минем көнем кыска. Бер ел эчендә ярымфабрикатларны күпләп ясый башладык. Аның бит упаковкасын, этикеткасын, чималын әзерләргә кирәк. Кайсы килеп чыга, кайсы юк. Кеше белән дә эшләргә кирәк, хатын-кызлар бит. Әле балалары чирли, әле тагын бер сәбәп. Берсе чыкмаса, үзем басам, пешерәм, савыт юам. Ашыгасы түгел, үз җаең белән барырга кирәк. Алга бару  бала үсү белән бер бит ул. Бала кисәк кенә үсеп китсә, аның тәне сузыла, тешләре авырта. Әз-әзләп алга барабыз. Үсәбез, әкренләп җайланабыз, – ди Алия Ганиева.

## Чәкчәк рецепты

Чәкчәк пешерер өчен, йомырканы бер-ике атна суыкта катырырга кирәк. Ясар алдыннан аласыз, җебетәсез, миксер белән туглыйсыз. Миксер белән бер ярты сәгать куе күбек күтәрелгәнче болгатырга кирәк. 15 йомыркага өч чеметем сода саласыз, иләнгән иң яхшы сыйфатлы он сала башлыйбыз.

Миксер болгатмый башлагач, озынрак агач калак белән болгатасыз. Кулыгыз өзелеп төшә инде, дигәндә, туктасагыз була.

Озак итеп, камыр язылганчы тугларга кирәк. Камыр коймакныкыннан әз генә катырак булырга тиеш. Камырны кулга алып булмый, ул йомшак.

Шул камырны онлаган тактага калак белән кистереп төшерергә кирәк. Өстенә он сибәсез. Һәм шуны әкрен генә тәгәрәтәсез.

Камыр йомшак, шуңа онны күбрәк салырга кирәк. Төшләргә кисәсез, майга салып кыздырасыз.

Май сыйфатлы булсын, ат мае кушсагыз, чәкчәкнең тышы кетердәп торачак.

Сиропны үзегезгә ничек ошый, шулай ясагыз. Бал күбрәк булса,



йомшаграк була. Бергә бер шикәр һәм бал салырга була, әз генә 100-200 грамм су өстәгез, сироп кайнаганда савытның төбенә ябышмасын өчен.

15 йомыркага сироп - 500 грамм шикәр, 500 грамм балл.

Сиропны озак кайнатсагыз, чәкчәк катырак була, кызу көннәрдә ерак юлга алып барырга ярый.

Йомшак кына, әз генә кайнатсагыз, ул ашарга тәмлерәк, төш эченә дә ныграк үтеп керә, ләкин чәкчәк таралып китәргә мөмкин, кызуда ерак юлга алып барып булмый, ә кышка яхшы.



# ХАТЫН-КЫЗ – УЛ МИЛЛӘТ АНАСЫ

***Без үскәндә Татарстан телевидениесеннән бөек татар халкының тарихын, язмышын сурәтләгән "Зәңгәр шәл", "Галиябану" һәм башка күптөрле спектакльләрне рәхәтләнеп карарга була иде. Дөрес, шәһәр театрларындагы зур сәхнәләрдә алар әле дә күрсәтелә. Ә бүген телевидениедә, заман таләпләренә карата, хәзерге тормышны чагылдырган спектакльләргә күбрәк урын бирелә, дип әйтер идем.***

***Нурсинә Хәкимова***

Хәер, ни өчен мин тарих битләрендә мәңге җуелмас шушы спектакльләрне исемә төшердем соң әле? Чөнки аларда татар хатын-кызының матур образы, күркәм гадәтләре, сыйфатлары белән бергә киемнәре дә зур урын алып тора иде.

Кызганычка, тора-бара бала итәкле күлмәкләр, чулпы таккан чәч толымнары, чигүле калфак өстеннән ябынган ефәк шәлләр юкка чыкты. Һәм хәзер, урамга чыккач, каршыңа ярым шәрә хатын-кыз килүен күргәч, әллә ни эшләп китәсең. Дөрес, үз теләкләре белән, башына яулык ябып, озын җиңле, озын итәкле күлмәк киеп йөрүче туташ-ханымнар да юк түгел. Мондый хатын-кызларның йөзләрендә аерым бер сөйкемлелек чагыла!

Яза башлагач, тагын бер нәрсә исемә төште: бер авылга баргач, миңа берничә мәртәбә бер гаилә белән аралашырга туры килде. Аларның кызлары, дингә бирелеп, хиҗап формасындагы киемнәр киеп йөри иде. Ә инде тагын бер баруымда шушы кызның әти-әнисе, олы абыйлары алдында ярым чишенеп, яланбаш йөрүен күрдем. Мин аны башта танымый да тордым. Бәлки, бу икейөзлелеккә керәдер?! Безгә күбрәк күңел сафлыгы, пакьлеге җитеп бетми торгандыр шул.

Ерак көнчыгыш илләреннән сатып алынган фильмнар белән дә бик күп үзгәрешләр килеп керде илебезгә. Мәсәлән, кендек күрсәтү, шәрә ботлар, ачык күкрәкләр, бер кулына - тәмәке, икенчесенә сыра шешәсе тотып, урамда эчеп йөрүләр.

Сүз дә юк, кайбер ир-атлар ярым шәрә йөргән кызларга кызыгып карыйлар. Әмма кайчак бу аянычлы хәлләргә китерергә дә мөмкин икән шул.

- Бервакыт рульдә барганда, ярым чишенгән бер гүзәл кызны күргәч, түзә алмыйча, аңа карадым һәм ирексездән авария ясый яздым, - дип сөйләгән иде миңа бер ир-ат.

Шушы сүзләрне язгач, яшь чагымда әбием миңа биргән киңәшләр исемә төште.

Ул безгә:

- Кызым, өсте ябылган ризыкны ашарга хәерлерәк, җирәндерми ул. Акыллы егетләр дә тыйнак итеп киенеп йөрүче, тәртипле кызларга кызыгалар, - дия иде.

Дөрестән дә, безнең чор кызлары берсе дә ирсез калмады, гаилә корып, менә дигән яшәделәр, тәртипле балалар үстерделәр. Ә кендек күрсәтеп, ярым шәрә йөрүче кызлар арасында ана булу бәхетеннән мәхрүм булганнары да бар. Чөнки куз дә, салкын тию дә ихтималы бар.

Хатын-кыз – ул милләт анасы, җир йөзендә нәсел калдыручы кеше. Бәлки, безгә чит мәмләкәтләрдә яшәүчеләрдәй киенгәнче, чын татар хатын-кызларына хас булган тыйнак киемнәрдән йөреп, матур гаиләләр корып, динебезне,



телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне дәвам итүче балалар тәрбияләп үстерү турында уйлый башларга вакыт җиткәндер?! Соңыннан үкенечкә калмасын иде...

# «МАКСАТЫМ - ИХЛАСТАН ТУГАН ҖИРЕМӘ ХЕЗМӘТ ИТҮ»

***Авылларның төзеклеге, матурлыгы, үсеше, биредә кешеләрнең бүгенге яшәеше һәм киләчәк тормышы җитәкчедән тора.***

*Нурсинә Хәкимова*

Шенталы районындагы Денис авылына яңа җитәкче килде. Ринат Әкрәм улы Хәлиуллинның туган авылы тормышына күз карашы нииндирәк, һәм ул үз алдына нинди максатлар куя икән, дигән сорауларыма җавап эзләп, аның белән сөйләшеп алырга булдым.

***- Ринат әфәнде, балачак һәм үсмер елларыгыз белән таныштырып үтсәгез иде.***

- Балачак елларым, башка авыл малайларыныкы кебек үк, бик гади үтте. Мин дә иптәшләрем белән туп типтем, елгада су коендым. Әтием колхозда агроном булып эшләгәндә, мин басуларда йөри, табигатебезнең матурлыгына соклана идем. Ул машина-трактор паркында бригадир булып хезмәт иткәндә, техникага гашыйк булдым. Бераз үсә төшкәч, чират көтүен көтештем, йорт хуҗалыгында булыштым.

Урта мәктәпне тәмамлагач, Самар дәүләт техник университетына укырга кердем. Биредә техник-коммерсант һөнәренең бөтен нечкәлекләренә төшендем.

Уку йортын уңышлы гына тәмамлагач, туган авылыма кайттым һәм үз эшемне ачып җибәрдем.

***- Авыл җитәкчесе булып эшләү теләге кайчан туды? Сезне биредә нинди уй-хыяллар һәм максатлар тартып китерде?***

- Югары уку йортын тәмамлап, авылга кайткач, бер автобус сатып алдым. Күпмедер вакыттан соң, эшемне киңәйтергә теләп, тагын берничә автобус алдым. Кешеләрне шәһәргә йөртә башлагач, шуңа игътибар иттем – һәр авыл саен әти-әниләр шәһәрдә укыган балаларына, зур сумкаларга тутырып, азык-төлек җибәрәләр иде. Нәкъ шушы вакытта авылның шәһәр халкын туендыруын аңладым. Шулай ук мине тирә-юнебездәге авылларның әкрен генә таркалып баруы борчый иде. Туып-үскән авылыбызның җир йөзеннән юкка чыгуын теләмәдем.

Биредә бер ел сынау срогын үттем. Алдагы җитәкчебез - Лимуза апа Бикмөхәммәтованың урынбасары булып эшләдем. Ул мине шушы вазыйфаның бөтен нечкәлекләренә өйрәтте. Аның сабырлыгына, таләпчәнлегенә, үз эше-



нең остасы булуына соклана идем.

Максатым - ихластан туган җиремә хезмәт итү, халкыма игелек кылу, яшьләргә эш урыннары булдыру, мәктәпләребезне яшәтү.

***- Хезмәткәрләрегез турында да әйтеп үтсәгез иде.***

- Бездә барлыгы дүрт кеше эшли. Гүзәлия Ногманова – минем урынбасарым. Рәфкать Мостафин – машина йөртүче. Зөлфия Абдулхәлимова – торак-коммуналь хуҗалыгы хисапчысы. Гөлфирә Хәннанова – спорт һәм хәрби эшләр бүлеге хезмәткәре.

***- Авылда нинди учреждениеләр эшләп килә?***



- Аллаһыга шөкер, ике мәчетебез бар.

Унберъеллык мәктәп эшләп килә. Биредә 56 укучыга унбиш югары квалификацияле укытучы белем бирә. Быел дүрт укучы мәктәпне тәмамлый. Ә беренче сыйныфта сигез бала белем алачак.

Балалар бакчасы булуы да шатландыра.

Табиб офисы эшли, ашыгыч ярдәм машинасы бар. Офис белән Рәсилә Галәветдинова җитәкчелек итә. Халисә Шәрәпова да, көн, дими, төн, дими, гел авыруларга ярдәмгә ашкына. Зөлфия Шәйхетдинованың уңганлыгы аркасында офиста чисталык, тәртип хөкем сөрә.

Почта эшләп тора. Аның белән Алия Әхмәтвәлиева җитәкчелек итә. Зөлфия Нуретдинова, Әлфия Минһаҗева, Елена Пенькова авыл кешеләренә газета-журналларны вакытында китереп бирәләр, ай саен коммуналь-торак хезмәтләренә түләүләр кабул итәләр.

Авылда шулай ук бер кибет, янгын сүндерү бүлеге эшли. Андый-мондый хәл була калса, дип, һәрчак әзер булган янгын сүндерү машинасы басып тора. Монда Наил Сөнгатуллин, Наил Хәертдинов һәм Хәлил Гөбәйдуллин эшлиләр.

Коммуналь-торак хуҗалыгында Фәнил Имаметдинов белән Рөстәм Төхвәтуллин хезмәт итәләр.

Авыл уртасында, ял итәр, рәхәтләнеп китап укыр өчен, китапханә һәм зур спорт залы булган Мәдәният йорты бар.

Картларга һәм ярдәмгә мохтаҗ булучыларга булышу өчен, социаль үзәк эшләп килә.

***- Ринат әфәнде, җирләр эшкәртеләме соң?***

- Шөкер, җирләребезне чүп үләннәре басып китмәгән. Берничә елдан бирле күрше “Карабикол” җәмгыяте һәм “Био-Тон” авыл хуҗалыгы компаниясе, кешеләрнең җир пайларын арендага алып, икмәк үстерәләр. Ә көзен халыкны ашлык белән тәэмин итәләр.

Терлек асраучыларыбыз да җитәрлек . Әйтик, озак еллар җир эшкәртеп, икмәк үстергән Фәрит Мөстәкыймов бүгенге көндә күп итеп терлек тота һәм алар өчен үзе азык чәчеп үстерә.

Шулай итеп, пенсионерларыбыз да тик ятмый, күп итеп кош-корт, кәҗәләр асрыйлар.

***- Шатлыкка, авылда яшьләр да юк түгел. Алар ни белән шөгыльләнәләр?***

- Авылыбызда яшәп калучы яшьләрнең туксан җиде проценты Себердә һәм Татарстанда нефть чыгару өлкәсендә эшлиләр. Ә хатын-кызларыбыз Канаш авылында кондитер эшен башкаралар, социаль үзәктә хезмәт итәләр. Кайсылары район үзәгендә урнашкан хастаханәдә эшли.

Тырышкач, авылыбызда өр-яңа өйләр калкып чыга. Йорт саен яхшы машиналар, өйләргә капиталь ремонт ясалган, кыскасы, халык бездә матур яши, Аллаһыга шөкер.

Шенталы район үзәген җитәкләүче Александр Михайлович Лемаевка рәхмәтебез чиксез. Ул - бик яхшы җитәкче, аның белән һәрвакыт уртак тел табып була, ярдәмен кызганмый.

Ничек кенә булса да, яшьләрне җиргә тартасы иде дә бит. Әгәр авылыбызда эш булса, алар чит җирләрдә йөрмәсләр, газиз туган якларында тормыш итәрләр иде, дип уйлыйм.

***- Тагынниләр белән шөгыльләнәсез?***

- Хезмәт һәм сугыш ветераннарының тол калган хәләл җефетләренең хәлен беләбез, үзләренә ярдәм итәргә тырышабыз. Бәйрәм көннәрендә, юбилейларында күчтәнәчләр, бүләкләр тапшырабыз.

Ә авыл тормышына килгәндә, күптән түгел кар чистартыр, юлларны тигезләр өчен, тракторга көрәк, басуларны чүп үләннәреннән арындырыр өчен, чапкыч сатып алдык.

Экскаватор бик кирәк иде. Аны сатып алыр өчен, авылдашлар, үзләре теләп, акча җыя башладылар, читтә яшәүчеләре дә булыша. Барысына да мең рәхмәт!

Ринат әфәнде хатыны Эльвира белән матур тормыш алып баралар. Салават һәм Илһам исемле уллары бар. Әниләре - Асия апа да балаларыннан бик канәгать, ул яраткан оныкларын тәрбияләшә. Эльвира ханым да тик ятмый, иренең бизнесын алып бара.

- Улларыбызга яраткан җырчыларыбызның исемнәрен кушарга булдык. Алар да җырларга бик яраталар, - дип елмая Ринат Әкрәм улы.

Тырыш, җаваплы, киң күңелле Ринат Хәлиуллин Денис авылы халкына ныклы таяныч булыр, дип ышанам.

Без аңа авыр, мәшәкатьле хезмәтендә түземлек, шәхси тормышында гаилә бәхете теләп калабыз.

***Хәзерге көндә яшьләрнең күбесе шәһәр тормышына кызыга. Авыллар бушап кала, җирдә эшләргә кеше юк, дип әйтәбез. Ләкин, бәхеткә, сирәк күренеш булса да, бар икән әле өметле яшьләребез. Сүзем Камышлы районындагы Иске Усман авылы егете Ринат Хәйретдинов турында булыр.***

***Нурсинә Хәкимова.***

# УЛ АВЫЛГА ГАШЫЙК

Хәер, аның тормышы турында башыннан ук сөйлим әле.

Ринатның балачагы авыл тормышына уралып үтә. Авыл хуҗалыгында механизатор булып эшләүче әтисе Рәфис, яраткан улы бераз үсә төшкәч, аны үзе белән басуга алып бара башлый. Иртәнге кояш нурларына коенып утыручы гүзәл табигать малайга яхшы тәэсир итә. Җирне сөреп, артыннан кап-кара буразналар сызып калдыручы көчле трактор да аңа бик ошый. Менә шул чагында Ринат үзенең туып-үскән җиренә, аның матур табигатенә, басу-кырларына һәм техникага гашыйк булганын сизми дә кала.

Ел артыннан еллар үтә. Әтисе улын чын игенче итеп тәрбияли, бу эшнең нечкә серләренә өйрәтә. Ә мәктәптә тугызынчы сыйныфны тәмамлагач, Ринат, ике дә уйлап тормый, Камышлыдагы һөнәр училищесына укырга керә. Чөнки ул балачактан ук сайлаган хезмәтенә тугры булып кала. Биредә белем алып, кулына "Киң профильле механизатор" дипломын алгач, туган авылына ашкынып кайта.

Яшь егет егерме яшендә грант ота. Бик кызык кына килеп чыга аның бу эше. Бераз уйланып йөргәч, Ринат Камышлы районына килә дә өлкән хуҗалар янына керә:

- Мин җирдә эшләргә телим, терлек үрчетер идем. Миңа ярдәм итә алмассызмы икән? – дип турыдан-туры әйтеп куя. Хуҗалар да, риза булып, бераз киңәшләшкәч, егеткә:

- Җир алып, эшеңне башлап җибәр әле, энем, - дип, хәер-фатыйхаларын бирәләр.

Барысы да җайга салына башлагач, ул бизнес-план төзи, рәсми кәгазьләр җыя. Шуннан соң Самар өлкәсендә үткәрелгән конкурста җиңеп чыгып, грант ота. Менә шулай итеп, бер авырлыксыз алга бара башлый ул. Шушы акчага трактор сатып алып, көзен



*Ринат Хәйретдинов әнисе Зәлия ханым белән терлек караганда*


Ринат әтисе Рәфис һәм ярдәмчесе (уртада) Сергей Гущин белән

җирләрен сөреп калдырырга да өлгерә. Өстәвенә, Камышлыдагы һөнәр училищесында белем алучы яшьләрне дә эшкә өйрәтә.

Билгеле, бердәм булып, уен-көлке арасында эшләгәч, күңелле дә булып куя.

Кызганычка, бу вакытта күмәк хуҗалыклар таркалган була инде. Ринатның әтисе Рәфис чит җирләрдә эшләп йөргән җиреннән кире авылга әйләнеп кайта һәм, яраткан улына киңәшләр биреп, үзе дә җиң сызганып эшкә керешә.

Билгеле, ата белән бала берләшкәч, эшләр тагын да алга китә. Әйтергә кирәк, бүгенге көндә Ринат Рәфис улының илле гектар җир мәйданы алты йөз илле гектар киңлекләргә кадәр җәелгән. Өстәвенә, ул күрше авыллары – Неклюдово һәм Хмелёвка җирләрен арендага алган. Җирдә рәхәтләнеп эшләр өчен, Хәйретдиновларның техникалары җитәрлек.

Аталы-уллы Хәйретдиновлар шушы җирдә бодай, солы, арпа, көнбагыш, җитен үстерәләр һәм йорт тутырып терлек асрыйлар. Әйтергә кирәк, Ринатның әнисе Зәлия ханым да бик уңган, ул сыерларны сава, сөтен, маен, каймагын, эремчеген урнаштыра.

Егерме сигез яшьлек егет җиргә зур ихтирам белән карый. Тагын да күбрәк аңлар, белер өчен, ул читтән торып Самар өлкәсендә урнашкан Кинель бистәсендәге институтны тәмамлаган.

- Хәзерге заманда югары белемсез калырга ярамый. Укып, белем туплагач кына, җир эшенең барлык серен аңлап була, - дип әйтте ул аралашканда.

Мин:

**- Ринат, ничек итеп, курыкмыйча, авылда калырга уйладың?** - дип сорагач, ул:

- Мин программист һөнәрен үзләштергәндә бераз шәһәрдә торып карадым. Анда тормыш бүтән. Ә авыл кешеләре гади, аралашучан, ачык күңелле, эшчән.

Менә шул чагында үземнең шәһәр кешесе түгеллегемне, асфальтта ипи үсмәгәнлеген, туган авылларыбызның гомере һәм якты киләчәге бары тик без – яшьләр кулында икәнлеген аңлап алдым.

Авыл тормышы мәшәкатьле булса да, аның тынычлыгы ошый миңа. Аннан соң сызылып аткан матур таңнарны яратам мин. Алар ышаныч тудыра. Монда җаным тыныч, чөнки мин - үз-үземә хуҗа.

Ә эштән курыкмыйм, бары тик исәнлек һәм дөньялар тыныч булсын иде, - дип җавап бирде.

Билгеле, яшь хуҗа Камышлыдагы өлкән җитәкчеләргә, авыл җитәкчесе Фәнил Кәримовка һәм ярдәм кулы сузучы дусларына, авылдашларына бик рәхмәтле.

Ринат Рәфис улы, киләчәктә яртылаш авып баручы, күмәк хуҗалык вакытыннан калган ферманы аякка бастырып, яхшы нәселле сыерлар, таналар, атлар үрчетергә планлаштыра.

Тик шунысы бар, авылдагы мәктәп ябылуы аның эчен пошыра.

– Педагог һөнәрен үзләштергән сеңелем Айгөл сөйгән егете Нәфискә тормышка чыкты. Алар авылда төпләнеп калдылар. Мәктәп булмагач, ул башка өлкәдә хезмәт итә башлады.

Мин дә яраткан кызым белән тормыш корып җибәрсәм, безнең балаларыбыз ачы суыкларда башка авылга йөреп укырга мәҗбүр булсалар – бу миңа бер дә ошамый. Ә мәктәбе дә булмаган авылга яшьләр кайтып урнашырмы соң? Авылыбызның киләчәге бармы? - дип борчыла туган җиренә гашыйк булган Ринат Хәйретдинов.

Минемчә, аның сүзләрендә хаклык бар.


Ринат Хәйретдинов әнисе белән өйләре янында

# СӘҮДӘ ЭШЕ ҮҖӘТЛЕК, УҢГАНЛЫК ҺӘМ ТӘВӘКӘЛЛЕК ТАЛӘП ИТӘ

***СССР чорында уңышлы эшләп килгән потребкооперацияләр, заготконторалар челтәре эшчәнлегенең никадәр мөһим булуын олы буын кешеләре яхшы хәтерли. Макулатура, тире, йон һәм башка чимал җыеп, шулардан тормыш кирәк-яраклары җитештерү белән бергә, заготовительләрнең экология проблемаларын да уңай хәл итүе хәзер аеруча зур игътибарга лаек. Заготовитель, сатучы эшләрен уңышлы алып барыр өчен, никадәр йөгерек акыл һәм халыкның психологиясен, ихтыяҗларын белү кирәк бит.***

***Фәрид Шириязданов***

Заготовитель гаиләсендә туып-үскән Рәшит Шәйхуллов Иске Фәйзулла авылында үткән яшьлек еллары турында сөйләде.

- Безнең бала һәм үсмер чакларыбыз бәхетле чорга туры килде. Бу инде сугыштан соңгы авырлыклар узган, һәм халык уңай тормышка аяк баскан вакыт иде. Кешеләргә хезмәт хакы акчалата түләнә башлагач, яшәү дә елдан-ел җайлана, матурая барды. Бөтен халык тырышып эшләгәнгә күрә, җирле колхоз эшчәнлеге һәм кешеләрнең көнкүреш шартлары һәрвакытта үсеш юлында булды.

Безнең әти-әниебез үз гомерләренә сәүдә өлкәсендә хезмәт иттеләр. Дөрес, ул чакта, хәзергедәй, эш өчен җайлы кибет тә юк, кирәк булган товарларны вакытында авылга алып кайтару да шактый авыр иде. Ә планны ничек тә үтәргә кирәк. Шуның өчен алар, көнне төнгә ялгап, ял һәм бәйрәм көннәрендә дә аяусыз эшләделәр. Нинди генә һава шартлары һәм юллар өзек булуга карамастан, әти-әниебез, якындагы Ульян өлкәсенә кергән һәм Татарстандагы төрле авылларга барып йөреп, кешеләргә хезмәт күрсәттеләр.

Тормыш уңайланган саен, халыкның ихтыяҗлары да арта барды. Бигрәк тә өй җиһазлары, мопедлар, мотоцикллар һәм машиналар да сатыла башлагач. Тик халыкның кулына акча керә башлауга карамастан, андый әйберләр әле сатуда җитәрлек дәрәҗәдә түгел иде шул. Авыл кибете кечкенә булуга карамастан, монда өс һәм аяк киемнәре, промтоварлар, азык-төлек һәм керосин сатуны да оештырырга кирәк иде.

Елгалар ташып, бөтен җирне су баскан, күперләр агып киткән, көзге һәм язгы пычракларда юллар өзелгән вакытларда әти-әниебезнең эше тагын да катлаулана иде. Ә тормыш кирәк-яракларын ничек тә кайтарып, халыкның ышанычын акларга кирәк бит!

Ни дисәң дә, ул вакытта кеше хезмәтенең кадерен белү дә бар иде. Әти-әниебезнең дә куйган хезмәтләрен күреп, аларга район һәм облпотребсоюз тарафыннан премияләр, мактау грамоталары, медальләр бирелде.



Әтиемнең әтисе - Вагыйз бабай һәм аның әтисе - Бәдретдин бабай заготовительләр булганнар. Эшмәкәрлек безнең нәселдә буыннан-буынга бирелеп килгән һөнәр булып саналган. Монда никадәр үҗәтлек, үткен булу белән бергә, уңганлык та кирәк бит. Вагыйз бабайның бакчасында үскән алма, слива, карлыган, кура җиләге һәм төрле яшелчәләр әле дә күз алдымда. Безнең йорт чисталыгы, пөхтәлеге һәм җыйнаклыгы белән дә башкалардан аерылып торды.



***Вагыйз бабай гаиләсе белән, уллары Мисбах, Вазыйх, Хәмзә***



*Бертуганнар - Рәшит, Гүзәл һәм Ришат Шәйхулловлар*



*Галия апа кызы Гүзәл, кияве һәм оныгы белән*



Бабамның коесы авылда иң тәмле сулы иде. Тирә-яктагы бөтен халык безнең коега суга йөрде. Шулай ук безнең өй башының калай белән ябылган булуы да авылда сирәк күренеш иде. Әлбәттә, боларның барысы да бабамның никадәр уңган һәм булган кеше икәнлеген ачык күрсәтәләр. Моның белән бергә бабамнарда да, әти-әниебездә дә кеше хәлен аңлый белү сыйфаты булуын да әйтеп үтәсем килә. Мәсәлән, аларның «Әҗәт дәфтәре» бар иде. Халыкка товарны бурычка биреп, шунда язалар иде. Чечняда һәлак булган Илдус Әхмәтҗановка акчалата ярдәм итүләре дә истә калган.

Ярдәмчеллек сыйфаты безгә дә күчкәндер, дип уйлыйм. Мәсәлән, энем Ришат авылыбыз тарихы турындагы китапны бастыруга үз ярдәмен күрсәтте. Авыл халкына күрсәткән ярдәме өчен дә күпләр аңа рәхмәтле.

Бабамның үҗәтлеге, уңганлыгы турында тагын бер мисал китерәсем килә. Ул чакта авылдагы бердәнбер кешедә - бары тик аңарда гына люлькалы мотоцикл бар иде. Шуңарда ул, халыктан азык-төлек, төрле чимал җыеп, заготконторага тапшыра һәм аннан товарлар алып кайта иде. Аннан соң, авылда бик сирәк кешедә, шул исәптән бездә дә, сепарат бар иде, шуңа да безнең урамдагы халыкның күпчелеге безгә сөт аертырга йөрде.

Тора-бара әтием дә аның эшен дәвам итте. Әле дә исемдә, аңа нинди генә йөкләмәләр җиткерелми иде: макулатура, сөяк, чүпрәк, тимер-томыр, йомырка, ит, тире, йон, иген, бәрәңге, кычырткан, агач каерысы, пыяла тара һәм башка чимал булырлык әйберләр җыеп, хөкүмәткә тапшыру һәм башка эшләр. Аның аты да, ЗИЛ-157 һәм Газ-66 маркалы машиналары да булганга, ул шуларда бөтен тирә-яктагы авылларны әйләнеп йөри иде. Кирәкле чималны җыюга халыкны кызыксындыру өчен, «дефицит» әйберләр дә кайтара иде.Ниләр генә юк иде анда: келәмнәр, мебель, телевизорлар, тузансуырткычлар, бензин пычкылары, мотоцикл, мопедлар һәм башкалар. Ә авыл балалары өчен - шарлар, уенчыклар, буяулар, сыбызгылар һәм сатуда булмаган башка әйберләр.



*Ришат улы белән*



*Ике туганнар - Мансур, Ришат һәм Ильяс*

Яшь чагымдагы иң якты истәлекләрем авылыбыз белән бәйләнгән. Мәсәлән, 7нче класста

укыганда, үземне Кара диңгездәге «Орлёнок» пионерлагерена җибәрделәр. Анда мин авылымны бик сагынып, туган ягыбызның, әебезнең күңелемә никадәр якын булуын беренче тапкыр ачык сиздем.

Авылда без, эшкә өйрәнеп, табигать кочагында чыныгып үстек. Өй һәм йорт эшләре һәрвакытта безнең өстә, һәм алар үзара бүленгән иде. Йорттагы мал-туарны карау, утын кисү-яру, мунча ягу һәм башка эшләр миңа йөкләнгән. Моннан тыш, мин әле печән чабарга да ярата идем.

Ә энем Ришат өй эчендә җыештыру һәм башка эшләрне башкарды. Ул бик чая иде, шуңа күрә миңа аңа күз-колак та булырга туры килде. Ул яшьтән спорт белән мавыкты, бигрәк тә җиңел атлетика белән. Ул һәрвкытта ярдәмчел булды. Авылда ниндидер эшләр башкарырга кирәк булганда, ул әле дә гел ярдәмгә килергә әзер. Гомумән, туган авылыбыз, туган йортыбыз безнең өчен һәрвакытта якын һәм кадерле. Хәзергәчә без даими рәвештә әниебезнең хәлен белеп, гел авылга кайтып-китеп йөрибез, өйне-йортны да, тәртипкә китереп, яңартып торабыз.

Кеше олыгайган саен яшьлеген ешрак искә төшерә. Ә безнең балачак иң ямьле заманга туры килгәнгә, ул күңелгә аеруча якын. Халык гөр-килеп эшләп, ярдәмләшеп, дус булып, кунакка йөрешеп яши иде бит. Шуңа да тормыш, һаман да ямьләнә торып, алга барды. Халык көнне төнгә ялгап эшләсә дә, барысы да киләчәккә өмет белән, хезмәттән һәм тормыштан ямь табып яшәде.

Торган саен колхоздагы авыр эшләрне техника, механизмнар башкара торгач, халыкка җиңеллек тә килде. Авыл тагын да ямьләнә, матурая барды. һәр йортта 4-5әр бала үскәндә, авыл урамнары һәрчакта гөрләп торды. Анда чылбырдай тезелеп киткән күлләрдә коенып, эштә чыныгып үскәнгә, безнең буын кешеләре тормышчан һәм нык буынлы булып җитлектеләр.

Без эшкә дә, уенга да вакыт таба идек. Авыл урамнарында уйнап үскәндә, без дуслыкның кадерен белергә һәм үзеңне кемнән дә кимсеттермәскә, нык буынлы булып, авырлыкларга бирешмәскә дә өйрәндек.

Ә инде хәзерге хәлләргә килсәк, безнең әтиләр башкарган эшләр бүген ташланган хәлдә. Төрле яклап кризислар, күп нәрсәгә мохтаҗлык артканда да, кыйммәтле чималлар ташланып, чүпкә баткан табигатьнең хәлен тагын да авырайталар. Ә менә шундый ук тиреләрдән, йоннардән эшләнгән әйберләрне чит илләрдән валютага алып керәләр, алтын бәясенә.

Әлбәттә, яшәү тәртибе гел болай бармас. Киләчәктә без дә, әби-бабаларыбыз, әти-әниләребез алып барган тормыш җаен өйрәнеп, шуннан гыйбрәт алып, үз тормышыбызны да уңай эзгә сала алырбыз, дип ышанам, - диде Рәшит Шәйхуллов.

Үз гомерләрен сәүдә эшенә багышлаган Шәйхулловлар нәселе авыл тарихында шактый тирән эз калдырган. Хәзерге заманга килгәндә, аларның яшь буыны вәкиле Ришат Шәйхулловны телгә аласы килә. Бу авыл тарихы турында китап булдыру кирәклеге турында сүз чыгуга ук, ул, үзенең теләктәшлеген белдереп, зур ярдәм күрсәтте. Аллаһыга шөкер, хәзер ул китап инде басмага әзер һәм аны дөньяга чыгару өчен хәрәкәт бара.

Ришат күрсәткән мондый изгелек очраклы хәл түгел, ул ирәннән, нәсел тамырларыннан килә. Авыл тарихын саклауга, аны мәңгеләштерүгә юнәлгән ярдәм - иң изге гамәлләрнең берсе. Эшмәкәр буларак, Ришат әле үзенең авылдашларын эш белән дә тәэмин итә. Туганнарын, әнисен хөрмәт итеп, хәлләрен белешеп һәм кайгыртучанлык күрсәтеп тора.

Ярдәме өчен үземнән, китап булдыру юлында хезмәт күрсәткән һәм, аның киләчәк өчен актуальлеген аңлап, теләктәшлек күрсәткән кешеләр исеменнән аңа олы рәхмәтләрне белдерәм.



*Мәчет янында*



*Ришат Шәйхуллов (сулдан беренче) һәм Рәшит Шәйхуллов (утырган) дуслары белән*



*Ришат Шәйхуллов хатыны һәм балалары белән*

# ИБРАҺИМ НУРУЛЛИНГА – 100 яшь

***2023 елның 18 апрелендә күренекле галим, язучы, драматург һәм тәнкыйтьче Ибраһим Зиннәт улы Нуруллинның тууына 100 ел булды.***

***Рафаил Шәйдуллин,***
***тарих фәннәре докторы, профессор***

Җир йөзендә нибары 72 ел гомер кичерүенә карамастан, ул бик зур казанышларга ирешә. Филология фәннәре докторы, Казан дәүләт университеты профессоры дәрәҗәләренә, Татарстанның Габдулла Тукай исемендәге Дәүләт бүләгенә, Татарстан мәдәният министрлыгы һәм Татарстан Язучылар берлегенең Гаяз Исхакый исемендәге премиясенә лаек була.

Бүгенге көнгә Ибраһим Нуруллинга һәм аның иҗатына багышланган дистәләгән фәнни-популяр хезмәтләр дөнья күрде. Аларда хәзерге Ульяновск өлкәсенең Мәләкәс районы Парау авылында туган гап-гади татар егетенең фәнни казанышлары һәм тормыш юлы төрле күзлектән яктыртыла, бәяләнә. Бу мәкаләдә аларны кабатлыйсым килми. Ибраһим аганың тормышы миңа шуның белән бик кызыклы һәм якын ки: ул – мин укыган Әбдери сигезьеллык (ул вакытта җидееллык) мәктәбен тәмамлап, күренекле галим һәм әдип булып танылган шәхес. 7 нче сыйныфтан соң, Ибраһим Нуруллин 1937/1938 елгы уку елында белем алуын Мәләкәс татар урта мәктәбендә дәвам итә, 8 нче сыйныфны тәмамлагач, Казанга юл тота. 1938–1942 елларда Казан мех техникумында укый, дүртенче курстан укуын ташлап, үз ихтыяры белән сугышка китә. Батырларча сугыша, каты яралана һәм бер аягын югалта. Ә бит егеткә унтугыз яшь! 1943–1945 елларда Парау мәктәбендә укытучы булып эшли. 1945 елдан аның тормышы Казан университеты белән бәйле. Әйтелгәнчә, ул анда



зур фәнни һәм иҗади уңышларга ирешә.

Шунысы кызык, Ибраһим Нуруллинның паспортында Парау авылында туган, дип язылса да, моның төгәллеген шиккә алучылар да бар. Аның балачагының байтак еллары Тупли (хәзер Самар өлкәсенең Елховый районында), Әбдери, Лабит һәм Зирекле Куак (өчесе дә Ульяновск өлкәсенең Яңа Малыклы районында) авылларында үтә. Тупли авылының төбәкне өйрәнүчеләре Ибраһим Нуруллин безнең авылда туган, дип язып та чыктылар. 1919–1920 еллар башында аның әтисе Зиннәт Нурулла улы Нуруллин Тупли мәктәбендә балалар укыта, соңрак Зирекле Куак башлангыч мәктәбендә эшли. Ә Әбдери җидееллык мәктәбе Ибраһимга фән, әдәбият дөньясына юл ача. 1929–1930 елларда гына барлыкка килгән Әбдери җидееллык мәктәбе укучы балаларга төпле белем бирә алган, дип нәтиҗә үзеннән-үзе туа. Бу мәктәптән берничә галим һәм хәрби чыга, шулар арасында, Ибраһим Нуруллиннан тыш, Лабит авылында туган филология фәннәре докторы Мәсгуд Вәлиәхмәт улы Гайнетдинов, подполковниклар Җәмил һәм Шамил Мостафа уллары Сафиннар. Күренекле шәхес, татарлар арасында бердәнбер авиация генерал-лейтенанты, биш Кызыл Байрак ордены һәм башка орденнар кавалеры Әхмәтгәрәй Насыйбулла улы Рамазанов та Лабит авылы тумасы. Димәк, анда ул чакта ук талантлы балаларның сәләтен ачарлык тәҗрибәле укытучылар эшләгән. Моның сәбәбен Әбдери авылында элегрәк "Үрнәк" исемле җәдиди мәдрәсә эшләве белән аңлатырга мөмкиндер. XX йөз башында әлеге уку йортына җәдитче мулла, бер үк вакытта социалист-революционер (эсер) Гакыйль Билал улы Ашмасов нигез сала. Яңа ачылган мәдрәсәгә хәзерге Ульяновск өлкәсенең Кызылсу (Татар Урайкиносы) авылыннан берничә укытучы укытырга килә. Мәдрәсә үзе озак эшләмәсә дә, аның Әбдери, Лабит һәм башка тирә-як татар авыллары өчен әһәмияте бик зур булган, дип ышанырга нигез бар.

Әйтеп узганыбызча, Ибраһим Нуруллинның балачагы туган авылы Параудан еракта урнашкан Әбдери, Лабит, Зирекле Куак һәм Туплида – әтисе укыткан һәм үзе укыган авылларда үтә. Әдипнең әтисе Зиннәт Нурулла улы Нуруллин 1890 еллар тирәсендә Парау

авылында Нурулла һәм Сәрбиҗамал гаиләсендә туа. Зиннәт Нуруллинның әти-әнисе ике яклап та укымышлы гаиләләрдән була. Нурулла бабасы, дини һәм дөньяви яктан ныклы белеме булса да, игенчелек һәм эшмәкәрлек белән шөгыльләнүне кулайрак күрә, яңа заманча яшәргә һәм эш итәргә омтыла. Ибраһим ага Нурулла бабасын болай сурәтли: “Аның өе урамга перпендикуляр итеп салынган алты почмаклы, калай түбәле зур өй иде. Киң ишек алдындагы лапас, сарай, келәтләр белән уратып алынган. Урыс капканың урам ягында тимер ишекле таш подвал бар иде”. Нурулла абзый улы Зиннәтне мәдрәсәгә биреп укыта. Уку йортын тәмамлаган улының балалар укыту ниятенә дә каршы төшми, киресенчә, аны хуплый. Зиннәт Нуруллин чыгышы белән хәлле гаиләдән булуына карамастан, дөнья малын арттыруга хирыслык итми, укытучылык эше аңа якынрак була, һәм ул шуның белән дөнья көтә. Бер үк вакытта үз заманының сәяси-иҗтимагый процессларында актив катнаша, колхозлар (коммуналар) оештыру эшенә дә үз өлешен кертә. Зирекле Куак башлангыч мәктәбе аның соңгы эш урыны була. Зиннәт Нуруллинны шул мәктәпкә нигез салучыларының һәм аның җитәкчеләренең берсе, дип саныйлар. Мөгаллим 1938 елда бик яшьли кара сары авыруыннан вафат була. Аны Зирекле Куак зиратында, Рево һәм Люция исемле ике-өч яшьләрендә үлгән игез балалары каберләре янәшәсендә җирлиләр. Аларның каберләре зиратта саклана, чардуган һәм таш куелган. Шул ташка мәрхүмнәрнең исемнәре язылган. Бүгенге көндә каберләре өстендә пар каен үсеп утыра.

Ибраһим Нуруллин башта Зирекле Куак башлангыч мәктәбендә белем ала, аннары укуын, әйткәнебезчә, биш-алты чакрым ераклыкта, Әбдери һәм Лабит авыллары арасында урнашкан Әбдери җидееллык мәктәбендә дәвам итә. Күбесенчә йөреп укый, кышкы салкыннарда, көзге-язгы пычракларда шушы ике авылда фатирга кереп яши. 1983 елның җәендә, Ибраһим ага белән аның тормыш иптәше, журналистика белгече, филология фәннәре кандидаты, Казан университеты доценты Розалина Мәрдановна Лабитка кайткач, алар Әбдеридә яшәүче укытучы Әсхәт Гыйниятуллиннар гаиләсендә кунак булалар. Дөнья һәм тормыш хәлләре, авылдагы татар балаларын укыту һәм тәрбияләү мәсьәләләре турында озак сөйләшеп утыралар. Нәкъ менә шушы йортны сайлап керүләренең сәбәбе шул ки, Әбдери мәктәбендә укыган вакытта Ибраһим ага Әсхәтнең әти-әниләрендә фатирда яшәгән була. Минем әнием дә (ә алар Ибраһим Нуруллин белән туганнан туганнар) бу гаилә вәкилләрен ихтирам итә иде. Шул ук көнне без бергәләп Әбдеридә яшәүче Нуркай Галимов белән дә очраштык. Сөйләшү аягурә булды, чөнки хуҗаның эше тыгыз, ул мунча мичен төзекләндерү белән мәшгуль иде. Шуңа да карамастан, Нуркай абый безне өйгә чәй эчәргә дәште. Ләкин Ибраһим ага, елмаеп, хуҗага үзенең рәхмәтен белдерде, барып һәм керер урыннарыбызның әле бик күп булуын әйтеп, ашыгуыбыз турында әйтте. Нуркай абый бу хәлгә бик уңайсызланса да, килешеп, “икенче вакытта бездә кунак булмыйча китә күрмәгез”, дип чакырып калды. Ибраһим Нуруллин, вәгъдәсен биреп, “синең белән яшьлегебезне искә алып сөйләшер сүзләрем бик күп калды әле”, дип саубуллашты. Бу өйдән чыккач, мин аңардан әлеге җылы мөнәсәбәтләрнең сәбәбен сорашып өлгергәнче, Ибраһим ага “без аның белән Әбдери мәктәбендә ярыша-ярыша китап укый һәм аларның эчтәлекләрен бер-беребезгә сөйли идек”, дип, үзе үк ачыклык кертте.

Аңа кадәр Ибраһим ага Әбдери авылының яңа ике катлы сигезъеллык мәктәбендә булды, анда мәктәп директоры Гөлфия Госмановна һәм аның ире, укытучы Харис Зәбирович Хафизовлар белән очрашты. Ул аларга үзенең Әбдери мәктәбендә уку еллары турында горурланып сөйләде. Сүзенең нигезендә Әбдери мәктәбенең ничек итеп аңа алдагы тормышын билгеләргә ярдәм итүе турындагы фикер ята иде. Әдип һәм галим мәктәпнең ролен искиткеч тырыш һәм булдыклы укытучылары, бай китапханәсе, сәләтле укучылары белән ассызыклады. Китапханәдәге татар, рус һәм чит ил язучыларының әдәби әсәрләрен сыйныфташлары белән узыштан укулары турында бик кызык итеп сөйләде. Аның хәтеренә аеруча француз язучысы Жюль Вернның әсәрләре сеңеп калган икән. Бу язучының мәктәп китапханәсендә сакланган әсәрләре турында бала вакытымда Ибраһим Нуруллиннан бер сыйныфка түбәнрәк укыган әтиемнән – Вәли Әхмәт улыннан да ишетергә туры килгәне бар иде.

Әбдери мәктәбендә бер Ибраһим Нуруллин гына түгел, барлык укучылар да, белемгә омтылып, җанлы тормыш белән яшәгәннәрдер, дип ышанабыз. Ул алардан, бәлки, әдәбиятны артык яратуы белән генә аерылып торгандыр. Өлкәнрәк сыйныфларда Ибраһим ага бик күп язучыларның исемнәрен, язган әсәрләрен белгән һәм үзләрен күрергә хыялланган. Нәкъ Әбдери мәктәбендә аның бу хыялы томышка аша да. Мәктәптәге әңгәмә вакытында Ибраһим Нуруллин танылган татар шагыйре Сәхаб Урайский белән очрашуны үз тормышындагы бер зур әһәмияткә ия булган күренекле вакыйга булarak тасвирлады. Ул очрашуда мәктәпнең өлкән сыйныфларында укучы, димәк, унөч, ундүрт яшьтәге балалар катнаша. Әйтеп китик, шагыйрь аларның авылдашы ук булмаса да, якташы – тумышы белән алда искә алынган Кызылсу авылыннан. Шагыйрь белән очрашу, аның шигырьләрен тыңлау һәм совет шигърияте турында җитди фикерләрен ишетү авыл балалары өчен мөһим вакыйга гына булып калмыйча, арадан кайберәүләре өчен иҗади этәргеч тә була. Шул

көннән соң кайбер мәктәп балалары шигырьләр һәм хикәяләр язарга омтылып карыйлар. Иҗат дип әйтерлек зур уңышка ирешә алмасалар да, бу омтылышлар авыл балалары күңелендә илһам уты кабыза. “Шул балалар арасында мин дә бар идем”, – диде Ибраһим ага.

Әдипнең истәлек итеп сөйләгән сүзләре мәктәп җитәкчелеген гаҗәпләндерде дә кебек, чөнки алар Сәхаб Урайский белән очрашу турында гына түгел, Ибраһим Нуруллиның Әбдери җидееллык мәктәбен тәмамлавы турында да, ялгышмасам, беренче тапкыр ишетәләр иде. Моны аңларга да була, үткәннәр белән бүгенгене бәйләгән җеп бер өзелсә, аның очларын табу, ялгау бик кыен. Ялгаучылар булмаса, үткәннәр онытыла. Авылда кеше кешене белә, дибез. Әмма күп кенә авыл мәктәпләрендә горурланырлык якташлар-авылдашлар турында мәгълүмат юк, дип әйтергә мөмкин. Күренекле шәхесләр белән горурлана белмәүләре өчен укучыларның үзләрен генә гаепләү дөрес булмас. Авыл мәктәпләрендә шунда укыган мәшһүр шәхесләр исемлеге төзү, алар турында материаллар туплау һәм мәктәп диварларында әлеге шәхесләрнең кемлеген күрсәткән элмә такталар кую буенча актив эш алып барыла, дип әйтеп булмый. Ә нигә әле, мәсәлән, Әбдери мәктәбен тәмамлаган һәм зур фәнни казанышларга ирешкән Ибраһим Нуруллин, Мәсгуд Гайнетдинов, исемнәре югарыда аталган хәрбиләребезгә мемориаль такталар куймаска? Алар аңа лаек. Горурланырлык шәхесләр татар авылларында күп алар!

Озак кына сөйләшеп утырганнан соң, Ибраһим ага мәктәп директорына үзенең авыл балалары белән очрашу оештырып булмасмы, дигән теләген җиткерде. Гөлфия Госмановна, үз чиратында, хәзер урак вакыты булуын, өлкәнрәк яшьтәге балаларның күпчелеге колхоз эшләрендә катнашуын искәртеп, аларны җыюның бик авыр икәнен, мондый очрашуны уку елы башлангач оештыруның мәгъкуль булачагын белдерде. Шул сүзләрдән соң, Ибраһим Нуруллин шаяру катыш: “Мин соңгарак калганмын, я иртәрәк килгәнмен икән алайса”, – дип көлемсерәде һәм мәктәп коридоры буйлап узу, берничә класска кереп, парта артында утыру һәм директор кабинеты янында урнашкан зур шкафлардан кулына китап алуны хыялында йөрткәнен әйтеп, авыр сулап куйды...

Минем өчен шунысы кадерле: Әбдери сигезъеллык мәктәбе, балалар азлыгына карамастан, бүгенге көнгә кадәр эшләвен дәвам итә. Ә Зирекле Куакта җидееллык мәктәп 1952 елларда гына эшли башлый, 1969 елда аны урта мәктәп итеп үзгәртәләр һәм ике катлы зур бина төзиләр. Укучы балалар булмау сәбәпле, шул мәктәп 2022 елда ябылды, дип ишеттем. Шундый ук кызганыч хәл дүрт мәчетле Тупли авылында да күзәтелә, заманында гөрләп эшләгән унберъеллык мәктәп берничә ел элек ябыла...

Ибраһим ага Нуруллинның, Казанда төрле дәрәҗәләргә ирешсә дә, авыл җанлы булып калуы турында аерым әйтәсем килә. Лабит һәм Зирекле Куак авыллары белән элемтәне беркайчан да өзмәде ул. Аның туган якларына кайтулары 1964 елда, сугыш инвалиды буларак, “Запорожец” машинасы алгач, тагын да ешайды. Күп вакыт ул туп-туры Лабитка, шул авылга килен булып килгән туганнан туган сеңелесе Әклимә (1925–2003 еллар) һәм аның тормыш иптәше Вәли (1924–2012 еллар) Шәйдуллиннарга кунакка кайтып төшә иде. Минем әти-әниемнәргә, ягъни безгә. Ибраһим абыйның тормыш иптәше Розалина Мәрдановна, кызлары Гүзәл (1952 елда туган) һәм Миләүшә (1955 елда туган) белән 1969 елда “Запорожец”та кайтулары балачак хәтеремдә яхшы саклана. Нәкъ шул кайтуында ул, гаилә әгъзалары белән бергәләп Зирекле Куак зиратына барып, әтисенең һәм энекәш-сеңелкәшенең чардуганын һәм кабер ташын төзекләндерде, буяды. Казанга киткәндә 1964 елда нәшер ителгән “Образлар дөньясында” дигән китабын безгә бүләк итеп калдырды.

Ибраһим ага һәм Розалина ханымның безнең якларга соңгы кайтулары 1990 елның җәендә булды. Бу юлы инде алар поездга утырып кайттылар. Башта Димитровградтагы кайбер туганнары һәм дуслары белән очраштылар, аннары Тия (Тиинск) авылында яшәүче туганнан туганы, мишәрчәләп әйтсәк, ике туган браты Нәсыйх Нурмөхәммәд улы Нуруллиннар гаиләсендә кунакта булдылар. Берничә көннән соң Казан кунакларын Лабитка машинада зурлап китереп куйдылар. Шул ук көнне, мунча кереп чыкканнан соң, этием белән Ибраһим ага ярты төнгә кадәр сөйләшеп утырдылар. Әбдери һәм Мәләкәс мәктәпләрендә укыган вакытта алар бер-берсен белгәннәрме, дигән сорауга мин җавап бирә алмыйм. Ибраһим ага Мәләкәс татар урта мәктәбенең 8 нче сыйныфын тәмамлап китә, ә минем әтием 8-9 нчы сыйныфларда шунда укый. Шундый очрашуларда сөйләшеп утыру өчен ике чордаш, ике фронтовик уртак сүз таба беләләр, бер-берсен ихтирам итеп, иплəп кенә әңгәмә алып баралар иде. Икенче көнне әти, мин һәм Нуруллиннар гаиләсе күрше авыл - Зирекле Куакка машинада бардык. Зирекле Куак мәктәбендә директор белән очраштык, ә аннары авыл зиратында Зиннәт Нуруллинның каберендә булдык. Ул вакытта кабер өстендә биеклекләре 3-4 метр чамалы яшь каеннар үсеп утыра иде. Ибраһим ага бу каеннарны мәктәп балалары утыртуы турында әйтте. Ә 2022 елда әнинең кече сеңелесе Сәмирә һәм башка туганнар белән Зиннәт бабайның каберен зиярәт кылганда, ул каеннар инде 20 метрлардан ашар кебек күренде.

Кире кайтканда Зирекле Куак һәм Лабит авыллары чикләрендәге утыртма агачлар арасына ял итәргә тукталдык. Урын бик матур, ерактагы калкулыклар, урманчыклар, кырлар һәм болыннар уч

төбендәге сыман күренеп тора. Ә астарак боҗраланып, ермакланып, җәйге искиткеч матурлыгы белән күңелне дулкынландырып, Зур Әүрәле елгасы агып ята. Нәкъ шул вакытта, табигать матурлыгына сокланып, Ибраһим ага: “Мондый матур табигатьне ничек калдырып китеп була...” – дип куйды. Мин уйлавымча, ул бу минутларда, күңеле сизгән сыман, туган ягы табигатенең күз алдына тезелгән матур күренешләре, үзенең балачак еллары һәм безнең белән хушлашты. Бу кайту аның өчен соңгысы булды. Берничә елдан соң Ибраһим Нуруллин инсульт кичерде, ләкин шуңа да карамастан, гомеренең соңгы көннәренә кадәр фәнни мәкаләләр һәм хикәяләр язуын дәвам итте.

Бу сүзләрдән соң күпме вакыт утырганыбыз турында хәзер әйтә алмыйм. Розалина Мәрдановнаның хуш исле кыр чәчәкләреннән матур итеп букет бәйләгәнен хәтерлим. Икенче көнне без өчәүләшеп, Ибраһим ага, әти һәм мин, әтинең үзе ясаган машинасына утырып, инеш буена печән чабарга киттек. Печән сәбәп кенә, төп максат Ибраһим аганың күптән күңелендә йөрткәнен – Әбдери-Лабит авылына кайтып, Зур Әүрәле елгасында балык тоту хыялын тормышка ашыру иде. Июль аенда яр буйларында балык тотучылар бик сирәк, чөнки Калмык Сакчысы буасы инешнең суын берничә метрга күтәртә. Шул сәбәпле елга агымнарындагы тукланган балыкларны (шәмбә, алдарка, алабуга, чыршы һ.б.) тоту бик кыен. Бу хәлне кунакка аңлатырга тырыштык, ләкин Ибраһим ага, “төзәлмәс” оптимист булуы сәбәпле, безнең белән килешергә җыенмады. “Балыкны төрле шартларда тотарга безнең хәлебездән килә”, – дип көлеп кенә куйды. “Ярый, улым, абзаңның күңеле булсын, кармакларны, суалчаннарны әзерлә”, – дип әйтте әти. Көн матур, чиста суда кояш нурлары уйный, су өстендә вак балыклар йөзеп йөри, баш өстебездә карлыгачлар оча. Борыннарыбызга чәчәк һәм су үсемлекләренең хуш исләре бәрелә, колакларыбызга кошларның гөрләшеп сайрашулары, бөҗәкләрнең безелдәве ишетелә. Безнең өчен табигатьнең шул почмагы бик матур урын булып тоелды.

Әти, елгага карап, күтәрелгән суны күреп, “ярый, сез балык тота торыгыз, мин печән чабарга киттем”, дип әйтте дә бездән ерак булмаган аланга кереп югалды. Без кармакларга суалчаннарны кидердек һәм аларны суга ташладык. Икәүләшеп озак кына калкавычларга карап, балык чирткәнен көтеп утырдык. Ләкин батмыйлар гына бит. Шулай күпмедер вакыт утыргач, балык тотуның үзебез өчен яңа булган ысулын таптык. Кармакка кидергән суалчанны су өстеннән йөртә башладык һәм, шулай итеп, берничә дистә алабуга һәм чыршы балыгын тотуга ирештек. Ибраһим ага саф һавада балык тотудан үзенә бер ләззәт тапты. Ул һәр тоткан балыгына балаларча сөенә. “Балыкны менә шулай тоталар аны!” - дип кычкырып куанычы белән уртаклаша. Аңа тотылган балыкның зурлыгы-ваклыгы түгел, хәтта балык үзе түгел, балык тоту процессы кызыграк булды. Әти машина тутырырлык печән чапты, без икәүләшеп бер зур табада кыздырырлык балык тоттык. Кайсыбызның күбрәк тотуын хәзер әйтә алмыйм, хәер, ул мөһим дә түгел! Тоткан алабуга һәм чыршы балыклары бик эре булмауга карамастан, Розалина Мәрдановна, аларны чистартып һәм тәмле итеп кыздырып, табынга китереп куйды. Без һәммәбез дә Ибраһим Нуруллинның балыкчылык сәләтен мактый-мактый кыздырылган балык ашадык.

Нәкъ шул вакытта елга буенда аның икенче хыялы да тормышка ашты. Ул, аягыннан протезын салып, Зур Әүрәле елгасында рәхәтләнеп су коенды. Безнең белән балаларча су сибеште. Елгада коену аның күңелен балачагына алып китте. Шуннан соң ул, елгада балык тотулары, анда куышып уйнаулары турында сөйләп, рәхәтләнә торган булды. Бу коену аның балачагына кайтуының соңгы аккорды булды. Берничә елдан соң Ибраһим ага бик каты авырды. Шул чорда мин аның белән берничә тапкыр очраштым. Һәр килгән саен ул Лабитка соңгы кайтуын искә алып сөйләде. Бу истәлек аның күңелендәге балачак еллары белән бәйле вакыйгаларны яңарткандыр, мөгаен. Кайсы вакытта: “Әниең пешергән тәмле ашлар, камыр ризыклары һаман да минем күз алдымда”, - дип әйтә иде. Ибраһим аганы аңлап була: безнең әни аш-суга оста, алар Лабитка кайткач, әни кунакларны, ризык төрләндереп, беренче чиратта, камыр ризыклары белән иркәләргә ярата иде.

Ибраһим Нуруллинны кайберәүләр “усал”, дип әйтсәләр дә, ул, минемчә, бик гади, мөлаем һәм ярдәмчел кеше иде. Әлбәттә, үз фикерләрен җиренә җиткереп һәм турыдан-туры әйтергә оста булды. Ибраһим ага бер кешегә карата да начарлык эшләмәде, аның күңеле һәрвакытта ачык һәм саф иде. Ул һичкайчан үз намусына хыянәт итмәде. Менә шул матур сыйфатлары галимнәрне, әдипләрне һәм аны белгән барча кешене Ибраһим Нуруллинның иҗатына, аның кешелекле образына җәлеп итә. Казанда һәм башка төбәкләрдә аның 100 еллыгына багышланган төрле мәдәни-әдәби кичәләр, массакүләм мәгълүмат чараларында оештырылган тапшырулар һәм газета-журнал битләрендә дөнья күргән мәкаләләр нәкъ менә шуны ачык чагылдыра. Бу хөрмәтләргә ул бик лаек. Минем фикеремчә, Казанда Ибраһим Нуруллин яшәгән йорт диварына, ул укыган Әбдери мәктәбенә аның шәхесен зурлаган элмә такталар куярга, Ульяновск, Димитровград урамнарының берсенә аның исемен бирергә кирәк. Татар тарихи-мәдәни мирасының мәшһүр күренеше буларак, күренекле галим, әдәбиятчы һәм тәнкыйтьче Ибраһим Нуруллинның исеме һәм иҗаты, риваять сыман, буыннан-буынга яңгырап яшәргә тиеш.

# Иске Ярмәк авылы мәктәбе - чемпионнар әзерләүче укыту-тәрбия үзәге

***Көчле рухлы һәм максатчан педагог кына, балаларга бирелгән мөмкинлекләрне үстереп, аларны белемле, физик яктан таза һәм көчле рухлы шәхесләр итеп тәрбияли ала. Физкультура укытучысы булып эшләгән Миназтин улы Әсхәт Гыйләҗев - менә шундыйлардан.***

***Ул хәрәкәтчән, җитез, җитди һәм үз-үзенә дә, башкаларга карата да таләпчән. Шуңа да аның янында беркем дә сүлпән һәм алкы-салкы була алмый. Ул 45 ел физрук булып эшләгән дәвердә Иске Ярмәк авылында физкультура һәм спортка карата элгәредән килгән хөрмәт тагын да көчәйде.***

***Фәрид Шириязданов.***

Түбәндә аның белән булган әңгәмәбез.

***– Физкультура һәм спортның әһәмияте хакынданиләр әйтә аласыз?***

– Физкультура – кешенең тән төзелешен, исәнлеген ныгытуга юнәлгән, табигый дәрес. Мәктәптә, җәмгыятьтә физкультура һәм спортка булган караш педагогика культурасы торышын, халыкның тормышчанлыгын һәм ныклыгын да ачык билгели.

Кытайда бөтен халык арасында киң таралган физик күнегүләр, элгәре СССРда һәм башка илләрдә производство гимнастикасына булган хөрмәт тә физкультураның никадәр мөһим һәм файдалы булуы турында сөйли.

Физкультура һәм спорт белән актив шөгыльләнү бернинди дару да бирә алмаслык исәнлек, яшәү дәрте һәм кешегә үз-үзенә карата ныклы ышаныч бирә, төрле җиңүләр яуларга омтылыш тудыра. Аның бар булган мөмкинлекләрен эшкә җигеп, уй-фикерләрен, хыялларын тормышка ашыру өчен дә киң юллар ача.

Спорт белән дус булган кеше башкалардан аерылып тора. Аның гәүдәсе төз, тән төзелеше дә матур һәм килешле. Нинди эшкә алынса да, ул аны батырып, җиренә җиткереп эшли.

***– Физкультура укытучысы эшенең төп максаты нинди?***

– Педагогика өлкәсендәге иң көчле тәрбияне бары тик физ-



культура һәм спорт бирә ала. Мәсәлән, спорт ярдәмендә җинаять юлына баскан үсмерләрнең дә тормышта уңышлы, үрнәкле шәхесләр булып китүе бер дә очраклы хәл түгел.

Кечкенә вакытта һәркемнең тизрәк үсәсе, олырак, көчлерәк булып күренәсе килә. Моның өчен ул тәмәке тарта башлый яисә рюмкага үрелә. Ә спортка тартылса, боларның зарарын тиз аңлый. Аннан соң, кечкенәдән чирләшкә, мескен хәлдәге үсмерләр, үз-үзләрен кулга алып, спортка тартылсалар, алар бөтенләй башка кешегә әвереләләр.

Үскәндә балалар аеруча актив, хәрәкәтчән була һәм аларның дәрте ургып тора. Шуңа да физкультура укытучысының төп максаты – баланың яшьлек энергетикасын уңай эзгә салып, аны физик яктан камилләштерү һәм төрле җиңүләргә омтылыш тудыру.

***– Спортның авыл җәмгыятенә, андагы халык көнкүрешенә карата уңай йогынтысы хакында нинди мисаллар китерә аласыз?***

– Иске Ярмәк авылында физкультура һәм спортның популярлыгы һәм мондагы спорт сөючеләрнең тормышта уңышлы булуы турында күп мисаллар китерергә була.

Андыйлар, һәрвакытта актив тормыш позициясендә булып, уңышлы эшләр башкарып яшиләр. Шуңа да безнең авыл тормышының кайсы гына тармагын алма – анда һәрвакытта җанлылык һәм күңел күтәренкелеге хөкем сөрдә.

Шулай ук кем генә авылда үткән балалык һәм үсмер елларын искә алмасын, аларның иң якты истәлекләре спорт күнегүләренә, төрле спорт ярышларында ирешкән уңышларга бәйләнгән. Армия сафларында хезмәт иткәннәр өчен мондый истәлекләр аеруча кадерле.

***– Спорт эшчәнлеге авыл тарихында да шактый зур һәм истәлекле урын алып тора. Бу нәрсәгә бәйләнгән?***

– Иске Ярмәктә спортның кискен үсеш алу чоры авылда мәктәп директоры булып спорт остасы Маннур Саттаровның эшли башлавына бәйләнгән. Ул елларда физкультура һәм спорт үсеше авылда әле аңа кадәр күренмәгән могҗиза күренешенә әверелә. Вышкалы трамплиннан сикерүләр, чын спорт бәйрәмнәрен үткәрү матур, җанлы һәм мавыктыргыч традициягә әйләнә. Спорт өлкәсендә Маннур Саттаров чорында башланган күтәрелешне физкультура укытучысы Шәһимәрдән улы Мөхәммәтнур Шириязданов дәвам итеп, аны үсеш юлына бастыра. Ашарга – ризык һәм киярга кием булмаган, авыр елларда чабатага бәйләгән, агачтан ясаган чаңгыларда шуып үскән балалар, төрле җиңүләр яулап, зур уңышларга ирешәләр. Әлбәттә, мин эшли башлаган еллар тормыш күпкә җиңеләя барган вакыт иде. Авыл мәктәбендә физкультура һәм спортны үстерү өчен, шактый киң мөмкинлекләр туа торды. Моннан файдаланып, мин, алга таба тагын да зуррак максатлар куеп, спортның төрле тармакларын үстерү өчен, бар булдыгымны эшкә җигеп, күп көч куеп, тырышып эшләдем. Авыл җәмгыятендә спортка караш, аның әһәмиятен һәм дәрәҗәсен үстерү мәсьәләсе һәрвакытта мәктәп эшчәнлегенең иң алгы планында торды. Мин, Әлмәт физкультура техникумын тәмамлап, Иске Усман авылында физрук булып эшләгән вакытта Мөхәммәтнур абый Шириязданов лаеклы ялга китәр алдыннан мине чакырып алды һәм үзенә алмашчы булырга тәкъдим ясады.

Иске Ярмәк авылы мәктәбен тәмамлаучылар арасында башка физкультура белгечләре булса да, аның миңа мөрәҗәгать итүе зур шатлык һәм горурлык хисләре тудырды. Шул вакытта мин, үз өстемә никадәр зур җаваплылык йөкләнүен аңлап, аның тәкъдимен кабул иттем. Моны гел истә тотып, элгәреддән килгән традицияләрне саклап кына калмыйча, спортның төрле тармакларын киң җәелдереп үстерергә тырыштым.

***– Сез эшләгән чорда һәм элгәре дә спорт өлкәсендә һәм тормышта югары уңышларга ирешүче спортчылар саны бик күп. Шулай да, иң тырыш, иң оста булганнарын кыскача булса да билгеләп үтәргә кирәктер?***

– Әлбәттә, бу сорауга тиз генә җавап бирергә авыр. Чөнки 45 ел эшләү дәверендә андыйлар саны шулкадәр күп булды. Ә иң мөһиме – барысы да – минем күңелгә якын, мактауга һәм олы хөрмәткә лаек булган укучыларым. Алар белән бергә без, җан фәрман ашкынып, төрле җиңүләр яуладык. Моның өчен никадәр көч түгелде, тырышлык һәм чыдамлык кирәк булды. Шуның өчен дә, берсенең исемен атап, калганнарын телгә алмасаң, яхшы булмас. Дөрес, алар турында һәм авылда спорт өлкәсендәге казанышлар хакында бер китап, альманах язып булыр иде.

Спортның таләпләре катгый – анда иң көчле, тырыш һәм, үзенең бар булдыгын эшкә җигеп, иң югары нәтиҗәләргә ирешүчеләр генә җиңүләр яулый ала. Әлбәттә, андыйлар хәтергә аеруча нык сеңеп калучан.

Әгәр дә район, зона һәм өлкә күләмендә үткәрелгән ярышларда җиңүчеләр, призёрлар булып танылган спортчыларны алсаң, мин иң югары уңышларга ирешкән укучыларымны әйтеп үтәр идем. Болар, райондагы, районнар арасындагы һәм зона буенча үткәрелгән ярышларда катнашып, җиңүләр яулаган һәм иң югары уңышларга ирешкән укучылар:

- Мингазов Рамил,
- Шәйхетдинов Минсәет,
- Мингазов Илфак,
- Каюмов Айрат,
- Гыйләҗев Айдар,
- Вәлиев Раил,
- Яруллина Резеда,
- Билалова Зөлфия,
- Вәлитова Гөлия,
- Шәйхетдинова Ләйлә,
- Әхмәтгалиева Руфилә,
- Шишкова Эльмира.

(Тәкъдим ителгән исемлек күпкә зуррак, монда исәпкә алынмаганнар үпкәләмәсеннәр иде).

***– Нинди генә эшне алсаң да, андагы уңышлар җиңел генә бирелми. Бар җирдә тырышлык, сәләт һәм, эшне ахырына җиткерү өчен, түземлек кирәк. Ә спорт өлкәсендә ничек?***

– Спортта җиңүләр яулау өчен, әле болар гына да аз. Анда, иң элек, үзеңнең бар булган кимчелекләреңне, җитешсез якларыңны, гомумән, үз-үзеңне җиңеп, югары нәтиҗәләргә ирешү өчен, рухи яктан да бик көчле булу кирәк. Кешегә иксез-чиксез мөмкинлекләр бирелгән. Шул мөмкинлекләрне кем күбрәк эшкә җигә ала, тик шундыйлар гына җиңүләр яуларга сәләтле була. Әлбәттә, монда геннар, гаиләдә һәм авыл җәмгыятендә спортка карата олы хөрмәт булуы да зур роль уйный.

***– Иске Ярмәктә физкультура һәм спортка карата элгәредән килгән олы хөрмәт яши, дигән фикерләр еш ишетелә. Моны ничек дәлилләп була?***

– Аллаһыга шөкер, авылда көчле рухлы һәм физик яктан таза халык – күпчелек санда. Анда спортка чын күңелдән бирелгән гаиләләрнең, хәтта династияләрнең дә күп булуы – гаҗәп хәл. Андыйларга авыл халкы аеруча зур хөрмәт белән карый. Мондый гаиләләр саны шактый күп. Шулай да, спортка җаны-тәне белән бирелгән, тормышта уңышлы һәм ихтирам казанып яшәгән, үзләре һәм балалары спортта югары уңышларга ирешкән гаиләләрне телгә алмыйча булдыра алмыйм.

Мәсәлән:

- Камил һәм Рушания Мингазовлар. Спортчы балалары – Рамил, Илфак, Марат, Айрат.
- Мәҗит һәм Фидания Зариповлар – Алмаз, Айсылу, Ләйсән.
- Фәһим һәм Миңсылу Шәфиковлар – Илдар, Рамилә, Юлия, Илмир, Илмира, Рузил.
- Яруллина Мәрьям апа – Рәмзилә, Рөстәм, Резеда. Спортчы оныклары – Ләйсән, Ләйлә, Руслан, Ринат, Рузил, Рузилә.
- Локман һәм Хәлимә Вәлитовлар – Гөлнара, Галия, Гөлия.
- Минсәгыйть һәм Тәнзилә Мәрдәновлар – Наилә, Ринат, Алсу. Спортчы оныклары – Артур, Реналь, Реваль.
- Расих һәм Мәсхүдә Габидуллиннар – Лилия, Ләйсән, Ринат.
- Гакыйль һәм Хәмдия Сафиннар – Гамил, Гамилә, Фәнил.
- Равил һәм Рузалия Кагировлар – Алексей, Илмира, Илназ.
- Дамир һәм Гөлфия Мөршитовлар – Оксана, Роберт, Данияр.
- Илшат һәм Руфия Әхмәтгалиевлар – Илнур, Руфилә, Руфил.
- Җәмил һәм Рузалия Сәләховлар – Филат, Айрат, Азат.
- Зөфәр һәм Әминә Рәхимовлар – Фәридә, Флюра, Зөлфәт.
- Рәис һәм Зөлфия Хөснетдиновлар – Гөлнара, Гөлия, Рәфис.
- Әсхәт һәм Сәрия Сәгыйровлар – Фәридә, Алия, Гөлия.
- Сәлих һәм Рәисә Шәрәфетдиновлар – Гөлнара, Илдар, Ленар.
- Илдар һәм Фәридә Шәрәфетдиновлар – Алинә, Диана, Софья, Люция.
- Сухроб һәм Нурия Гафуровлар – Рөстәм, Заррина, Руслан, Яна, Сайдали.

***– Гадәттә көчле рухлы кешеләрнең энергетикасы да көкрәп тора, һәм аларның гайрәте әле башкаларга да көчле тәэсир итә. Сез моңа ничек карыйсыз?***

– Әлбәттә, шулай. Кайсы гына уңышлы җитәкчене алсаң да, аларның күбесе оста спортчы булган һәм үз гомерләренә физик күнегүләрдән читләшмәгән. Моңа мисалларны да бик күп китерергә була – В.В. Путин, М.Ш. Шәймиев (трамплиннан сикерү остасы), К.А. Титов, В.Ф. Сазонов, Д.И. Азаров.

Спорт белән дус булган кешеләр янына башкалар да тартыла, һәм җәмгыятьтә аларның абруе һәрвакытта югары була.

Авылда туып-үскән кешеләр күңелендә һәм авыл тарихында тирән эз калдырырлык зур эшләр башкарган кеше белән очрашу һәм аралашу һәрвакытта эчтәлекле һәм истәлекле була. Ләкин дә ул кешенең хезмәттәшләре, аның шәкертләре белән дә сөйләшү аның турындагы уй-фикерләрне тагын да көчәйтә.

Малик Мәрдегалим улы Мөхәммәтҗанов – башлангыч хәрби әзерлек дәресе укытучысы:

– Иске Ярмәк авылы мәктәбендә укыту чорында Әсхәт Миназтдинович белән без, гел бер бәйләмдә булып, киңәшләшеп, ярдәмләшеп эшләдек. Төрле ярышларга, конкурсларга да бергә йөрдек. Ул, һәрвакытта физкультура һәм спортның кеше язмышында һәм мәктәп педагогикасы өлкәсендә никадәр зур әһәмияткә ия булуын исбатлап, бар куәткә тырышып эшләде. Укучылары: «Безгә, физкультура дәресендә «өчле»дән югарырак тамга алу өчен, бик нык тырышырга, көч куярга кирәк иде», – дип сөйлиләр. Әсхәт Миназтдинович, һәрвакытта укучыларга исәнлекнең, вакытның кадерен белү һәм үз-үзләрен кулда тоту кагыйдәләрен өйрәтеп, аларда спортка карата хөрмәт тәрбияләргә тырышты. Аның укучылары арасында спортта һәм тормышта югары уңышларга ирешкәннәрнең күплеге моның ачык дәлиле булып тора.

Иске Ярмәк авылы муниципаль администрациясе башлыгы Минсәет Низам улы Шәйхетдинов:

– Мәктәп елларында мин спорт белән актив рәвештә шөгыльләнгәнгә күрә, Әсхәт Миназтдинович белән күп кенә якты истәлекләр бәйләнгән. Ул, кешене төшенкелектән, кыюсызлыктан һәм шикшөбһәләрдән саклап, җыйнаклыкка, тыйнаклыкка һәм түземлеккә өйрәтә. Ул үз-үзеңә ышаныч һәм рухи ныклык тудыра. Тормышта болар – иң мөһим һәм кирәкле сыйфатлар. Ә җитәкчелек эшендә – бигрәк тә!

Мәктәп директоры булып эшләгән Булат Әһлиуллинның аны «Фанатик!» дип бәяләве дә чынбарлыкка туры килә. Әсхәт абый балалар белән генә түгел, аларның ата-аналары белән дә зур

## Тренерның укучылары



*Әхмәтгалиева Руфилә - табиб*



*Билалова Зөлфия -*
*сәүдә өлкәсе хезмәткәре*



*Вәлиев Раил -*
*Ямал-Ненец автоном округында*
*өлкән инженер*



*Вәлитова Гөлия -*
*җир төзү инженеры*



*Каюмов Айрат -*
*инженер-механик, хәзер юрист*



*Мингазов Рамил - Камышлы районының*
*Гражданнар оборонасы һәм гадәттән*
*тыш хәлләр идарәсе башлыгы*



*Мингазов Илфак - Пугачёв вертолёт*
*училищесын тәмамлап,*
*хәрби очучы булып хезмәт итә*



*Шәйхетдинов Минсәет -*
*Иске Ярмәк авылы башлыгы*



*Шәйхетдинова Ләйлә -*
*туризм һәм сервис өлкәсендә*
*менеджер*



*Шишкова Эльмира - студент*



*Яруллина Резеда - теш табибы*

эш алып барды. Мәсәлән, кыш көннәрендәге бураннарда, трактор чанасына, машина әрҗәләренә утырып, ярышларга күп йөрергә туры килде. Бу очракта ул, өстенә зур җаваплылык алып, ата-аналарга балаларын исән-сау килеш алып кайтырга вәгъдә биреп, нарасыйларын ярышларга җибәрергә ничек тә күндерә белә иде.

Спорт, күп вакытны алып, бердәм дәүләт имтиханнарын бирергә комачаулый, диючеләргә, киресенчә, аның балага, вакытның кадерен белеп, аны файдага куллынырга өйрәтүен аңлата белә иде. Спортта уңышлы кеше тормышта да бөтен яклап уңышлы була. Менә шуны да ул күпләргә яхшылап төшендерә белде. Безнең мәктәптә укыган егетләрнең барысы да, армиягә тулы әзерлек белән барып, уңышлы хезмәт иттеләр. Аларның командирларыннан килгән күп мактау хатлары гел иртәнге «линейкаларда» укыла иде. Тагын шуны да әйтергә кирәк, спорт командасына керүчеләрнең тәртибе үрнәкле, укуы алдынгы булырга тиешлеге мәктәптәге язылмаган төп закон иде. Бу хакта ул завучтан, класс җитәкчеләреннән даими сорашып-белешеп торды. Кемгә булса да никтер спортзалга керү юлы ябыла калса, бу аның өчен зур хурлык санала иде. Алтмыш сигез яшенә кадәр физкультура дәресен укыту өчен дә аңа никадәр көч-куәт, үз эшенә тулысынча бирелгәнлек тә кирәк булгандыр. Олы яшьтә, чаңгыда шуар яисә гимнастика снарядларында күнегүләр ясар өчен, никадәр ихтыяр көче, үҗәтлек тә кирәк бит әле! Тагын бер нәрсә игътибарга лаек – укучының мәктәптә спорт өлкәсендә ирешкән уңышлары уку елларында гына бүленеп калмасын, ул аларга гомерлек юлдаш, ярдәмче булсын өчен дә, ул күп хезмәт куйды.

Мәсәлән, авыл яшьләренең өйләренә барып, ул аларны спортзалга йөрергә һәм төрле спорт ярышларында катнашырга күндереп, көчле командалар туплады. Ул командаларның саны унга җиткән чаклар да булды.

Камышлы муниципаль районы администрациясенең спорт һәм туризм бүлеге инструкторы Гали улы Марат Шәвәлиев:

– Әсхәт абый Гыйләҗевның үз эшенә карата булган җаваплылыгы, булдыклылыгы, җаны-тәне белән бирелгәнлеге, үз-үзенә һәм башкалага карата да булган таләпчәнлеге һәм шулай ук аңардагы уңай кешелек сыйфатлары – болар барысы да тормышта сирәк очрый торган күренеш.

Иске Ярмәк авылында укучы балалар саны, Камышлы мәктәбенә караганда, күпкә ким булуга да карамастан, аның спорт командалары, һәрвакытта камышлылар-га «конкурент» булып, беренчелекне чиратлап яулап, җиңүләрне бүлешеп ярыштылар.

Әсхәт абый һәр уку елы ахырында: «Быел иң яхшы, оста спортчыларым мәктәпне тәмамлап китәләр. Елдан-ел укучылар саны да кими бара. Киләсе елга нишләрмен инде?!» – дип ачы кайгыга кала иде. Ә үзе, алдагы ярышларга шундый ук әзерлекле, оста, көчле рухлы һәм җиңүләр яуларга «көйләнгән» спорт командалары алып килеп, күп вакытта беренчелекне яулыйлар иде.

Мондый җиңүләр җиңел генә бирелми шул. Тулысынча эшкә бирелгәндә, шәхси тормышка вакыт аз кала, һәм гаиләгә әһәмият азайганда, әле ниндидер аңлашылмаучанлык та булмыйча калмый. Физрук эшендә кеше психологиясен, физиологиясен, аңа бирелгән мөмкинлекләрне ачыклап эш итү – иң мөһим мәсьәлә. Баланың күңелен үстереп, аның рухын ныгыту кебек алымнарны оста кулланганда гына, җиңүләр яулана. Спортта: «Җиңүгә ышаныч кеше күңелендә көрәшкә, ярышка кадәр үк тупланганда гына, ул аңа ирешә ала!» – дигән әйтем бар. Балаларда шундый ышаныч тудыру өчен, Әсхәт абый бар көчен куеп эшләде. Аның эше яшәү рәвеше иде. Шуңа да аңа «Отличник народного просвещения», «Методист по спорту» кебек мактаулы һәм дәрәҗәле исемнәр бирелгән. 2002 елда ул федераль дәрәҗәдәге хезмәт ветераны исеменә лаек булган. Ә шулай да, төп бәяне аңа үзе тәрбияләгән, күпсанлы спорт сөюче укучылары бирәләр.

Әсхәт Гыйләҗев тәрбияләгән укучылары арасында физкультура укытучысы һөнәрен сайлаган һәм бу өлкәдә уңышлы эш алып барган кешеләр дә бар.

Мәсәлән:

- Шәрипов Минзәки,
- Сафин Тәлгать,
- Яруллин Рөстәм,
- Шагиев Илшат,
- Ганниев Илдар,
- Гыйләҗев Айдар.

# САМАРЦЫ В ЗОЛОТОЙ КНИГЕ ПОЧЕТА УЛЬЯНОВСКОЙ ОБЛАСТИ

***В июле текущего года исполнится 30 лет учреждению «Золотой книги Почета Ульяновской области», в которую вносятся фамилии жителей региона, удостоенных звания «Почетный гражданин Ульяновской области». За прошедшее время на страницах фолианта появилась информация о 236 лицах, которым за их заслуги присвоили это высшее региональное звание. Среди них представлены 18 наших соплеменников, восемь из которых являются уроженцами самарской земли, именовавшейся в 20–30-е годы прошлого столетия и губернией, и областью, и краем. О некоторых наших земляках из упомянутой «восьмерки» мы и поведем рассказ.***

**Рашид ШАКИРОВ**



*Д.И. Шарипов, 1996 год*

Иначнем его с **Д.И. Шарипова,** занесенного в Золотую книгу в 1996 году. К тому времени он был ветераном труда и общественным деятелем, который с 1968 по 1991 год работал вторым, а затем первым секретарем Чердаклинского райкома КПСС, неоднократно избиравшимся депутатом районного и областного Советов народных депутатов.

Дамир Исмагилович родился 25 октября 1931 года в деревне Старая Тюгальбуга (тат. – Иске Төгәлбуа) Кошкинского района Средневолжского края, административным центром которого являлся город Самара (ныне это село находится в Новомалыклинском районе Ульяновской области). Его отцом стал учитель местной школы Исмагил Гилязович, выходец из батрацкой семьи, проживавшей при его появлении на свет в деревне Татарский Калмаюр (тат. – Татар Колмаеры авылы) Ставропольского уезда Самарской губернии (в настоящее время – село Чердаклинского района Ульяновской области). А мамой нашего героя была уроженка соседнего села Поповка Хусна Джаляледдиновна.

Во второй половине 30-х годов учитель с семьей перебрался в село Елховый Куст Новомалыклинского района Куйбышевской области, где был назначен директором школы, а после возвращения по ранению из первой отправки на фронт еще и избран председателем местного колхоза. Дамир часто ходил с отцом в поле и исподволь постигал азы крестьянского труда и опыта, что сказалось позже при выборе юношей профессии. В этом селе он стал школьником.

В год гибели Исмагила абый при форсировании Днепра в ходе Великой Отечественной войны Хусна ханум с шестью детьми вернулась в Татарский Калмаюр, отошедший к только что образованной Ульяновской области. Мама пяти дочек и одного сынка полагала, что на малой родине мужа будет легче пережить военное полуголодное лихолетье. Но и здесь их ждали проблемы с продуктами. По воспоминаниям Д. Шарипова, к весне последнего года войны в их доме не было ни крошки. И тогда подросток отправился по бездорожью в соседнюю Андреевку, где руководителем колхоза умело работал Т.А. Чагров, который в то время вывел хозяйство в число областных передовиков и в начале 1948 года станет Героем Социалистического Труда. Дамир обрисовал ситуацию Терентию Алексеевичу и вернулся домой с узелком муки.



*С женой*

Несмотря на трудности бытия и опасения отца, изложенные в письме по пути на фронт во второй раз, мальчик продолжил посещать школу и на родине главы семьи. А написал Исмагил абый в декабрьском послании жене 1942 года следующие строчки: «Изиля (старшая дочь. – Прим. Р.Ш.) и Дамир, наверное, не смогут продолжить учебу, сердце болит за них. ... Я прошу тебя, дай детям хорошее воспитание, Дамира с рук не выпускай. Если захочет, пусть идет в 4-й класс учиться».

Опасался за сына красноармеец Шарипов напрасно. Погружался тот в мир знаний старательно и успешно, называя самой своей любимой учительницей Х.С. Сайфетдинову-Шаммасову – просветительницу и поэтессу, которая с 1908 года преподавала в школе Татарского Калмаюра. У этой уроженки Самарской губернии в 1913 году в Казани вышел

первый сборник стихов «Кызлар бакчасы» («Девичий сад»), а через пару лет – следующий под названием «Таң җиле» («Рассветный ветер»). В советские годы Хадича ханум всецело отдалась общественной и педагогической работе. В памяти нашего героя (да и не только его) она осталась удивительно светлым, добрым человеком.

В 1949 году Дамир и Изиля окончили среднюю школу, и им необходимо было решить: кому поступать на очное отделение вуза. По совету мамы – колхозной доярки и прирожденного педагога, сумевшей поднять всех детей, Изиля уехала в Старую Кулатку и стала учительницей начальных классов, а Дамир – студентом агрономического факультета Ульяновского сельскохозяйственного института (УСХИ). Условия послевоенной жизни заставляли его и однокурсников работать по выходным дням грузчиками на железнодорожной станции или пристани, чтобы обеспечить себя едой и одеждой. Тем не менее в 1954 году он успешно окончил УСХИ и по распределению отправился агрономом в колхоз «Красная Заря» Старокулаткинского района.



*Ульяновский сельхозинститут, 40-е годы*



*Получает Красное знамя ЦК КПСС, Совмина СССР, ВЦСПС и ЦК ВЛКСМ, 1973 год*

Здесь Шарипов проявил себя не только грамотным специалистом, но и умелым организатором, которого избрали секретарем комсомольской организации села. Вскоре старательный и ответственный Дамир стал главным агрономом Зарыклейской МТС. Потом его утвердили главным агрономом районного управления сельского хозяйства. Любящий землю специалист и усердный труженик проявил свои лучшие качества и на этом посту. Поэтому его ожидали очередные повышения. Сначала Дамир Исмагилович возглавил районное управление сельского хозяйства, а позже был выдвинут на должность первого заместителя председателя райисполкома.

Но виды на него, можно предположить, были большие, и поэтому в начале 60-х первого зампреда РИКа отправили на учебу в Ленинградскую высшую партийную школу, которая вела подготовку и повышение квалификации партийных и советских кадров. Окончив ее в 1964 году, герой статьи вернулся в Старую Кулатку и более трех лет работал вторым секретарем районного комитета КПСС.

А в мае 1968 года его перевели на такую же должность в Чердаклинский райком партии. Здесь Шарипову довелось трудиться под началом первого секретаря райкома, фронтовика Ф.И. Балагурова, который по праву считался грамотным руководителем, выведшим район в число лучших в области. «С ним в одной упряжке мне довелось работать почти четыре года, – вспоминал позже Дамир абый. – Когда же он в декабре 1971 года пошел на повышение, то коммунисты района на пленуме на должность избрали меня. И с этого момента я бессменно проработал первым секретарем ровно двадцать лет».

Добавим, что не просто отработал, а ударно и эффективно. Постоянно заботился о росте руководящих кадров, продвигая способнейших и обязательно «пропуская» их через практику партийной деятельности. При обновлении руководства старую гвардию не «списывал», давая ей возможность применять где-то имевшиеся знания и опыт. Своих «первых лиц» хозяйств и организаций знал досконально, потому что регулярно посещал трудовые коллективы.

Вот что вспоминал в 2021 году о нашем герое почетный гражданин Чердаклинского района З.С. Хакимов: «Когда я возглавлял колхоз «40 лет Октября», то уже привык к тому, что первый секретарь РК КПСС приезжал к нам не реже трех раз в год. Во время весеннего сева и уборки урожая он, побывав во всех бригадах и ознакомившись с организацией работ и качеством их выполнения, подводил итоги. Обедал не в центральной столовой, а на полевом стане, вместе с механизаторами. Невольно возникала беседа, которая нередко велась на татарском языке, позволявшая колхозникам, не смущаясь, задавать любые вопросы. И глава района не уходил от ответов. А в зимние периоды он осматри-

вал скотные дворы всех трех наших ферм, запросто общаясь при этом с животноводами и интересуясь их положением и проблемами».

При Шарипове Чердаклинский район не только удержал планку Балагурова по многим показателям, но и стал известен в масштабах страны. Подтверждение тому – четыре Красных знамени союзного значения и одно – областного, которые за успехи в социалистическом соревновании были оставлены чердаклинцам на вечное хранение. Неоднократно район получал и переходящие знамена. Благодаря усилиям Шарипова, его команды и местных тружеников в районе стала явью прочная кормовая база, были созданы восемь животноводческих комплексов, крупнейшая в области птицефабрика «Ульяновская», механизированы все животноводческие фермы. Развивалась и сеть социальных объектов: открылись пять новых средних школ и 12 домов культуры, а также медицинские профилактории и фельшерско-акушерские пункты, общественные столовые и красные уголки. На 200 километров увеличилась протяженность асфальтированных дорог. По просьбе мусульман в райцентре был выделен участок для возведения мечети.

Активно строились и производственные здания: мастерские и гаражи, теплые стоянки для сельхозмашин и механизированные зернотоки, помещения для скота. На радость сельчан росли и жилые дома – ежегодно сдавалось до 700 благоустроенных квартир.

Запомнился наш герой своим современникам не только как знаток сельскохозяйственного производства, умеющий находить общий язык с людьми, но и как руководитель, который всегда прислушивался к дельным советам и с уважением относился ко всем, с кем трудился и общался. Отсюда и встречное уважение чердаклинцев (и не только их), и отзывы о нем с особой теплотой.

Дамир Исмагилович немалое сделал для земляков и по общественной линии, являясь в течение 8 лет членом бюро обкома партии и 20 лет подряд избираясь депутатом областного Совета депутатов. В этом Совете он в 1987–1991 годах был председателем комиссии по межнациональным и конфессиональным делам, то есть стоял у истоков создания в регионе национально-культурных автономий (НКА), а также национальных газет и телепередач.

Заслуги Шарипова были отмечены орденами Ленина, Трудового Красного Знамени и «Знак Почета», а также медалями «За трудовую доблесть», «За доблестный труд. В ознаменование 100-летия со дня рождения В.И. Ленина». Его вклад в развитие района зафиксирован



*Д.И. Шарипов*



*Открытие памятной доски в Чердаклах, 2019 год*



*Ленинградская ВПШ, Таврический дворец, 1960-е годы*



*День памяти Д. Шарипова в Чердаклинском районе, декабрь 2018 года*

и двумя медалями ВДНХ СССР (золотой и серебряной). Добавим, что Дамир ага – дважды почетный гражданин – и области, и Чердаклинского района.

Уйдя на заслуженный отдых, наш пенсионер не свернул свою общественную деятельность. Он входил в исполком областной татарской НКА, в совет районной татарской НКА и в президиум районного Совета ветеранов. А в 2006–2008 годах был членом Общественной палаты Ульяновской области I созыва. Не отказывал Шарипов и в советах руководителям района и хозяйств, когда те обращались за помощью. Контакт с ними не обрывался.

Как следствие – не прерывался и поток почестей. Высшую награду Всемирного конгресса татар – медаль «За большие заслуги перед татарским народом» (под № 10) – Дамиру ага вручили в Казани в 2007 году. А в честь его 75-летия Законодательное Собрание Ульяновской области наградило героя статьи почетной грамотой. С того же года (2006-го) имя этого заслуженного человека с гордостью носит его родная Татарско-Калмаюрская средняя школа. Свою последнюю, видимо, награду он получил в ноябре 2015 года – памятный знак Губернатора Ульяновской области «В память о праздничном параде в Ульяновской области в день 70-летия Победы в Великой Отечественной войне 1941–1945 годов».

Несмотря на солидный возраст Д. Шарипов ежедневно занимался физическим трудом в саду-огороде, читал художественную и историческую литературу (дома была солидная библиотека), интересовался политикой. Очевидцы говорят, что он чисто говорил и красиво пел на родном языке. Более полувека Дамир эфенди прожил в любви и согласии с женой Рясимей Талиповной, с которой вырастил и воспитал двух сыновей – Ильдара и Шамиля. Они стали опорой отца, когда в 2015 году тот овдовел. Радовали нашего героя и трое внуков. Но через три года он следом за супругой ушел в иной мир.

Например, их принято до сих пор считать «рассадниками этнической преступности», что в целом не верно – раз в чайнатауне живут в основном китайцы и выходцы из прочих стран Дальнего Востока, то кем и быть тамошним преступникам – неужели белокурым блондинам? Также не китайцы, не пуэрториканцы и не итальянцы «изобрели» организованный бандитизм – один из «боссов» итальянской мафии вспоминал, что в США они встретили развитую местную криминальную среду, которой заправляли евреи и ирландцы. Единственное преимущество, которые дают чайнатауны и прочие анклавы для нарушителей закона, – стойкое недоверие местных жителей к полиции и боязнь быть отвергнутым сообществом за «предательство», знаменитый «закон молчания». Но, как показывает та же «итальянская мафия в Италии», причины и тут кроются не в национальном факторе, а в особенностях социального развития, этнопреступники просто привозят на новую территорию свои старые обычаи.

Несомненный же плюс анклавов в том, что они позволяют переселенцу из другой страны обустроиться с минимальными потерями и дискомфортом – он попадает в привычную языковую и информационную среду, городскую планировку, сервис, культурные, религиозные и бытовые реалии… В этом же состоит и главная опасность анклавов – они тормозят, причем сильно, целыми поколениями, адаптацию в новом обществе, сводя потребность в изучении иной культуры и традиций другой страны к минимуму. Нет числа примерам, когда живущие в чайнатауне мигранты, особенно старшего возраста, вообще не учат чужой язык и предпочитают за границами поселения не бывать.




Впрочем, некоторые видят в этом «плюсы системы» – в такой среде сохраняются традиции и обычаи родного народа, которые в чужой стране, естественно, нигде более не культивируются. Раздаются даже голоса за создание искусственных анклавов – компактных поселений людей определенных национальностей для «сохранения корней и идентичности». Например, эта проблема актуальна в современной России, где «национальный вопрос» власти хоть как-то «делают вид, что решают» только в автономных регионах, но не за их пределами. И «этнические поселки» – это реакция на отсутствие национального образования, создания реальной комфортной полиэтнической среды и отсутствие какой-то вменяемой (а не на уровне деклараций) борьбы с ксенофобией в нынешнем РФ.

Но такая «искусственная анклавизация», как и система анклавов вообще в сфере сохранения родной культуры, – палка о двух концах. Она лишь консервирует традиции и обычаи в том виде, которые существовали до переселения – никакой особой среды для развития и совершенствования в небольших поселениях нет. Глобализация, стандартизация и научный прогресс – явления, которые заставляют развиваться любое общество, европейское ли, азиатское, африканское, христианское, исламское, буддистское, традиционно-консервативное или либерально-модернистское. От жизни вокруг не скрыться за запертыми воротами. А проблему сохранения и, прежде всего, развития культуры и национальной идентичности в этих условиях для людей, оторванных от исторической родины, могут решить другие инструменты, более тонкие и «энергозатратные». А что поделать – нельзя двигаться в ногу со временем, стоя на одном месте…

# ҺӘР БАЛА ҮЗ РИЗЫГЫ БЕЛӘН ТУА



***Һәр елны җәйнең беренче көнендә халыкара дәрәҗәдәге бәйрәм — Балаларны яклау көне уза.***

***Кешенең язмышы тулысынча үз кулында, диләр. Әмма олы тормышның нинди булуына йогынты ясый торган күп кенә нәрсәләр балачакның ничек үтүенә бәйле, чөнки бала бу дөньяга тулысынча яклаучысыз һәм ярдәмчесез килә. Бары тик якыннар мәхәббәте сабыйга исән калу гына түгел, ә тормышның барлык шатлыкларын һәм кайгыларын белү мөмкинлеге бирә. Кызганычка, балалар дөньясы мәшәкатьсез түгел. Нәкъ менә балаларның күпкырлы булуы һәм аның актуаль проблемалары сабыйларга багышланган бәйрәмне оештыру өчен сәбәп булган.***

***Эльмира САЙФУЛЛИНА***

1 июнь — Халыкара балаларны яклау көне күп илләрдә билгеләп үтелә. Ә беренче тапкыр ул рәсми рәвештә 1950 елда бәйрәм ителә башлый. Беренче булып, балачактагы актуаль проблемалар белән бәйле сораулар 1925 елда Женевада узган Бөтендөнья конференциядә хатын-кызлар тарафыннан күтәрелә. Әмма бу идея



киң җәмәгатьчелектә зур яклау тапмаган.

Балалар иминлеге мәсьәләләре җәмәгатьчелек алдында Бөек Ватан сугышының соңгы елларында кискен тора. Шуңа күрә 1949 елда хатын-кызлар конгрессы махсус бәйрәм оештыру идеясын кабат тәкъдим итә. Конференциядә планетаның барлык балаларына һәм яшүсмерләренә бәхетле балачак һәм тынычлык өчен көрәшкә бөтен көчне юнәлтү турында бердәм карар кабул ителә.

Менә инде 70 елдан артык әлеге бәйрәм күп кенә илләрдә бик купшы һәм зур әзерлек белән билгеләп үтелә. Башкача булырга да мөмкин түгел. Чөнки балалар – безнең киләчәгебез, тормышыбызның мәгънәсе. Шулаен шулай дибез дә, әмма арабызда башкача уйлаучы, үзләрен күбрәк яратучы олылар да җитәрлек, кызганычка. Алар, гаилә коргач та, бала табарга ашыкмыйлар яисә бер бала табалар һәм шуның белән вәссәлам. Янәсе, тормыш авыр, бөтен нәрсә кыйммәт. Балага лаеклы тормыш бирә алмыйлар, ярлылар санын арттырасылары килми. Нәтиҗәдә авылларда мәктәпләр ябыла, мәчетләребездә татар мөселманнары саны елдан-ел кими, милләтебез югала бара...

Россиядәге демографик хәлне үзгәртер өчен, хөкүмәт төрле ярдәм чаралары куллана, ел саен Россия президенты үрнәк булырлык күп балалы гаиләләрне «Ата-ана Даны», «Герой-ана» ордены белән бүләкли. Минемчә, бу бүләкләр бик урынлы. Бер-ике балаларын үстерергә дә авырсынучы ата-аналар белән чагыштырганда, бу гаиләләр, чыннан да, герой исеменә лаеклар.

Соңгы халык санын алу мәгълүматлары буенча, Россиядә 1,7 миллион кимендә өч балигъ булмаган балалы гаилә бар. Шуларның 1,3 миллионы — әнисе һәм әтисе белән, 344 меңе — әнисе белән генә, 60 меңе әтисе белән



генә яши. Чынлыкта, күп балалы гаиләләр күбрәк. Аларның кайберләрендә әле генә 18 яшь тулган балалар бар, кайберләрен әнисе белән этисе түгел, ә башка туганнары тәрбияли.

Өлкәдә яшәүче таныш-белешләрне генә барлый башласаң да, араларында күп балалы, үз балалары үсеп җиткәч, тәрбиягә бала алучы гаиләләр аз түгел.

Мәкаләмне дә шундый, күпләребезгә үрнәк булырлык Минтаһир һәм Затия Гайнетдиновлар гаиләсенә багышларга булдым.

Затия һәм Минтаһир – авылдашлар, әмма Затиянең яшь чагы чит җирләрдә уза. Берникадәр вакыттан соң, өч улын кочаклап ялгыз калган яшь хатынны язмыш җилләре кабат туган якларына алып кайта. Менә шул вакытта ул үзенең чын бәхетен – Минтаһирны очрата. Алар, өйләнешеп, матур гына гаилә корып җибәрәләр, ике кызлары һәм бер уллары туа. Шулай итеп, Гайнетдиновлар гаиләсендә алты бала шау-гөр килеп, тату гына үсеп җитәләр. Олылары – Рафаэль, Дамир, Илнур, Самарга китеп, белем алып, үз көннәрен үзләре күрә башлыйлар. Ул арада кечкенәләре дә үсеп җитәләр. Ленар, 9 сыйныфны тәмамлагач, Самарның Җәмигъ мәчете каршында эшләп килүче «Нур» мәдрәсәсенә укырга керә, 10 – 11 сыйныфны «Яктылык» мәктәбендә тәмамлый. Гүзәл белән Гөлинә дә туганнары янына якынрак – Самар уку йортларын сайлыйлар. Фатирлар арендалап торуы бик кыйммәт булганга, Минтаһир белән Затия, гомер иткән нигезләрен - авылдагы зур өйләрен калдырып, Самарга күченәләр һәм ипотекага фатир сатып алалар.

- Балалар да күз алдыбызда булырлар, кайтуларына ашарга да әзер булыр, дип тә уйладык инде, - ди Затия ханым. – Арендага түлисе акчаны ипотекага түлибез хәзер. Оныкларыбыз белән дә, балаларыбыз белән дә еш күрешү мөмкинлеге дә бар.

Әйе, беренче карашка, башка ишле гаиләләрдән бернәрсәләре белән дә аерылмыйлар Гайнетдиновлар. Ә шулай да...

Моннан 6 ел элек Затиянең ялгыз танышы яңа туган сабыен бала табу йортында калдырырга карар кыла. Бу хәбәрне белеп алган 6 бала анасы үзенә урын таба алмый, ничек инде нарасыйны балалар йортына бирәсең? Тормыш иптәше һәм үсеп җиткән балалары белән киңәшләшкәннән соң, Гайнетдиновлар сабыйны үз канатлары астына алырга булалар.

***- Үз балаларыгыз күптән мөстәкыйль тормыш алып баралар. Биш көнлек сабыйны алырга ничек курыкмадыгыз? Аннан соң, 6 балагыз, оныкларыгыз булган бит инде ул вакытта...***

- Нәрсәдән куркырга соң? – диде Затия ханым, бераз дәшми торгач. – Мин ул вакытта нарасыйны ятим итмәү турында гына уйладым. Яңа гына дөньяга аваз салган сабыйга гаилә җылысы, ата-ана мәхәббәте бирү, аны ятимлек ачысыннан яклау турында кайгырттым.

Азалиябезне (тәрбиягә алган кызның исеме) тәрбиягә алу





юк, Аллаһыга шөкер. Барысы да тәртипле, балаларын үстерәләр. Безнең 5 оныгыбыз бар. Иң олысы – Рифатыбыз Белгород өлкәсендә армия хезмәтен үтә. Балаларыбыз да, оныкларыбыз да татарча сөйләшәләр, милли гореф-гадәтләребезне, бәйрәмнәребезне яхшы беләләр һәм үтиләр. Азалиябезне дә шул ук өлге белән үстерә алырбыз, дип ышанабыз, - ди бәхетле ана, оныгы Дилә һәм төпчеге Азалияне башларыннан сыйпап.



җиңел генә булмады, төрле кыенлыклар, бюрократия проблемалары да булды. Әмма, баланы үз канатыбыз астына алу теләге бик көчле булганлыктан, без барысын да җиңеп чыктык, Аллаһыга шөкер. Олы балаларым Азалияне бик яраталар, беренче көннән үк миңа аны үстерешергә ярдәм ителәр. Алар барысы да киң күңелле, ярдәмчелләр.

***- Хәзерге заман яшьләре бала табарга куркалар бит. Аны үстерергә акча күп кирәк, бала үстерүне карьера төзү белән бергә алып баруы кыен, дип зарланалар. Ә сез ничек уйлыйсыз?***

- Һәр бала үз ризыгы белән туа. Гаиләдә бала туса – аны туендырырлык, үстерерлек мөмкинлекләре дә табылачак. Мин моны үз тәҗрибәмнән чыгып әйтәм. Азалияне алганда, яшебез шактый иде инде. Шуңа карамастан, Аллаһы Тәгалә эшен дә, исәнлеген дә бирә безгә. Кечкенәбез балалар бакчасына, модельләр мәктәбенә йөри, кул эшләре белән мавыга. Без аның кызыксынуларына игътибар биреп, аны киләчәккә ышанычлы адымнар белән атларлык кеше итеп тәрбияләргә тырышабыз. Бүгенге көндә 5 балабызның да (моннан 4 ел элек Дамирым йөрәк өянәгеннән үлеп китте) битебезгә кызыллык китергәннәре

Кызларның Затия ханыма сеенуларына карап соклandым, һәм бу гаиләдә бары тик мәхәббәт, шатлык һәм бәхеткә генә урын табылачак, дип уйлап куйдым.

Әңгәмә барышында ниндидер авырлыклар, проблемалар, акча җитмәүлек турында бер генә сүз дә ишетмәдем. Затия Гайнетдинова дәүләт тарафыннан күрсәтелгән ярдәм чараларын атап үтте, тормыш иптәше Минтаһирның тырышып эшләвен искә алды. Әмма кыенлыклар турында сүз ишетелмәде. Фатир эчендәге чисталык һәм пөхтәлекне, заманча җиһазларны, Азалиянең күпсанлы уенчыкларын күреп, гаиләнең әйбәт кенә яшәвенә инандым.

Менә бит, бу гаиләгә карап, нәтиҗә ясап була, минемчә. Авырлыклардан куркучыларга үрнәк булырлык гаиләләр шактый. Камышлы районын гына алсак та, әллә никадәр андый гаиләләр. Алай гына да түгел, тәрбиягә алган башка милләт балалары чип-чиста татарча сөйләшәләр, мәчеттә укып, дини гыйлем алалар, мәктәптә дә яхшы укыйлар, спорт-сәнгать ярышларында да алдынгылар рәтендә. Ул балаларның көләч йөзләренә карап, аларның бик бәхетле һәм шат булуларын аңлавы кыен түгел.

Үзләренең 4 – 5 баласы янына 2 -3 ятимне дә сыйдырган, аларга лаеклы тәрбия биргән, җан җылысын бүләк итеп, милләтебезне, динебезне, мәдәниятебезне саклап калырлык шәхесләр үстергән күп балалы ата-аналарны герой, димичә булмый.

Ә сез минем белән килешәсезме?



# «БӘХЕТЛЕ ГАИЛӘНЕҢ НИГЕЗЕНДӘ САБЫРЛЫК ЯТА»

*“Бигрәк пар килгәннәр!” – дип соклан-мый мөмкин түгел Илшат белән Юлия Залятдиновларга. Бер-бер-сен яраталар, хөрмәт итәләр, бер-берсенең кадерен беләләр алар. “Юлиянең зәңгәр күзләре мине гомерлеккә әсир итте”, - дип елмая Илшат.*

*Миләүшә Газимова.*

Никахлашканнарына 18 ел үтеп киткән инде, ә Илшат белән Юлия әйтерсең лә кичә генә өйләнешкәннәр. Бер-берсенә гашыйк күзләр белән карыйлар, мәхәббәт ялкынын сүндермичә, аны саклап яшиләр.

Залятдиновлар – үрнәккә куярлык күркәм татар гаиләләренең берсе. Икесе дә дин юлында, матур итеп, саф татар телендә сөйләшәләр, дүрт бала тәрбиялиләр, ачык йөзле, әдәпле, тәрбияле кешеләр.

Камышлыда туып-үскән Илшат әфәндегә 38 яшь. Юлия – Самар кызы, ул иреннән бер яшькә кечерәк.

Язмам геройлары Татар бистәсендә (Зубчаниновка) йорт салып кергәннәр.



Илшат, “КамАз” машинасы сатып алып, вак таш, ком ташый. Ул Уфада “Лалә тюльпан” ислам мәдәни-мәгариф үзәгендә белем алган, Татар бистәсендәге “Болгар мирасы” мәчетендә имам Расих хәзрәт Вакказовның урынбасары.

Юлия ханым – хуҗабикә, яшелчә һәм чәчәк үрентеләре (рассада) үстереп сата, бакчачылык белән шөгыльләнә, кул эшләре белән мавыга - бәйләм бәйли, чигү чигә. Ире һәрвакыт диярлек эштә булгач, әлбәттә инде, бала тәрбияләү дә күбрәк аның өстендә.

- Нарасыйларыбыз – тормышыбыз мәгънәсе, Аллаһы Тәгалә биргән иң зур бүләк, бәхет-сәгадәт, - диләр балаларын өзелеп яратучы, һәрберсенә тиешле игътибар биреп үстерүче Залятдиновлар.

Олы уллары егет булган инде, аңа унҗиде яшь икән, кече малайларына – җиде яшь. Кызларына исә сигез һәм җиде яшь тулган.

***- Хәләл җефетегезнең нинди сыйфатларына кызыгып өйләндегез?*** – дип кызыксындым Илшат әфәндедән.

- Яшь вакытта бит әле хыялыйлык, романтика хөкем сөрә. Сыйфатларына караганда, егетләр башта кызның тышкы кыяфәтенә игътибар бирә, чибәрлегенә кызыга. Ул чакта миңа – 19, Юлиягә 18 яшь иде.



Ә инде еллар уза торган саен җитдиләнә төшәсең, тормышка башкача карый башлыйсың. Хатының иң якын кешеңә әйләнә, аңа карата хөрмәт тагын да арта, балаларыңның әнисе буларак, үзенә рәхмәт хисләрең көчәя.

Хәләл җефетем – минем ышанычлы терәгем. “Ирне ир иткән дә – хатын, чир иткән дә – хатын”, диләр. Юлия итагатьле, сүземне тыңлый, дәрәҗәмне төшерми. Бик яхшы ана ул. Балаларыбызга тиешле тәрбия бирә, үзләрен һәрьяклап карый. Аллаһыга шөкер, тышкы яктан да, эчке дөньясы да матур.

***- Ә сез ирегез турында ни әйтер идегез?*** – дип Юлиягә мөрәҗәгать иттем.

- Үз сүзендә тора, вәгъдәсен үти торган кеше ул. Без - хатын-кызлар өчен бу – ир-аттагы иң мөһим сыйфатларның берсе. Җаваплы, җыйнак. Илшат бөтен мәсьәләләр буенча да минем белән киңәшә, аңа минем фикерем мөһим. Гаиләсен саклап-яклап яши, гомумән, безнең өчен ул - ышанычлы таяныч, терәк, һәм мин аңа барысы өчен дә рәхмәтлемен.

**- Юлия, балаларыгызны тәрбияләүдә нәрсәгә өстенлек бирәсез?**

- Мин аларны исраф итмәскә өйрәтәм. Динебездә бу – тыелган нәрсә. Исраф – акча, мал һәм Аллаһы Тәгалә тарафыннан безгә бирелгән кадерле гомерне, вакытны, нигъмәтләрне сәбәпсезгә, файдасызга туздыру яки әрәм-шәрәм итү. Ул-кызларыбызга шуны гел аңлатып киләм, Раббыбыз биргән һәрнәрсәнең кадерен белегез, дип туглап торам.

Шулай ук аларны хезмәткә өйрәтеп үстерәбез. Һәрберсенең өйдә, йортта үз вазифалары бар.

Японнарда: "Әгәр әти-әниләре эшләгәндә, балалары ял итә икән, оныклары хәер сораячак", дигән тирән эчтәлекле мәкаль бар.

Нарасыйларга артларыннан савыт-сабаны юып кую, тузан сөртү һәм башка шундый гади эшләрне башкару авыр түгел бит. Бу аларда бәләкәйдән хезмәткә мәхәббәт тәрбияли. Эштә чыныгып, аны сөяргә өйрәнеп үскән кешеләр дөнья көтүчән булалар, тормышта югалмыйлар, дип саныйм.

Улларыбыз-кызларыбызны, үзара тату булыгыз, сез – дөньяда бер-берегезгә иң якын кешеләр, ярдәмләшеп, кадерләшеп яшәргә кирәк, дип тәрбиялибез.

Алда әйтеп үткәнемчә, Залятдиновлар - дин таләпләрен үтәүчеләр исемлегендә.

- Әбием – әтиемнең әнисе минем иң беренче остазым иде. Ул безгә кечкенәдән исламга мәхәббәт тәрбияләде. Аның намаз укыганын, ураза тотканын күреп үстек без.

Аннары Гали авылыннан Камышлыга Төркиядә укып кайткан Расих хәзрәт Вакказов килде. Ул безнең мәчеттә имам булып эшләде. Нәкъ аның һәм мөтәвәллиятебез әһелләре тырышлыгы белән авылыбызда мәдрәсә ачылды. Мин шунда белем алдым. Ул чакларда миңа бер 13 – 14 яшьләр булгандыр. Гомумән, ул елларда биредә бик күп бала укыды.

Мин Расих Вакказовка бик рәхмәтлемен. Аллаһы Тәгалә, миңа һидәят биреп, дин юлына бастырса, Расих хәзрәт, безгә гакыйдәне



аңлатып, тирән гыйлем биреп, иманыбызны тагын да көчәйтте, дип сөйли Илшат әфәнде.

- Миңа да исламга мәхәббәт балачактан сеңеп калган, - дип сүзгә кушылды Юлия. – Әтиемнең әнисе безнең белән бергә яшәде. Бик дини кеше иде ул. Аның белән бергә сәхәргә тора идем. Әле мин бала гына булгач, әлбәттә, көн буена ураза тотмый идем. Әмма әби белән бергә сәхәр ашау, кичен авыз ачу, аның гыйбадәт кылганын күрү динебез нигезләренә төшенергә мөмкинлек бирде.

Ә инде 30 яшьләремдә намазга бастым, башыма яулык бәйләп, озын күлмәк киеп йөри башладым. Моңа мине бер аянычлы хәл этәрде. Иремнең ике туган апасы ике ай эчендә яман чирдән үлеп китте. Мин гел аның янәшәсендә булдым, хастаханәләргә озата бардым.

Ул вафат булгач, башыма төрле уйлар керә башлады. Менә кеше бүген бар, иртәгә юк. Кыямәт көнендә Аллаһы Тәгалә каршына үзебез белән алып бара торган намазларыбыз да, уразаларыбыз да, биргән садакаларыбыз да булырга тиеш бит. Ә минем әле һаман боларның берсе дә юк. Шулай уйланып йөргәч, дин юлына басарга булдым, намаз укыйм, ураза тотам, әлхәмдүлилләһ. Ирем дә бу карарымны шатланып кабул итте. Хәзер инде башка төрле яшәү рәвешен күз алдына да китерә алмыйм.

Күпләр, лаеклы ялга чыккач, яисә балаларны үстергәч, яисә эшләрем беткәч, намазга басармын әле, дип, вакыт булмавына сылтап, гыйбадәт кылуны кичектерәләр. Ә бит Аллаһы Тәгаләдән күпме гомер бирелгәнен кем белә?! Әйткәнемчә, бүген без исән, иртәгә инде якты дөньядан китеп барырга мөмкин. Шул турыда уйлансак иде. Аннары, гыйбадәт кыла башлагач, кешенең тормышы яхшы якка үзгәрә, Раббыбыз гел ярдәмен биреп тора бит ул.

***- Бүген яшьләр дингә тартыламы?*** – дип мөрәҗәгать иттем мәчеттә хезмәт итүче Илшат әфәндегә.

- Аллаһыга шөкер, ел саен гыйбадәтханәгә йөрүчеләр саны арта бара. Мәчетебез җәмагатендә күбесе – 25 – 45 яшьлек диндәшләребез.

Шуны да әйтеп үтәсем килә, Зубчаниновкада бик күп татарлар яши. Шуңа күрә дә без аны Татар бистәсе, дип атап йөртәбез. Әлхәмдүлилләһ, бердәм, дус булып яшибез. Расих хәзрәт тә, мин дә, башка күп дин кардәшләребез дә - Самар шәһәренең татар милли-мәдәни мөхтәрияте (җитәкчесе – Линар Сабиров) әгъзалары. Мил-

ләттәшләребезне берләштерүгә, ана телебезне, гореф-гадәтләребезне, мәдәниятебезне, динебезне саклап калуга һәм үстерүгә юнәлтелгән чараларда катнашып киләбез.

***- Балаларыгызга дини тәрбия бирәсезме?***

- Әйе, вәгазьлибез, яхшыны - яманнан, хәләлне хәрәмнән аерырга өйрәтәбез, исламның әһәмиятлелеген, Аллаһы Тәгаләнең барлыгын, берлеген, мәрхәмәтле, бөек булуын аңлатабыз.

“Болгар мирасы” мәчетендә балалар өчен дини дәресләр оештырдык. Кечкенәләребезне шунда алып барырга тырышабыз.

Гомумән, нарасыйларны сүз белән генә түгел, күбрәк үрнәк күрсәтеп тәрбияләргә кирәк бит ул. Улларыбыз-кызларыбыз, бездән күреп, гыйбрәт алалар, әхлак кагыйдәләрен сеңдереп баралар, дип уйлыйбыз.

Балаларны иманлы, тәүфыйклы итеп тәрбияләүдә исламның әһәмияте искиткеч зур. Кеч-



кенәдән дин нигезләрен өйрәнеп үскән нарасый тәртипле була ул.

***- Гаилә бәхетле булсын өчен, ир белән хатын арасындагы мөнәсәбәтләр нинди булырга тиеш?*** – дип кызыксындым Илшат әфәндедән.

- Аллаһы Тәгалә безгә түземле булырга кушкан. “Сабырлыкның төбе – сары алтын”, дип юкка гына әйтмәгәннәр бит инде. Ир белән хатын арасындагы шушы сыйфат – иң мөһиме. Очрашып йөргәндә мәхәббәт хөкем сөрә, берминди проблема юк. Ә бергә яши башлагач, бәхәсләр дә, аңлашылмаучылык та килеп чыгарга мөмкин. Тормыш бит ул, төрле хәлләр була. Менә шул вакытларда түземлек кирәк тә инде. Бәхетле гаиләнең нигезендә сабырлык ята. Бер-береңнең сүзенә колак салып, юл бирә белеп, һәрхәлдә түземлек күрсәтеп яшәү мөһим. Әлбәттә инде, ир-ат буларак, мин гаиләмә карата гадел, йомшак булырга тырышам. “Хатыннарына һәм балаларына иң яхшы мөнәсәбәттә булганнар - сезнең арагызда иң яхшыларыгыз ”, - дип әйткән бит Пәйгамбәребез с.г.в.

Коръәни-Кәримдә: “Мөэмин хатыннар да, мөэмин ирләр дә бер-берсенә дус булырлар, бер-берсен хәерле якка өндәрләр, гөнаһтан тыярлар”, – диелә. Ир дә хәләл җефетенең акыллы киңәшенә колак салырга тиеш. Хатын-кызның зирәклеге бар икән, ул ирен дөрес юлга кертеп җибәрер.

***- Юлия ханым, тормыш иптәшегезнең сүзләренә ни өстәр идегез?***

- Аның белән тулысынча килешәм. Тагын шуны әйтер идем, ирне ир итеп, хөрмәтләп, балалар алдында аның югары абруен күрсәтеп яшәргә кирәк. Пәйгамбәребез с.г.в.нең: “Ире канәгать хәлдә вафат булган һәрбер хатын-кыз җәннәткә теләгән ишегеннән керсен,” – дигән сүзләрен исебездән чыгармасак иде.

***- Тормышта кемнәргә таянып яшисез?*** – дип сорадым Залятдиновлардан.

- Иң беренче чиратта, Аллаһы Тәгаләгә таянабыз, - дип башлады сүзен гаилә башлыгы. – Минем әти-әнием – Мәксүм белән Зәйнәб, Юлиянең ата-анасы – Фәрит белән Фәлүзә – безнең терәгебез. Алар – безнең иң газиз кешеләребез, үзләренә барысы өчен дә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын.

Әлхәмдүлилләһ, ышанычлы, кайгыны да, шатлыкны да тигез итеп бүләрлек иптәшләребез бар.



- Мин дә әти-әниләребезгә, безне дөньяга китергәннәре, лаеклы тәрбия биргәннәре, ярдәм итеп яшәгәннәре, һәрвакыт яныбызда булганнары өчен олы рәхмәтемне белдерәсем килә, - дип өстәде Юлия.

***- Үзегезне бәхетле кешеләр, дип әйтә аласызмы?*** – дигән соңгы соравымны бирдем әңгәмәдәшләремә.

- Аллаһы Тәгалә мине мөселман итеп яралткан, исәнлек биргән, дин юлыннан атларга насыйп иткән, гаиләм тулы, әти-әниләребез исән-сау, эшем, яхшы иптәшләрем бар – шуларның барысы да минем өчен зур бәхет. Гомумән, дөньяда яшәү – үзе бәхет ул. Раббыбызга шөкер кылам, - дип җавап бирде Илшат әфәнде.

- Ата-аналарыбыз, якыннарыбыз, туганнарыбыз исән-имин, ирем яхшы, газиз балаларым, йортыбыз, яраткан шөгылем бар. Аллаһыга шөкер, әлбәттә, мин бик бәхетле, - дип елмайды Юлия дә.

# ГЛАВНАЯ ЦЕННОСТЬ – СЕМЬЯ



***Рустам Ахтемович Ахметзянов родом из деревни Благодаровка Челно-Вершинского района. Мальчишкой вместе с отцом часто ходил в сельскую мечеть, где и узнал о традициях, предписаниях и основах ислама. Да и рос Рустам в семье, основой которой являлись уважение, культура доброты и сильные семейные традиции. Эти качества помогли Рустаму Ахтемовичу создать крепкую, дружную семью. Не изменяет своим принципам мужчина и в работе. Вот уже больше 20 лет Рустам Ахтемович трудится начальником отделения судебных приставов Челно-Вершинского района.***

***Алина Харисова***



После окончания средней школы в родном селе Рустам, как и большинство молодых людей, поехал учиться в город. Поступил в Самарский плановый институт на экономиста. Областная столица хоть и была богата на перспективы, но мысль быть полезным родной земле не покидала молодого человека. В 1998 году Рустам Ахтемович возвращается на родину. Трудится сначала на одном из местных нефтяных предприятий, а через два года поступает на службу в органы принудительного исполнения. Проработав судебным приставом и набравшись опыта, Рустам Ахтемович через некоторое время был назначен начальником местного отделения. «Имея за спиной экономическое образование, познать юридические тонкости было непросто. Одновременно с приходом на службу я поступил в филиал Московского института права. Хоть и изначально столкнулся со сложностями, но работа мне была интересна. Интересна с точки зрения психологического поля, когда необходимо







убедить должника в необходимости исполнения решения суда, с точки зрения каких-то юридических норм. Когда осознаешь, что ты помог восстановить чьи-то права и добиться справедливости, понимаешь, что находишься на своем месте», – рассказывает начальник отделения Челно-Вершинского района.

Рустам Ахтемович верит в судьбу. Иначе как объяснить, что будущую супругу мужчина встретил в родном селе, в Челно-Вершинах. С Альбиной наш герой познакомился после возвращения на родину. В 2004 году молодые сыграли свадьбу. Родители Рустама стали для супругов настоящим примером крепкого семейного союза. Рустам Ахтемович признается, что друг для друга они остаются лучшими советчиками, помощниками, самыми близкими и дорогими людьми. В этом году старшая дочь Рустама и Альбины оканчивает школу, в ближайшее время для нее наступит пора выпускных экзаменов. Младшая – учится в старших классах, скоро и ей предстоит получить аттестат зрелости.



Недавно мусульмане отметили один из главных праздников – Ураза-байрам. Семья Ахметзяновых собралась за изобильным столом, чтобы поздравить друг друга и вместе провести вечер. Для них главное слово – вместе. Вместе – в радости и в горе, в труде и отдыхе. Отдыхать семья судебного пристава также предпочитает неразлучно. Чаще всего они все вместе выезжают на Каму или реку Кондурчу. Семья любит порыбачить и насладиться красотой местных пейзажей.

Традиции формируют ценности. Чета Ахметзяновых доказала, что одна из самых главных ценностей жизни – это семья.

*Нурания АБЗАЛОВА,*
*Самар өлкәсенең атказанган сәламәтлек саклау хезмәткәре, Фатих Мортазин премиясе лауреаты.*

# АК ЧӘЧӘКЛӘР

*Изгелегегезнең чиге юк,*
*Кояш сипкән нурлар шикелле.*



Татар Байтуганы авылына килгән һәрбер кешене, кунакмы ул, туган ягын озак еллар күрмичә сагынып кайткан бер баласымы, туймы, кыз сорарга килгән яучымы, егет йортын күрергә килгән кодалармы, газизләрен соңгы юлга озатучылармы, әти-әни васыятен үтәп, аларны туган җирләренә җирләргә алып кайтучыларммы – барысын да тау битендә, кояш нурларына күмелеп утыручы бер йорт каршы ала. Ул бар яктан да агачлар белән уратып алынган. Аның артында бик зур талтирәкләр һәм шомырт агачлары сакта тора, ә алдында капка төбеннән үк салкын сулы чишмә челтерәп ага. Аны Рәйсә апай чишмәсе, диләр. Чишмә янында ук чыганакның моңлы җырын тыңлап үскән горур талтирәк үсеп утыра. Монда юлчылар, туктап, саф чишмә суын эчеп, агач күләгәсендә ял итеп алалар. Хәзерге вакытта бу йорт буш булса да, тирәсендәге агачлар аны ялгыз итмиләр, бер төрле матурлык өстәп, тирә-якны бизәп торалар.

Мәктәп күрше Рус Байтуганында урнашканга, буранлы суык көннәрдә әтием мине җиккән атта каршы ала иде. Шушы йорт каршысыннан узган саен ул: «Бик күп бал ашаттылар безгә бу йорт хуҗалары - Рәхимҗан ага белән Дәрлиҗиһан апай, кызым», - ди торган иде.

- Аларның малайлары белән су коенырга йөри идек. Без кайткач, Дәрлиҗиһан апай алдыбызга зур коштабак белән кыяр, чүлмәк белән бал, үзе салган зур күмәч чыгарып куя иде. Әй, рәхәтләнеп сыйлана идек тә, тамак туйгач, тагын инешкә йөгерә идек, - дип искә алганда, әтиемнең күзләре һәрвакыт дымлана иде. Ул вакытта ачлык булган, шулкадәр мул сыйларны ничек итеп онытып булсын инде... Бу гаиләнең үз балалары да күп булган, алар чит балаларны да ашаткан-нар. Шундый киң күңелле, юмарт кешеләрне оныту мөмкин түгел. Рәхимҗан ага белән Дәрлиҗиһан апай биш малай һәм бер кыз үстерәләр – Сәлимҗан, Газимҗан, Хәбибҗан, Мирсәиф, Рәхимә, Мирзаҗан. Алар барысы да бик уңган булып үсеп җитәләр, үз гаиләләрен коралар. Сәлимҗан, Рәхимә - икешәр,





*1948 ел, Камышлы*



*Рәйсә Кәлимуллина, 30 яшь. Сабан туеннан соң, күршеләре белән, 1961 ел*



*Тәнзиләгә 8 яшь*

Хәбибҗан бер малай үстерәләр. Көтмәгәндә, 1941 елның 22 июнендә, Бөек Ватан сугышы башлана. Тетрәндергеч бу хәбәр Байтуганда гөрләп Сабан туе барган вакытта яңгырый. Сөйгән ярларын, хатыннарын, балаларын, ата-аналарын соңгы тапкыр кочып: «Көчле булыгыз, дошманны җиңәбез дә кайтабыз», - дип, ир-егетләр сугышка китәләр. Рәхимҗан ага белән Дәрлиҗиһан апай Кәлимуллиннар да сугышның беренче көнендә үк дүрт улларын озаталар (Мирсәиф бераз авырып торганга, аны алмыйлар).

Аларны хатыннары һәм балалары озатып калалар. Кызганычка, сабыйлары аталарын бүтән күрмиләр – Сәлимҗан, Газимҗан, Хәбибҗан, батырларча һәлак булып, сугыш кырларында ятып калалар. Туганнарын югалту кайгысын күтәрә алмыйча, Мирсәиф үлеп китә. Бу күтәргесез кара кайгыга ата-анага ничек түзәргә?! Яраланган йөрәкне ничек тынычландырырга, ятим оныкларның сагышлы карашына ничек чыдарга, «Әтием кайчан кайта?» дигән сорауга нәрсә дип җавап бирергә? Үсеп җитеп, үзләре әти булгач та, алар өзелмәс өмет белән яшәрләр. Кем белә, бәлки, әти кайтыр әле. Әмма юк шул – алар яу кырында мәңгелеккә ятып калганнар...

Мирзаҗан Кәлимуллин сугышта элемтәче (связист), парашютчы булып хезмәт итә. Бөек Җиңү көнен Берлинда каршы ала. Шулай итеп, Рәхимҗан ага белән Дәрлиҗиһан апайның бер уллары һәм бер кызлары кала. Мирзаҗан «обозный цехка» эшкә урнаша, чаналар ясый. Сугыштан соңгы авыр еллар...

1948 елда болытлы көнне кояш яктырткандай, Татар Байтуганы авылына Мәчәләйдән Рәйсә Зәки кызы Субеева шәфкать туташы булып килә. Татар Байтуганында ул елларда 1000нән артык кеше яшәгән. Ачлык, ялангачлык, юклык, трахома чире. Йорт саен ачлыктан интеккән ятим балалар, көне-төне нужа куып хәлсезләнгән аналар. «Яп-яшь тол хатыннар, бәләкәй арба белән утын әзерләп, ашлык сугып, көлтә бәйләп, бар тапканнарын налог түләп саклап калдылар балаларын», - дип сөйли иде Рәйсә апай елый-елый. Ул үзе дә, көндез медицина пунктында эшләсә, төннәрен көлтә бәйләргә йөргән. Бармыйча калырга ярамый.

Рәйсә апайның әнисе Шәмселбәдәр - Камышлыдан, әтисе - Мәчәләй егете. Әтисе Габделхәер хәзрәтнең оныгы – Зәки. Аның хакына Мәчәләйдә елганы «Мулла елгасы» дип атаганнар. Шәмселбәдәр һәм Зәки гаиләсендә бала күп туса да, Вазыйх һәм Рәйсә генә исән калалар. Рәйсә апай балачактан әти-әнисеннән бик тирәнтен дин нигезләрен өйрәнә. Кыен вакытларда да, куанычлы минутларда да дога укый идем, дип сөйли иде Рәйсә апа.

Бу яшь чибәр кызга күз атып йөрүчеләр күп булган. Тик шомырт кара күзле, бөдрә чәчле матур егет Мирзаҗан кыз янына беркемне дә якын җибәрми. Кызның йөрәген яулау егеткә җиңел бирелми. Өч ел тырышканнан соң гына, Рәйсә Мирзаҗанга ризалыгын бирә. Рәхимҗан абый белән Дәрлиҗиһан апай Мәчәләйгә кыз сорарга баралар һәм яулык алып кайталар.

Яшь гаилә ата-аналары белән бергә төп нигездә яши башлыйлар. Йортка килен төшүгә бик куаналар, билгеле. Әмма аның эше бик тынгысыз була. Таң алдыннан да, ярты төн уртасында да медицина ярдәме сорап киләләр. Татар Байтуганы халкы гына түгел, күрше Алтын тау поселогы халкына да ярдәм итәргә туры килә. Рәйсә апай андагы хатын-кызларның да күбесенә бәбиләргә ярдәм итә.

1952 елда, гаиләне тулыландырып, аңа бәхет өстәп, кызлары Тәнзилә туа. Тәнзилә Рәйсә апайның да, Мирзаҗан абыйның да бөтен матурлыгын, табигатьнең язгы һәм җәйге гүзәллеген үзенә туплаган, диярсең. Тулган ай кебек, түм-түгәрәк йөзле, зур яшел-коңгырт, энҗедәй күзле, бөдрә чәчле гүзәлләрнең дә гүзәле булып туа

бу кыз. Ә әби белән бабайның куанычын сөйләп бетергесез. Кызганычка, Дәрлиҗиһан апаның гомере кыска була. Дүрт улларын югалту хәсрәте аның исәнлеген нык какшата – 1954 елда ул үлеп китә. Килене Рәйсәгә ул васыять итеп әйткән кебек: «Бер бала да җитә, күп тапма. Әнә, мин дүртесен җирләдем», - дип әйтеп калдыра. Шулай итеп, Тәнзилә бердәнбер бала булып үсә. Тик аңа иркә булып үсәргә туры килми. Кая иркәләнсен инде? Әнисе көн-төн эштә. Җәелеп китеп эшләргә медпункты да юк ул вакытта (1967 ел). Өйдән-өйгә күченеп эшлиләр. Ә 1960 ел азагында мәчеттә бала табу йорты (роддом) ачалар. Рәйсә апаның хезмәте тагын да катлаулана. Көн-төн эштә. Өч Байтуган авылына берүзе. Ул елларда бәбиләүчеләр саны да күп. «Халык - Сабан туенда, ә мин - дежурда», - дип искә ала Рәйсә апа.

Бераздан бала табу йортын ябалар, медпунктны бер өйдә ачалар, ә мәчеттә балалар бакчасы эшли башлый. Соңрак медпунктны кабат мәчеттә ачалар. 1970 ел азагында гына агачтан ике бүлмәле медпункт салалар, күмер белән ягыла торган мич була. Күршесе Назыймә апай санитарка булып эшли. Бик уңган иде, дип еш искә ала аны Рәйсә апай.

Рәйсә апай сөйләгәннәрне тыңлаганда һәрвакыт түрәләргә исем китә иде. Башлангыч татар мәктәбен, мәчетне япканнар, зур итеп медпункт та салдырмаганнар. Димәк, алар халык турында бөтенләй уйламаганнар. Балалар мәктәптә укысалар, мәчеттә картлар дога кылсалар, файдасы да, савабы да булыр иде. Юк шул, атеизмның чәчәк аткан чагы...

Рәйсә апай Татар Байтуганында 40 елдан артык фельдшер булып эшли. Ә Тәнзиләгә иркәләнеп торырга туры килми. Әнисе көн-төн эштә булганга, бөтен өй эшләрен кызга башкарырга туры килә. «Син дә, минем кебек, фельдшер булырсың», - дигәч, Тәнзилә: «Юк, әни, мин укысам, табибка укыйм», дия торган булган.

Рәйсә апай яраткан хезмәтенә бар көчен, сәләтен куя. Аның медпункты бар яклап та гел алдынгылардан була. Әнием Рәйсә апайдан укол кадатып чыга иде дә: «Медицина хезмәтен сайласагыз, Рәйсә кебек, йомшак куллы, җылы карашлы, сүз белән дә дәвалый алучы булыгыз», - дия иде.

Еллар уза, Тәнзилә Байтуган авылының 8 еллык мәктәбен, аннан соң Камышлыда 9 – 10 сыйныфларны тәмамлый да, әнисе юлын сайлап, Куйбышевның медицина институтына керер исәп белән имтиханнар тапшыра. Әмма конкурсны уза алмый. Аны Сосна авылына химия-биология укытучысы итеп алалар. Яшь укытучыны барысы да бик яраталар, мәктәптә эшләргә калырга өндиләр. Авылда Тәнзиләгә гашыйк булмаган егет калмагандыр, мөгаен. Тик ул дуслашу түгел, берсе белән дә сөйләшми дә. Аның максаты бар: көзен имтиханнарны уңышлы тапшырып, Куйбышев мединститутына керү. Ниһаять, 1970 елда кызның хыялы чынга аша.

Уку бер дә җиңел булмый, билгеле. Көн-төн кулдан китап төшми. «Уку – энә белән кое казу», дип юкка гына әйтмәгәннәр инде. Бик тырышып укый Тәнзилә. Студент еллары - онытылмаслык еллар. Уйламаганда Тәнзилә гашыйк булып куя. Кызның йөрәген шул институтта укучы Камышлы егете Рәфхәт Шиһапов яулый. Егет институтны алданрак тәмамлый, яшь пар матур итеп туй уздыралар. Тәнзилә укуын тәмамлагач, аларны Чебоксар шәһәренә җибәрәләр, анда интернатура үтәләр. 1977 елда улары Марат туа. Бераздан Шиһаповлар Похвистнево шәһәренә кайталар, уллары Азат дөньяга килә. Тик сабыйның гомере кыска була – ул бала тудыру йортында сары чире йоктыра, матур гына үсеп килгәндә үлеп китә. Бу югалту гаилә өчен беренче сынау була. 1982 елда кызлары Гөлнара туа. Рәйсә апаның дәвам-



*Рәйсә Кәлимуллина бер яшьлек кызы Тәнзилә белән*



*Тәнзиләгә 13 яшь, 1965 ел*



*Тәнзилә Шиһапова-Кәлимуллина, 1970 ел*



*Рәйсә һәм Тәнзилә Кәлимуллиналар*





*Тәнзилә һәм Рәфхәт, уллары Марат, , кызлары Гөлнара, 1982 ел*

чылары гел бергә, киңәшләшеп медицина өлкәсендә хезмәт итәләр. Рәфхәт Әсхәтович – уролог-хирург, Тәнзилә Мирзовна гинеколог булып эшлиләр гомер буе.

1995 елда Тәнзилә ханымны Похвистнево районының баш гинекологы итеп куялар, тагын өч елдан акушерлык бүлеге җитәкчесе итеп билгелиләр. 2010 елда Похвистнево шәһәрендә Камышлы, Кләүле, Исаклы, Шенталы, Похвистнево районнары өчен бик зур перинаталь үзәк төзелә. Санап киткән район хатын-кызларының барысы да шушы үзәктә бала табалар. Тәнзилә ханымга шушы үзәк җитәкчесе вазифалары йөкләнә. Медицина хезмәткәре буларак, бу - искиткеч җаваплы эш, дип әйтә алам. Берьюлы ике кеше гомере өчен җаваплылык бит ул. Тәнзилә Мирзовна дәвалаган хатын-кызлар санының чуты юктыр, мөгаен. Ана булырга теләгән, әмма төрле проблемалары булган хатын-кызлар табиб янына күз яшьләре белән ярдәм сорап килгәч, Тәнзилә Мирзовна, аларны юатып, күңелләренә өмет салып, тынычландырырга тырышкан.

Ул һәрдаим белемен арттыру өчен төрле курслар уза тора. Төрле елларда Мәскәү, Баку, Краснодар, Казан һәм башка шәһәрләрдә квалификация үстерү курсларын тәмамлый. Үз эшенең чын остасы булган табиб бик күп гаиләләргә бала бәхете бүләк итә.

Тәнзилә Мирзовнаның тырышлыгы хөкүмәт тарафыннан югары бәяләнә. Күпсанлы Мактау грамоталары һәм Рәхмәт хатлары арасында сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы биргән Мактау граматосы да бар. 2015 елда аны Мәскәүдә узган медицина хезмәткәрләре бәйрәменә чакыралар һәм «Отличник здравоохранения» дигән мактау билгесе белән бүләклиләр.

Әмма тирән фикерле, тыйнак, акыллы Тәнзилә ханым өчен авыруларның, бәхетле аналарның чын күңелдән әйткән рәхмәт сүзләре - иң зур бүләк.

Бүгенге көндә дә Тәнзилә Мирзовна хезмәт юлын дәвам итә. Ул тудырган балалар, үсеп җитеп, үзләре дә әни-әти булырга өлгерделәр инде. Ә табиб һаман әле төрле яктан рәхмәт сүзләре ишетә. Аңа язалар, шалтыраталар, бәйрәмнәр белән котлыйлар, аллы-гөлле чәчәк бәйләмнәре аның өстәлендә ел әйләнәсе шиңми. Минемчә, бу – бәхетнең иң зурысы. Шушы рәхмәтләр, дәва алган авыруларның ихтирамы аңа алга таба да армый-талмый эшләргә көч бирә.

Ул үзе турында сөйләргә яратмый, тыйнаклыгы кушмый. Ә менә аның кул астында эшләүчеләр, осталыгына сокланып: «Бик таләпчән, һәр кешегә карата игътибарлы, һәрбер сүзен уйлап сөйли, бөтен хезмәткәрләренә дә бертигез ихтирам белән карый, һәрвакыт пөхтә, чиста киенгән, беркайчан да бизәнми. Хезмәткәрләреннән дә пөхтәлек, чисталык таләп итә. Эшне җиренә җиткереп башкарырга, коллективта бердәм булырга өйрәтә. Көтмәгәндә зур комиссияләр, хәтта Мәскәүдән дә килеп төшәргә мөмкиннәр. Без һәрвакыт бу тикшерүләргә әзер булырга тиеш», - дип сөйлиләр.

Минем үземә дә бәбиләүче хатын-кызларны шул үзәккә илтергә туры килде. Анда ятучы авырулар, Тәнзилә Мирзовна авылдашларның хәлен белешеп тора, җылы сүзләрен җәлләми, диләр. «Җылы сүз – җан азыгы», дип дөрес әйтәләр инде.

***«Сулар сибеп кенә гөлләр үсми,***
***Кояш нуры әгәр тимәсә».***
***Бик дөрес сүзләр.***

Җәй уртасындагы кырау кебек, Тәнзилә ханымның тормышында да бик күп сынаулар була. 2009 елның 2 гыйнварында әтисен соңгы юлга озаталар, аннан соң – каенанасын, каенатасын, иренең бертуганнарын... 2013 елның 30 декабрендә фаҗигале рәвештә улы Марат вафат була, 2020 елның 29 декабрендә яраткан тормыш иптәше мәңгелеккә күзләрен



йома. Билгеле инде, әлеге югалтулар аның йөрәгендә мәңге төзәлмәслек яралар калдыралар. Шулай да ул алга атларга көч таба. Бүгенге көндә аның куанычы – энисе Рәйсә, кызы Гөлнара, оныгы Әмир һәм ике туган энеләре-сеңелләре, абыйлары.

Өч ел инде Рәйсә апай Похвистнево шәһәрендә, кызы Тәнзиләдә яши. 2021 елның 28 декабрендә ул 90 еллык күркәм юбилеен билгеләп үтте. Күз ачмаслык буран иде. Без, берничә машина тезелеп, Коръән мәҗлесенә бардык. Шундый һава торышы булуына карамастан, бөтен чакырылган кунаклар килгән иде. Барыбыз да Рәйсә апага җылы, матур теләкләр теләдек. Гомере буе авылдашларының исәнлеге сагында торган, бар яктан булган, соклангыч уңган, йомшак күңелле якташыбызга санап бетергесез изгелекләре, татар милләтенә, дингә тугры булган бала – Тәнзилә ханымны тәрбияләгәне өчен чиксез рәхмәтләр җиткердек.

Туып-үскән нигезен дә онытмый Тәнзилә ханым. Аның бакчасында нинди генә гөл-чәчәкләр, яшелчәләр үсми. Табыннарны да һәрвакыт бик мул итеп әзерли Тәнзилә Мирзовна. Ул, ел саен туган нигезенә кайтып, корбаннар чалдыра, бакыйлыкка күчкән якыннары рухына Коръән укыта. Әлеге сүзләремне язганда әниемнең: «Кызым, күңелең җитсә, бөтен нәрсәгә дә өлгереп була», - дигән сүзләре искә төшә. Әниемнең Рәйсә кебек булыгыз, дигән сүзләрен искә алыпмы, без дә апам белән медицина юнәлешен, шәфкатьлелек юлын сайладык.

1978 – 1981 елларда Гөлфия апам Рус Байтуганында фельдшер булып эшләде. Аннан соң аның эшен мин дәвам иттем. Рәйсә ханым белән гел бергә эшләдек, ул – Татар, мин – Рус Байтуганында. Яшь аермабыз байтак булса да, Рәйсә апай белән гел бергә идек. Конференцияләргә дә бергә барабыз, медосмотрларны да, прививкаларны да бергә үткәрәбез. Рәйсә апа лаеклы ялга чыккач, Гөлфия апам яңадан аның урынына кайтты. Байтуган медпунктлары гел беренчеләрдән булдылар һәм еллар буе беренчелекне саклап килдек. Аллаһыга шөкер, Гиппократка биргән антыбызга тугры булдык. Рәйсә Зәкиевна, Тәнзилә Мирзовна, Гөлфия һәм Нурания Минсәхиевналар ак халатларына тап төшермәделәр.

Язмам азагында тагын шул бәхетле нигез турында искә алып үтәргә булдым. Аның яныннан узганда, берничә генә минутка булса да туктап сокланмый калмыйм. Чишмә тавышын, агач яфракларының пышылдавын тыңларга яратам, догалар кылам. Быел язын бик зур булып үскән тополь агачы янына килеп баскач, яфракларның тавышына хәйран калдым. Әлеге агачның яфрак тавышы да башкалардан аерылып тора, вакыт-вакыт ниндидер көй дә сузалар сыман. Гасырлар буе аккан Рәйсә апай чишмәсе дә кушылды яфраклар җырына. Ә мин сүз белән аңлатып булмаслык моңга чумдым. Бу нигезгә килен булып төшкән чибәркәй - Рәйсә апай, шунда дөньяга аваз салган Тәнзилә ханым турында әллә ничә томлы ки-



тап язарга булыр иде. Мәкаләмнең геройлары - Рәйсә Зәкиевна һәм Тәнзилә Мирзовна нинди генә зур дәрәҗәле биеклеккә күтәрелсәләр дә, алар өчен иң зур дәрәҗә – гомер буе юлдашлары булган Аллаһының рәхмәте һәм гаделлек. Кылган игелекләре санап бетергесез. Һәрбер изгелекләре өчен үзләренә саваплар кайтсын иде.

Шушы искиткеч шәхесләр алдында баш иеп, авылдашлары исеменнән аларга чиксез рәхмәтләр җиткерәм һәм изге теләкләр юллыйм. Исәнлек-саулык, озын гомер, аяз күк йөзе, күңел тынычлыгы, югалтуларсыз гомер кичерүләрен телим.

# “КИЛӘЧӘКТӘ БИК ЯХШЫ БЕЛГЕЧ БУЛЫРГА ХЫЯЛЛАНАМ!”

***Акыллы, максатчан, тәрбияле, ачык күңелле яшьләребез белән аралашуы бигрәк рәхәт тә инде! Өстәвенә, тыйнак, уңган-булган, үз милләтләрен хөрмәтләүче, күркәм холыклы, һөнәрләрен ихластан яратучы кешеләр дә булсалар, бу күңелгә аеруча хуш килә. Алар белән сөйләшү ләззәт китерә, киләчәгебезнең ышанычлы кулларда булуына зур ышаныч туа.***

***Миләүшә Газимова***



Нәкъ шушындый матур сыйфатларга ия булган гүзәл татар кызларыбызның берсе - 21 яшьлек Альбина Нияз кызы Сафиуллина белән аралашу да бары тик уңай тәэсирләр калдырды.

Яшь милләттәшебез Самар дәүләт медицина университетында дүртенче курста укый. “Аллаһы бирсә, киләчәктә бик яхшы белгеч булырга хыялланам мин!” – ди Альбина. Һәм моның өчен, бар көчен куеп, тырышып-тырмашып гыйлем ала ул. Мәктәпне дә алтын медальгә тәмамлаган кыз, төрледән-төрле бәйгеләрдә, олимпиадаларда катнашып, призлы урыннар яулап килгән. Балачагыннан ук табиб булырга хыяллангач, аеруча химия һәм биология фәннәрен яратып үзләштергән. Химия буенча, гомумән, мәктәптә иң көчле укучы булган!

- Әлеге дәресне алып барган, безгә тирән белем биргән укытучым Татьяна Александровна белән бүгенге көндә дә аралашабыз, җылы мөнәсәбәтләребез сакланып килә. Мин аңа бик рәхмәтле, - ди Альбина.

Кызның альбомын актарып утырганда, аның әле курчакларын, әле аю, эт кебек йомшак уенчыкларын дәвалаганын сурәтләгән фотоларны күргәч:

- Сөбханаллаһ, син, чыннан да, бик кечкенә чагыңнан ук табиб булып уйнагансың икән бит! – дип гаҗәпләндем.



- Әйтмәгез дә инде, - дип көлеп җибәрде Альбинаның әнисе – Илүсә ханым. – Хәтта дүрт-биш яшьләрендә Әлфирә әбисе үзенә табиблар кия торган ак халат белән ак башлык тектереп бүләк итте.

Кызыбыз һөнәрен дөрес сайлап алды, дип саныйбыз, чөнки ул – үтә дә җаваплы, көчле рухлы, максатына омтылышлы кеше.



- Рус Байтуганы авылында гомер итүче, 41 ел буена фельдшер булып эшләгән әбием Нурания дә миңа йогынты ясамый калмагандыр, - дип сүзгә кушылды Альбина. – Ап-ак халатына кызыгудан тыш, аның үз хезмәтенә, кешеләргә карата искиткеч яхшы мөнәсәбәтен, чын мәхәббәтен күреп соклана идем. Әбием мине тагын да илһамландырып җибәрде. Ә инде балаларны өзелеп ярактанга, педиатрия бүлеген сайлап алдым.

***- Синеңчә, табиб нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?*** – дип кызыксындым Альбинадан.

- Эмпат, ягъни тирә-ягындагыларның хис-тойгыларын күрә һәм аңлый белүче шәхес булырга

кирәк. Иң мөһиме – кешеләрне чын күңелдән ярату. Аларга ихластан ярдәм итү теләге, түземлек, мәрхәмәтлек сыйфатлары булырга тиеш. Безнең хезмәттә һич кенә дә хата ясарга ярамый! Шуңа күрә мин университетта яхшы билгеләр алырга түгел, ә тирән гыйлем үзләштерергә омтылам. Беренче



өч елда бик авыр иде. Иң катлаулы предметлар өченче курста тупланган. Хәзер инде җиңелрәк, чөнки төп нигез салынды һәм шушы белемнәрне кулланырга гына кала.

Яшь милләттәшебез укый да, поликлиникада эшли дә икән инде. Биредә ул педиатрның шәфкать туташы вазифаларын башкара – табиб белән бергә авыру балаларны кабул итә, аларның өйләренә барып йөри.

- Анда мин практик тәҗрибә туплыйм, профессиямнең нечкәлекләренә тагын да төшенәм, белемемне баетам, - ди бу турыда язмам герое.

Альбина – бик актив, уңган кыз. Ул биш ел шәрык биюләре белән шөгыльләнгән, төрледән-төрле чараларда, конкурсларда катнашкан. Тәмледән-тәмле тортлар да пешерә ул.

Кул эшләренә дә бик оста. Картиналар чигә, алмаз мозаикасы белән мавыга, ыргак белән бәйләм бәйли.

Ә күптән түгел яшь милләттәшебез, Бөтендөнья татар конгрессы оештырган “Оста куллар-2023” конкурсында катнашып, Рәхмәт хаты белән бүләкләнгән. Әлеге бәйгедә Россиянең төрле төбәкләреннән, хәтта чит илләрдән дә кул эшләрен тәкъдим итүчеләр булган. Шулай ук Альбина Самарда узган “Мирас” Халыкара татар мәдәнияте фестивалендә “Декоратив-гамәли сәнгать” номинациясендә призлы урыннарга лаек булган.

- Бер 9 – 10 яшьләремдә чалыштырып (крестиком) чигү белән кызыксына башладым. Тора-бара ыргак белән курчаклар, җәнлекләр һәм башка әйберләр бәйләргә тотындым.

Алмаз мозаикасы да бик ошады миңа. Иҗатның әлеге юнәлеше әле алмаз картинасы дип тә атала, ягъни бу - ташлар белән рәсем ясау. Клей белән капланган киндергә ташлар кую схемасы төшерелгән һәм шуның буенча пинцет ярдәмендә рәсем урнаштырыла.

Боларның барысына да интернеттан өйрәндем. Беренче мәлләрдә килеп чыкмый, сүтеп, барысын да яңадан ясарга туры килә иде. Әмма мин башлаган эшне җиренә җиткерергә күнеккәнмен. Хә-





зер инде нинди генә кул эшләрем юк!

Чигүгә килгәндә исә, картиналарымда күбрәк табигать күренешләрен сурәтлим, аеруча ямьле җәйне яратам.

Әниемә дә чигү җене кагылган. Икәү бергә кул эше белән шөгыльләнеп утырганда, әтиебез, шаярып, безне: “Минем үрмәкүчләрем”, дип атый (көлә).

Иҗатым тормышымда мөһим урын алып тора. Бу күңелемне тынычландыра, - дип сөйли яраткан мавыгуы турында Альбина.

***- Әти-әниең синең табиб һөнәрен сайлавыңны ничек ка-***



***бул иттеләр? Һәм, гомумән, алар белән мөнәсәбәтләрең нинди?*** – дип кызыксындым әңгәмәдәшемнән.

- Әти-әнием – дөньядагы иң якын, иң газиз кешеләрем. Аларны мин өзелеп яратам. Мөнәсәбәтләребез, шөкер, искиткеч яхшы. Әтием дә, әнием дә һәрвакыт минем башлангычларымны хуплап, ярдәм итеп тордылар һәм хәзер дә шулай ук. Табиб һөнәрен сайлавыма да каршы килмәделәр. Мин ата-анама барысы өчен дә бик рәхмәтле, үзләренә сокланам, алар белән горурланам.

Әнием Илүсә бер генә минут та тик тора торган кеше түгел, үткен, чая. Шул ук вакытта хискә бирелүчән, йомшак, нечкә күңелле дә.

Әтием Нияз – гаилә башлыгы, безнең ышанычлы терәгебез, таянычыбыз, җитди, уйчан кеше.

***- Әти-әниең синдә нинди сыйфатлар тәрбиялиләр?***

- Үзләрендә булган барлык күркәм сыйфатларны миндә тәр-



бияләргә тырышалар алар. Яхшы күңелле, тәртипле, ярдәмчел булырга, олыларны хөрмәт итәргә, кечеләргә булышырга өйрәтәләр. Мин аларның һәр сүзен күңелем түренә салып куям, битләренә кызыллык китермәскә тырышам.

***- Ә әби-бабаларың сине тәрбияләүдә катнашалармы? Аларның нинди үгет-нәсыйхәтләрен исеңдә калдыра барасың?***

- Әтиемнең ата-анасы – Газизҗан һәм Әлфирә Сафиуллиннар, әниемнең әти-әнисе – Фәргат һәм Нурания Абзаловлар, әлбәттә, балачактан алып, бүгенге көнгә кадәр миңа тәрбия сабакларын бирәләр.

Аларның миңа кечкенәдән: “Кызым, акыллы, тәртипле, тыйнак, тырыш булсаң, барысына да ирешерсең”, - дип әйтеп килгән сүзләрен гомерлеккә истә калдырдым.

Нурания әбием - “Әлифба” китабы авторы Сәләй Вагыйзовның туган авылы - Татар Байтуганында аның хөрмәтенә йорт-музей ачкан кеше. Бабам Газизҗан Самар Җәмигъ мәчетендә хезмәт итә. Аларны күпләр белә, халык арасында танылган кешеләр, дип әйтәсем килә.

Әти-әнием дә, әби-бабайларым да мине сүз белән генә түгел, күбрәк үз үрнәкләрендә тәрбияләделәр. Аларның үзара һәм башкаларга булган мөнәсәбәтләрен күреп, гыйбрәт алам.

Әби-бабайлар тәрбиясен күреп үскән бала бәхетле, дип саныйм мин, чөнки алар – катлаулы тормыш юлын үткән тәҗрибәле кешеләр, акыл иясләре, һәр сүзләре алтын бөртегенә тиң.

Әти-әнием, әби-бабаларым – минем иң якын, сөекле кешеләрем. Һәр адымнарында миңа үрнәк күрсәтәләр, минем киңәшчеләрем, сердәшчеләрем. Барысы өчен дә үзләренә Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын.

***- Альбина, үз холкыңны берничә сүз белән ничек тасвирлар идең?***

- Мин максатчан, үткен, авырлыкларга бирешмәскә тырышам, бары тик алга барырга омтылам.

***- Кимчелекләрең өстендә эшлисеңме?***

- Әлбәттә. Әйтик, мин – интроверт. Кешеләр белән танышып китүе авыррак бирелә миңа, яңа коллективта беренче мәлләрдә үземне уңайсызрак хис итәм, башкаларга озак иялэшәм. Мин моны җитешсезлегем итеп кабул итәм һәм бу яктан үзгәрергә тырышам.



Гомумән, кешегә гомере буена үз өстендә эшләргә, кимчелекләрен төзәтергә, холкын яхшы якка үзгәртергә тырышырга кирәк, дип саныйм.

***- Камил гаиләне ничек күз алдыңа китерәсең?***

- Минем өчен әти-әнием – камил гаилә. Үзара мөнәсәбәтләрен күреп, чын күңелдән сокланам. Алар бербөтен булып яшиләр. Бер-берсенә тавыш күтәргәннәрен, талашканбәхәсләшкәннәрен ишеткәнем юк. Араларында чын мәхәббәт хөкем сөрә. Бер-берсенең кадерен белеп, тыңлап, хөрмәтләп гомер итәләр.

Киләчәктә, Аллаһы бирсә, минем гаиләмдә дә шундый ук мөнәсәбәтләр булсын иде, дип телим. Алар мине ничек тәрбияләде, минем дә үз балаларыма шундый тәрбия бирәсем килә.

***- Ә, гомумән, синең өчен тормышта гаилә яисә карьера мөһимрәкме?***

- Минем өчен икесе дә мөһим. Карьера ясыйм, дип, гаиләмне ташламаячакмын. Һәм башым белән гаилә тормышына гына чумып, балачактан хыялланган һөнәремнән баш тартмаячакмын.

“Мөселманның көймәсе елганың уртасыннан барырга тиеш”, диләр.

Динебез Ислам буенча уртадан бару хәерле.

Мин дә бар нәрсәдә дә алтын урталыкны тоту ягында.

***- Кешеләрдә нинди сыйфатларны өстен күрәсең?***

- Ачык, мәрхәмәтле, ышанычлы шәхесләрне яратам.

Алдакчыларны җенем сөйми.

***- Иптәшләрең күпме?***

- Әлхәмдүлилләһ, янымда чын дусларым бар. Шатлыкта да, авыр чакларда да без бергә.

Мин үзләренә теләсә нинди мәсьәлә, проблема белән мөрәҗәгать итә алам, һәм алар беркайчан да үтенечемне кире какмыйлар.

Мин дә иптәшләремә карата шундый ук мөнәсәбәттә.

***- Альбина, китап укырга яратасыңмы?***

- Элек әдәби китапларны бик күп укый идем. Хәзер күбрәк медицина темасына өстенлек бирәм.

***- “Бәхет” төшенчәсен ничек аңлыйсың?***

- Әби-бабаларым, әти-әнием, якын кешеләрем исән-сау, янымда булсалар, аларның йөзләрендә елмаю балкыса, шушы минем өчен иң зур бәхет.

***- Тормыш шигарең (девиз) бармы?***

- Беркайчан да бирешмәскә, көчле рухлы булырга!

Кыенлыклар кешене, аның холкын чыныктыралар, шуңа күрә авырлыклардан курыкмыйм.

***- Әгәр тылсымчы сиңа берәр теләгеңне чынга ашырырга тәкъдим итсә, нәрсә сорар идең?***

- Илләребезгә тынычлык, күгебезнең һәрчак аяз булуын теләр идем.

# Последний из великих

## Взлет и падение хана Тоштамыша



***Хан Каганбек, так удачно начавший «закручивать гайки» и наславший на Русь брата Араб-шаха, протянул недолго – в 1377 году он то ли умер, то ли был низложен своим «победоносным братом» и отослан править Улусом Шибанидов. В Новом Сарае воцарился энергичный Араб-шах (Арапша, Араб-оглан), который решил продолжить агрессивную политику набегом зимой 1377–1378 года совместно с «усмиренным» князем Нижегородским на Мохшу – мордовские амиры были разбиты и приведены к покорности, отказавшись от поддержки Мамая и Булак-хана.***

***Дмитрий ГРЕКОВ***

### Тимур и Тохтамыш против Орды

Но коллаборационизм не спас князя Дмитрия Константиновича (или же он снова чем-то прогневил своего босса) – после Мохши ордынцы налетели на Нижний Новгород и опять его спалили, а потом сделали то же самое с Рязанью. Новый султан явно хотел показать «распоясавшимся» урусам, «кто в доме хозяин»...

Тем временем на восточных рубежах Орды тучи ходили хмуро. Изгнанный из Поволжья в Синюю Орду Урус-хан ввязался в борьбу против набиравшего силу верховного амира Турана (фактического правителя Улуса Чагатаидов при марионеточных ханах, расширявшего его во все стороны кровавыми завоеваниями) Тимура (в Европе известен как Тамерлан). Агрессор сделал ставку на дальнего родственника Уруса – Тохтамыша, сына Туй-Ходжи, сбежавшего к Тимуру в Мавераннахр после казни отца в 1376 году.

В 1277 году Урус-хан то ли умер, то ли погиб в сражении против войска, которое возглавил сын Тохтамыша Джелал ад-Дин. Власть в Кок-Орде перешла к сыну покойного Токтакие, но он умер (непонятно отчего) буквально через два месяца, и ему наследовал брат Тимур-Малик. Он смог отогнать воинство Тохтамыша, после чего возгордился, запил и настроил против себя амиров, которые начали смотреть через кордон, в Мавераннахр.

В итоге, когда в 1379 году Тохтамыш снова вошел в Синюю Орду, он не встретил сопротивления – города сдавались без боя, а войско отказалось сражаться за Тимур-Малика, которого схватили и выдали сопернику, а тот приказал бывшего правителя казнить.

> *Но для честолюбивого Тохтамыша трон Кок-Орды был всего лишь ступенькой – в 1380 году он собрал «неисчислимые полчища» и выступил на Новый Сарай.*

Вопреки репутации отчаянного рубаки (созданной, впрочем, лишь одной второй битвой на Пьяне), Араб-шах не стал сражаться на два фронта (на западе Мамаева Орда, на востоке – Синяя), оставил трон, признав Тохтамыша своим сюзереном и выговорив свободу и мирную жизнь в своем Улусе Шибанидов – где они с братом Ибрахимом «лето проживая при вершине Яика, а зиму – в устье Сыра, ...с приятностию провели свой век». Его потомки основали в XVI веке династию Шибанидов, правившую в Хорезме до середины XVIII века.

Новый хан-султан взял на вооружение лозунг «Сделаем Орду великой опять». Для этого прежде всего требовалось победить Мамая и подчинить контролируемые им земли к западу от Волги и Крым. Но тут очень удачно случилась битва на Куликовская битва, в которой Мамай не только был наголову разбит «ничтожными урусами», но и лишился своего «легитимного прикрытия» – погиб марионеточный Булак-хан, а нового Чингизида под рукой у беклярбека уже не случилось.

Он, конечно, успел собрать очередное войско (скорее всего, принимая во внимание небольшое время между двумя сражениями, просто подошли те силы, которые

не успели явиться на Дон) и сразиться с Тохтамышем в октябре (или ноябре) 1380 года на реке Калке (той самой) – однако был снова разбит. Ну как разбит – почти всё его воинство перешло на сторону «законного государя», и пришлось бежать в родной Крым. Там он хотел укрыться в Кафе, у генуэзцев, на иностранной земле, но итальянцы его не пустили, и пришлось скакать в Солхат. Где его в конце 1380 (или в начале 1381) года догнали люди Тохтамыша и убили. Так закончилась карьера «второго Ногая», очередного «делателя ханов»...

## Как напасть на Москву

Итак, Улус впервые за многие годы (после смерти Бердибека – впервые за 41 год) был един, и «великая замятня» завершилась. Единственное, что мешало Тохтамышу насладиться властью и богатством, – наглые урусы. Нет, сперва русские князья, как полагается, поздравили нового султана с воцарением и наслали ему подарков. Но когда в 1382 году хан отправил на Русь своего эмиссара Ак-Ходжу с поручением вызвать князей в Орду на традиционное «переполучение ярлыков» от новой власти, доехать тот смог только до Нижнего Новгорода – урусы вели себя так дерзко, что ордынское посольство задало стрекача, опасаясь за свои жизни. Кто-то явно расправил груди после Куликовской битвы и намеревался отринуть «традиционные ценности»...

Пришлось срочно собирать новое войско, убивать русских купцов в Казани (чтобы не сообщили о походе на родину) и двигаться летом 1382 года на Русь. Как только Тохтамыш вступил на землю Рязанского княжества, Олег Великий поспешил присягнуть ему на верность, указать броды через Оку и дать проводников. В конце концов, Рязань грабила каждая набегавшая на Русь рать, и страдать за чужие московско-нижегородские грехи дураков не было. Затем ордынцев догнали сыновья князя Нижегородского Василий Кирдяпа и Семен Дмитриевичи, которые поступили аналогично – присягнули за отца, выдали проводников и сами остались при войске заложниками.

> *Вот так быстро Московское княжество, зазнавшееся после Куликовской битвы, осталось перед лицом нового нашествия в гордом одиночестве...*

Князья Московские повели себя в оной ситуации совсем неприлично – ссылаясь на «внезапное нападение без объявления войны» (ох уж эти коварные вороги, вечно они нас ловят в самое неподходящее время...), Дмитрий Иванович (да не один, а с женой и детьми) сбежал в Переяславль, затем в Кострому, а его двоюродный брат и «герой Засадного полка» Владимир Андреевич Серпуховской кинул свой Серпухов, чтобы метнуться... в Волок Ламский. Оба князя покинули свои столы под предлогом «сбора сил», но выглядело это и тогда, и сейчас очень некрасиво. Кстати, митрополит Киприан тоже сбежал – в Тверь, которую ордынцы трогать не собирались, ибо она всегда в спорах с Москвой была на их стороне.

Москву бросили на какого-то худородного «служилого князя» (то есть не имевшего княжества и подъедавшегося при чужом дворе), литвина Остея, «внука Ольгердова» (до сих пор морщащие лбы историки считают, что это либо Андрей, либо Дмитрий Ольгердович). Подтверждая то, как плохо пахла вся сия история, москвичи даже взбунтовались и собрали вече (!!!), на котором всё-таки решили оборонять город. Ну а Серпухов, к слову, Тохтамыш сразу взял и сжег.

## Как сжечь Москву

23 августа 1382 года Тохтамыш обложил Москву. И тут оказалось, что вся затея вот-вот пойдет прахом – свежепостроенные «белокаменные» стены были прочны, два штурма (24 и 25 августа) отбиты, хан оказался в тупике, москвичи смеялись над ним со стен. И тут проявилась лучшая черта правителей России всех времен – готовность пожертвовать собой... Княжичи Василий Кирдяпа и Семен (кстати, родные братья княгини Московской Евдокии Нижегородской) 26 августа поклялись, что хан удовольствуется выкупом и изъявлением покорности – войдет в город «поглядеть на достоприме-



*Московское вече по версии художника Васнецова*

чательности». Некоторые москвичи отчего-то засомневались, но княжичи настаивали: «Верьте нам, мы ваши князья христианские, вам в том клянемся».

*Ну и далее всё было понятно – делегацию с дарами и князем Остеем «татаровя» у ворот изрубили, ворвались в город, перебили примерно «от 10 000 до 24 000 человек» и сожгли всё...*

Помимо Москвы, ордынцы взяли и сожгли Владимир, Звенигород, Можайск, Юрьев, Лопасню, Переяславль-Залесский и Коломну (а потом и Рязань – похерив присягу Олега). Только Волок Ламский сумел отбиться – не очень обоснованно, но «по совокупности» князь Владимир Серпуховской носил кличку Храбрый. Однако сие была лишь ложка меда в бочке дегтя... Вот так глупость (чего было пыжиться, если не готовы стоять до конца?) и трусость московских князей (останься в городе Дмитрий или хотя бы Владимир – глядишь, и не сглупили бы) отменили все результаты достославного Мамаева побоища всего-то через два года. Но Дмитрий не унывал – вернувшись с войском, он наслал его... на Рязань (при любом раскладе жги Рязань – козел отпущения) «за предательство».



***Монета хана Тохтамыша***

А потом пришлось мириться с Тохтамышем – хан оказался умным и многого не требовал, всего-то получить ярлык, признать султана «отцом родным», вернуть долг по «выходу» с 1380 года, старшего сына Василия Дмитриевича сдать в заложники (сидел в Новом Сарае до смерти отца в 1389 году), да отдать Кашин князю Тверскому.

А вот Михаилу II Тверскому, снова решившему просить ярлык на Владимирское княжение, Тохтамыш отказал. Когда же в 1394 году помер князь Борис Нижегородский, хан отдал ярлык не его племянникам, а Василию I Дмитриевичу Московскому, который не погнушался тем, что сие было прямым юридическим нарушением, и «с благодарностию восприя»... На ближайшие 100 лет все, кто хотел сбросить вассальную зависимость от Орды, могли не беспокоиться.





# КҮРГӘЗМӘ ОНЫТЫЛМАСЛЫК ВАКЫЙГА БУЛЫП ХӘТЕРДӘ КАЛДЫ

***Дөньяда борынгы төркиләр аяк басмаган җир юклыгын Канада галимнәре дә раслады. Төрки халыкларның тирән тарихы белән кызыксыну бөтен дөнья галимнәре арасында беркайчан да кимемәгән, сүрелмәгән. Чөнки дөньяда яшәгән бөтен халыкларның да диярлек килеп чыгышы төркиләр тарихы белән бәйләнгән. Инде моның хаклыгы да торган саен ныграк ачыклана бара.***

***Фәрид Ширияздանов***

Тарихчы-галим Фәрди улы Рафаил Мөхәммәтдинов та үзенең «Тюрки в истории мировой цивилизации» әсәрендә моны тел өлкәсендәге фәнни ачышлар ярдәмендә ныгытып нигезли. Италия, Канада галимнәре дә бу өлкәдә кыйммәтле ачышлар ясыйлар.

2008 елның июль аенда Канададан Самарга «Степь и прерии» дигән гыйбрәтле күргәзмә килде. Анда Америка индеецларының һәм төрки халыкларның яшәү рәвеше, гореф-гадәтләре, телләре охшаш булуы турында кызыклы мәгълүматлар тупланган иде.



Күргәзмә Алабин исемендәге музейда узды. Монда Евразия киңлекләрендә яшәүче төрки халыклар һәм Америка индеецларының көнкүреш рәвешенең генә түгел, ә каннарының, генотипларының якынлыгы турында да кыйммәтле мәгълүматлар бар иде.

Америкада яшәүче индеецларның тарихы, килеп чыгышы һәм аларның борынгы цивилизациясе белән тирән кызыксыну төрле илләрдәге галимнәр арасында күптәннән яшәп килә. Хәзер төрки халыкларның Беринг проливы аша кайчандыр җәяүләп үтеп йөргәннәре дә билгеле.

Майя халкын һәм ацтекларны «индейско-монголоидный» типка кертеп, Италия галимнәре аларның Кавказ халыкларына аеруча якын булуын исбатлыйлар. Евразия төркиләре белән атабаски, навахо һәм апачи индеецларының гореф-гадәтләре охшашлыгын да ачыклыйлар.

Европа һәм Азия илләрендә яшәүче төркиләрнең гадәтләрендә, авыз иҗатында бүре образы зур урын алса, индеецларда кайот (Америка бүресе) шундый ук кулланышта була, һәм алар да аны изгеләштерәләр. Индеецлар, бу җәнлекнең ау серләрен өйрәнеп, үзләренең аучылык һөнәрендә һәм сугыш стратегиясендә уңышлы кулланганнар.

Индеецларның телләре, аш-су әзерләү тәртибе, дөньяга карашы Евразия төркиләренә охшаш булу белән берррәттән, аларның һөнәр осталыклары да охшаш икәнлеге билгеле. Мәсәлән, келәм туку өлкәсендә бу аеруча ачык күренә.

Әгәр дә үзбәкләрне алсак, келәм тукуны башлар алдыннан алар, корбан чалып, аксакалларны чакырып, мәҗлес уздыралар. Яңа узорлар ясарга исәпләгәндә дә, Аллаһы Тәгаләнең ризалыгын сорап, дога кылалар. Эш барышында да моңа багышланган махсус җырлар башкаралар. Туку осталыгы - аларда буыннан-буынга бирелеп килә торган, милли һөнәр.





Үзбәкстанда узган келәмнәр күргәзмәсендә катнашкан навахо нәселе вәкиле, туку тәртибе, орнаментларның һәм серле традицияләрнең охшашлыгы турында сокланып, үз халкының традицияләре дә шундый ук булуы турында сөйли.

Болгариянең Пловдив шәһәрендәге «Чипров келәмнәре» остасы Велика Стоева кулланган келәм туку традициясендәге охшашлык индеецларга тагын да якынрак булуы турында сөйли. Мондагы төсләр гаммасы, орнамент үзенчәлеге меңнәрчә еллар сакланып килә икән бит!




Келәмнәрдәге тирән серләр саклануы - ул әле тагын да гаҗәбрәк күренеш. Андагы түгәрәкләр Кояшны яисә мәңгелекне хәтерләтсә, күбәләкләр, кошлар сыны кеше җанын бер дөньядан икенчесенә күчерүчеләр икәнен, ахирәтне хәтерләтеп торалар.

Аларга караган саен кеше бу дөньяда вакытлыча булуын һәм үзен лаеклы тотарга кирәклеген искә төшерә. Мондый ук охшашлыкны азәрбәйҗаннарда да күреп була.

Төркиләрнең һәм индеецларның якынлыгы аларның телләре охшашлыгында да ачык күренә. Мәсәлән, Америкадагы Төньяк белән Көньяк сугышларында табиб булып катнашкан тел галиме Отто Рериг төрек телен яхшы белгән. Ул сиу һәм дакота кабиләләрендәге индеецларның Урал-Алтай тел төркеменә кергән төрки халыкларның тел үзенчәлекләренә якын булуы турында сөйли. Ә Швециянең тел галиме Стиг Викандер Истамбулда булганда төрек теле белән кызыксына һәм аның майя индеецлары теле белән охшашлыгына хәйран кала.

Ул ацтекларның атамасы «Акцилан» булуын ачыклый. Акцилан Ак Җылан дигән сүзне аңлата бит! Ә Ак Елан - татар халык әкиятләрендә - еланнар патшасы, пакьлек, тирән акыл, бөеклек, даһилык билгесе.



Сүзләрнең килеп чыгышындагы охшашлык та кызыклы. Мәсәлән, сүзнең ахырында Төркиядә, Кавказда ВАН иҗеген куллану - гадәти хәл: Нахичеван, Иреван, Ангираван, Ширван, Ораван. Ә индеецларда - Вахцетаван, Иханктонван, Саскачеван һәм башкалар.

Бу халыкларның гадәтләре, телләре охшашлыгын исәпләгәндә, аларның дөньяга карашы, фикерләү юнәлеше дә алгы планга баса. Монда алардагы диннәрнең борынгы тәңречелек һәм ша-

манизм принципларына тәңгәл килүе дә ачык күренә.

Индеецларның бәйрәмнәрендәге табигатьне, андагы дүрт стихияне һәм шуларның ияләрен зурлап, алар хөрмәтенә корбан чалу гадәте булуы да - шундый ук гаҗәп күренеш. (Алар да дүрт стихиягә табынган: Җиргә, Утка (Кояшка), Суга һәм Зәңгәр Күккә).




Шулай ук индеецларның да кеше үлгәннән соң аның җаны башка дөньга күчүенә ышанулары билгеле. Бу очракта алар да, моңа әзер булу кирәклеген аңлап, тормышны уңай алып барырга тырышканнар. Мәңгелеккә күчүгә зур әһәмият биргәннәр.

Индеецлар аулау өчен төзелгән таш кормаларны араннар дип атаганнар. Аран сүзе татарларда да бар бит! Безнең борынгы бабаларыбыз да шундый араннар (загоннар) кулланып, кыргый хайваннарны аулаганнар.

Аш-су ягын исәпкә алганда да, төркиләр белән индеецлар тормышының охшашлыгы ачык күренә. Алар итне киптерәләр, хәтта аны төеп, он хәленә китерәләр. Походта аны кайнар су белән болгатып, аш урынына кулланалар.

Ерак җирләргә, сугышларга барганда, ике халыкта да йомшак итне атныңияр астына кую гадәте булган. Ат тиресе белән консервацияләнеп, ит, үзенең кыйммәтле матдәләрен югалтмыйча, бер елга якын сакланган. Мондый ит ерак походларга барганда алыштыргысыз ризык булган. Моны бастырма дип атаганнар. (Дөрес, хәзер инде бастырманы бездә бөтенләй башкача әзерлиләр).

Индеецларда, Кавказдагыча, кукуруза, борчак һәм кабак кушып, ботка пешерү гадәте бар. Аларның мичләре дә, үзбәк тандыры кебек, балчыктан ясалган, тик ул җиргә күмелгән.

Канададан кадәр килгән бу күргәзмә шулкадәр гыйбрәтле, кызыклы һәм гаҗәп экспонатларга бай иде. Шуңа да ул гомергә онытылмаслык вакыйга булып хәтердә калды һәм төркиләр тарихына карата кызыксынуны тагын да көчәйтте.

Беләсе иде - безнең милләттәшләребез дә, бу күргәзмәне күреп, шундый ук тирән хисләр кичерә алдылармы икән? Ул бит Самарда бер ай буена барды!





## Как беженцы от погромов создали государство Израиль

*Мы продолжаем рассказ об интересной, но не очень любимой в нашей стране теме — зарождении мирового сионистского движения, создании Израиля и той роли, которую сыграли в этом выходцы из России*

*Дмитрий ГРЕКОВ*

# Россия – родина сионизма

*(Продолжение. Начало — в предыдущих номерах)*

### Новый старый «Тель-Авив»

Четвертый сионистский конгресс в Лондоне в 1900 году разбирался с проблемой ухудшения положения евреев в Румынии и миграции их оттуда. Также обсуждали вопрос о национальном спортивном движении. Но конкретных решений так и не приняли. В 1901 году на пятом конгрессе в Базеле Герцль сообщил о своей встрече с турецким султаном Абдул-Хамидом II, а также о развертывании деятельности Еврейского колониального банка. Однако часть делегатов, только что сформированная «Демократическая фракция», не были удовлетворены достижениями «правых консерваторов». Также было принято решение проводить в дальнейшем конгрессы не ежегодно, а раз в два года.

Воспользовавшись «годичными каникулами», оживились российские евреи — в Минске 22 августа 1902 года прошел второй съезд сионистов России. Собрались 300 делегатов, 100 гостей и 70 журналистов. Обсуждали вопросы, которые дискутировались на прошедших всемирных конгрессах, и также разделились на религиозных «ортодоксов» и светских «демократов».

В сентябре 1902 года вышел написанный на немецком языке роман Герцля «Альтнойланд» («Старая новая страна») — утопия, описывающее процветание в Палестине еврейского государства в 1923 году. В том же году книга была переведена на иврит под названием «Тель-Авив», что и стало именем нового города во время его основания в 1949 году. Однако многие евреи увидели в этом «пустые фантазии», и оппозиция




*Альтнойланд*

Герцлю получила новый импульс к развитию.

19–20 апреля 1903 года случился мировой скандал — во время погрома в Кишиневе было убито 38 евреев, 394 ранено, разгромлено 1 350 домов. Герцль даже приехал в Россию и встретился с министром внутренних дел Павлом Плеве, которого считали одним из инициаторов погрома. Событие вызвало огромный мировой резонанс и обсуждалось на шестом сионистском конгрессе в Базеле в том же году. Многие делегаты согласились, что «надо строить выездной Эрец-Исраэль», только там евреи будут счастливы. Но где? В Палестине турки окончательно запретили, отказавшись выдать «хартию». Англичане предложили Уганду — туда решили послать специальную комиссию для обследования. Естественно, делегаты раскололись на группы «угандийцев» и «только Палестина — только хардкор».

### Оборона проживающих — дело рук самих проживающих

Именно русская делегация конгресса ушла при начале обсуждения «угандийского вопроса», став ядром движения «Ционей Цион»



*Кишинев после погрома*

(Сионистский Сион) — крыла сионистов, которые настаивали, что по религиозным, историческим и культурным соображениям никакое иное место, кроме Палестины, не может стать еврейским государством. А когда 3 июля 1904 года Теодор Герцль скончался в возрасте всего 44 лет, «угандийский вариант» окончательно умер — на седьмом конгрессе в Базеле в 1905 году комиссия, обследовавшая эту территорию в Африке, отчиталась о том, что это место «не пригодно для проживания евреев». Под давлением «Ционей Циона» была принята резолюция о запрещении создавать Эрец-Исраэль за пределами Палестины. Естественно, часть делегатов откололась («территориалисты») и создала Еврейское территориальное общество.

В России же из-за участившихся погромов и роста антисемитизма (на фоне общего роста ксенофобии и шовинизма) во время войны с Японией начали стихийно появляться организации еврейской самообороны. Поначалу в такие формирования входило относительно большое число участников. Так, например, в Киеве организация самообороны насчитывала около 1 500 человек, в Кишиневе — 1 000, а в Одессе еще больше. Однако из-за нехватки оружия и боеприпасов всех людей нельзя было использовать. Да и оказалось, что не было нужды в столь многочисленных отрядах. Опыт показал, что даже в большом городе 200–300 хорошо вооруженных участников самообороны было совершенно достаточно, чтобы ликвидировать в зародыше любую попытку устроить погром. В городах поменьше хватало и нескольких десятков человек. Все это, разумеется, при условии, что войска и полиция не выступали на стороне погромщиков, храня, по крайней мере, нейтралитет.

## Добро должно быть с кулаками

В Палестину идею самообороны принесли с собой зачинатели Второй алии, прибывшие в дни праздника Хануки в 1904 году. То были гомельцы, которые уехали организованной группой (13–14 человек) вскоре после погрома, разразившегося в их городе в сентябре 1903 года. Они принесли с собой не только идею, но и первый практический опыт защиты от внешнего врага собственными силами. Гомельские отряды самообороны носили символическое наименование «Гиборей Цион» (Герои Сиона).



*Менахем Усышкин*

В декабре 1904 года в сионистском журнале «Новая жизнь» Менахем Усышкин опубликовал статью «Наша программа». В ней утверждалось, что религиозно-духовный и конгрессно-дипломатический сионизм — не что иное, как разные формы одной сущности, а именно — политического сионизма. В политическом возрождении любой нации участвуют три слагаемых: народ, территория и внешние обстоятельства. Для того чтобы любой народ оказался в состоянии построить самостоятельный политический и культурно-экономический центр, он должен готовить себя к этой цели при помощи мощной и дисциплинированной организации и обладать большими денежными средствами; должен быть стойким и запастись терпением. Однако прежде всего необходима готовность жертвовать сиюминутными нуждами ради интересов будущего. При отсутствии всех этих предпосылок любые попытки создать государство обречены на провал.

Таким образом, в мировом еврейском движении верх взял курс на построение собственного государства именно в Палестине, «на священной земле предков», и для достижения этой цели сионисты были готовы бороться всеми доступными им способами… Всё больше людей переходили от разговоров, написания статей, книг и «ведения полемики» к конкретным делам.

Дошло даже до того, что кайзер Вильгельм II посетил Палестину в то же самое время, что и Герцль с делегацией сионистов, обещая им накануне «поговорить с султаном». Но увы — беседа с Абдулом Хамидом II и собственными дипломатами (антисемитами, да еще и не хотевшими «обострять вопрос» с Англией, Францией и Россией) охладила рвение императора, и скоропостижный «роман с евреями» закончился.

Хөрмәтле укучыларыбыз, сезнең игътибарыгызга милләттәшебез – Әхсән Ихсановның шигырьләрен тәкъдим итәбез.

Әхсән әфәнде Самар өлкәсе Шенталы районының Денис авылында 1946 елның 11 апрелендә дөньяга килгән.

Әтисе, малаеның тууын күрә алмыйча, ике ай алдан вафат булган. Ул вакытта алар сигез туган: бишесе - әниләре белән, өчесе чит җирдә яшәгәннәр. Аналары янындагы иң олы абыйларына ун яшь булган.

Әхсән әфәнде 1953 - 1963 елларда авылның урта мәктәбендә белем алган.

1964 - 1969 елларда Ульяновск авыл хуҗалыгы институтының механиклар әзерләүче факультетында укып, инженер-механик һөнәрен үзләштергән.

1969 - 1976 елларда колхозда инженер, рәис булып хезмәт иткән.

1969 елда Сәгыйдә исемле чибәр кыз белән гаилә корып җибәргәннәр. Ә 1970 елда уллары дөньяга килгән.

1977 - 2011 елларда Әхсән Ихсанов автозаводта (УАЗ) механик, цех начальнигы, производствоның баш механигы булып эшләгән.

2001 елда лаеклы ялга чыкса да, хезмәтен дәвам иткән.

Милләттәшебез УАЗның «Хезмәт ветераны», СССР һәм Россиянең «Хезмәт ветераны» дигән дәрәҗәле исемнәренә лаек булган.

2001 - 2003 елларда, якшәмбе көннәрендә, мәдрәсәдә дини белем алган ул. 2012 елда изге җирләргә хаҗ кылырга да насыйп булган аңа.

Бүгенге көндә Әхсән әфәнде һәм аның хәләл җефете Сәгыйдә өч онykларына куанып гомер итәләр. Үзләре дини кешеләр буларак, нәсел дәвамчыларына да ислам нигезләрен аңлаталар, догалар өйрәтәләр.

Илһам килгәндә, Әхсән абый шигырьләр яза икән. Шигъриятькә карата мәхәббәтне аңарда туган авылы мәктәбенең татар теле укытучысы - мәрхүм Мөхәммәт Әхмәдиев уяткан. Моның өчен Әхсән әфәнде мөгаллименә бүгенге көнгә кадәр бик рәхмәтле булып яши.

# «АЛЛАҺЫ, КАБУЛ ИТЕП, ЯРДӘМ БИРСЕН ЧЫН МӨСЕЛМАН БЕЗГӘ БУЛЫРГА!»

## *Нәсыйхәт*

*Өйрәнгәннән бирле, һәр намазны*
*Вакытында тырышам укырга.*
*Аллаһы, кабул итеп, ярдәм бирсен*
*Чын мөселман безгә булырга!*

*Кабул булсын кылган гамәлләрем,*
*Гөнаһлы гына була күрмәсен.*
*Фәрештәләр миңа ярдәм бирсен,*
*Шайтан гына тия күрмәсен.*

*Гомерем буе яхшы кешеләр*
*Дус булдылар фани дөньяда.*
*Зиһен бирдең, Раббым, укырга диеп,*
*Коръән бирдең минем кулларга.*

*Һәрвакытта мактыйм*
*тормышымны,*
*Рәхмәт әйтәм ихлас күңелдән.*
*һәрвакытта, Раббым,*
*Сиңа зикер итәм,*
*Сүнмәсен лә нурлар күземдә.*

*Туры юлдан йөрт, газиз Аллам,*
*Ачлык, ялангачлык безгә тимәсен.*
*Синең ярдәм белән, Бер Аллаһым,*
*Күрдем татлы Зәм-Зәм чишмәсен.*

*Балаларга, оныкларга һәрчак*
*Дин турында сөйлим, укырга*
*Өйрәтәмен чынлап гарәп телен,*
*Хаҗ гамәлен ничек кылырга.*

*Озын гомер, дуслар, Аллаһыдан*
*сорыйм,*
*Тыныч булсын сезнең җаныгыз.*
*Ак бәхетләр, чиксез зур шатлыклар*
*Алып килсен көн дә таңыгыз.*

*Саулык-сәламәтлек телим*
*барчагызга,*
*Тыныч булсын һәрчак дөньялар.*
*Исән булып, кайгы-хәсрәт күрми,*
*Яшәгез сез, дуслар, туганнар!*

## *Игелекле булыйк*

*И, дускаем, ихлас күңелеңнән*
*Ярдәмле бул һәрбер ятимгә.*
*Яхшы эшнең әҗер-саваплары*
*Тиңдәш булыр ахирәтеңдә.*

*Пәйгамбәрнең язган хәдисләрен*
*Укыгыз сез, үрнәк алыгыз.*
*Чын күңелдән кылсаң игелекләр,*
*Тынычланыр сезнең җаныгыз.*

*Авыруларның, тирә-күршеләрнең*
*Белеп торыйк һәрчак хәлләрен.*
*Истә тотсак дуслар-туганнарны,*
*Аллаһ бирер безгә ярдәмен.*

*Мәчетләрдә укыган намазларның*
*Күбрәк була әҗер-савабы.*
*Онытмасак каберлекләр өстен,*
*Игелекнең булыр дәвамы.*

Дөрес юлда булсак, «Кәүсәр» чишмәсенең
Аллаһ бирер суын татырга.
Кардәшлекне онытмагыз, диеп,
Һәрчак әйтәм оныкларыма.

Онытмасак туган ягыбызны,
Шатланырлар әби-бабайлар.
Аллаһыдан сорыйм: әти-әниләргә
Барса иде безнең догалар.

## Туган авылым

Туган якка кайтсам, җиргә ятып,
Эчәр идем чишмә суларын.
Имәнлеккә барып, искә алыр идем
Яшьлегемнең барча дусларын.



Малай чакта бергәләшеп көн дә
Бара идек урман буена.
Җиләк җыеп арыгач, коена идек
Гөрләп аккан инеш суында.

Инеш суы салкын, чөнки ул башлана
Калкулыкта чыккан чишмәдән.
Яшьлек искә төшкәч, күзгә яшьләр килә,
Күңел тула моңсу хисләрдән.

Менә - кичү юлы, аннан - зур Биек тау,
Тау башында ике кабер бар.
Аны узган чакта, кыйблага карап,
Дога кыла барча юлчылар.

Авыл уртасында – манаралы,
Өч гасырны күргән ак мәчет.
Иртә һәм кич анда яңгырый азан,
Намазга чакыра безне, нур чәчеп.

Инеш суы ага Чирмешәнгә,
Кушыла алар авыл очында.
Шомырт җыя идек әрәмәдә,
Балык тоттык буа суында.

Нинди матур безнең Сабантуйлар!
Анда - көрәш, атлар узышы,
Чүлмәк вату, авыл көен җырлау –
Минем өчен йөрәк сагышы...

Туган авылым, оныта алмыйм сине,
Гомерем буе минем исемдә.
Туган мәктәп, беренче укытучым
Һәрчак булыр минем күңелдә.

Туган авылым, синдә иң беренче
Әти, әни дигән сүзебез.
Син өйрәттең безгә татар телен –
Иң кадерле туган телебез.

Туган авылым, сине онытмаска
Вәгъдә бирсен барча кешеләр.
Шул вакытта яшәр туган авыл,
Шатлык белән тулар күңелләр.

## Авыр еллар

Белмим, әллә күпкә, әллә бик озакка,
Әллә инде гомерем буена,
Ачлык, ялангачлык күргән яшь көннәрем
Һәрвакытта минем уемда.

Яз башында туң бәрәңге җыеп
Ашый идек, пешереп учакта.
Җәен кузгалаклар, балтырганнар җыеп,
Калдыра идек киптереп кышлыкка.



Бишебезгә бар иде бер бишмәт,
Бер пар калуш, бер пар чабата.
Беребез салып, икенчебез киеп,
Уйный идек чыгып без йортка.

Менә шулай үстек барчабыз да –
Күрше малайлары, кызлары.
Бирешмичә, авырлыкны җиңде
Яшьлегемнең барча дуслары.

Бик күп еллар үтте ул вакыттан,
Хәзер үзебез әби-бабайлар.
Бер Аллаһым, андый авырлыкны
Күрмәсәләр иде балалар.

## Газиз әниемә

Газиз әнкәм, нинди матур сүз ул -
Иң кадерле кеше син миңа.
Күпме кайгы-хәсрәт күрдең без үскәндә,
Чиксез рәхмәт әйтәм мин сиңа.

Күпме күз яшьләре түктең безнең өчен,
Армый-талмый көн дә эшләдең.
Балаларым ач булмасын, диеп,
Ял итүне бер дә белмәдең.




Мәктәп бетереп, киттем мин укырга,
Пенсияңне, әнкәй, син миңа
Бирә идең, үзеңә калдырмыйча,
Әйтә идең, улым, кайгырма.

Һөнәр алгач, без таралдык, әнкәй,
Ил буенча - төрле якларга.
Син, мескенем, калдың, һәр көн безне көттең,
Без оныттык хат та язарга.

Хәзер инде, мәрхүмкәем, соң булса да,
Гафу ит син, кичер, орышма.
Газиз Аллам, сорыйм: әнкәемә
Урын бирсәң иде оҗмахта.

## Изге теләкләр

Намаздан соң биш баласын җыеп,
Сәке уртасына утырып,
Әни безгә Коръән укый иде,
Багышлатып, дога кылдырып.

Дин турында күп хәдисләрне
Гарәпчәдән итеп тәрҗемә,
Без - балаларына җиткергән өчен
Бик зур рәхмәт әйтәм әнигә.

Хаҗ кылуны Аллаһ фарыз иткән
Һәр мөселман булган кешегә.
Әниемнең шушы изге хыялы
Бик күп тапкыр керде төшемә.

Әни баралмады хаҗ кылырга,
Исәнлеге чамалы булганга.
Мин сүз бирдем - барып анда,
Әнием өчен тәваф кылырга.

Казаннан мин очтым Акабага,
Аннан Мәдинә белән Мәккәгә –
Мина үзәнендә, Гарәфәдә булып,
Мөздалифәдә тәүбә итәргә.

Кәгъбәтуллаһны җиде
тапкыр әйләнеп,
Эчтем шифалы «Зәм-Зәм» суларын.
Аннары, намаз укып, дога кылдым,
Күрдем изге Өхед тауларын.

Пәйгамбәребез узган хаҗ юлларын
Ярдәм бирде Аллаһ үтәргә.
Әль-Хәрамда намаз, дога укып,
Янә Мәдинәгә күчәргә.

Пәйгамбәребез каберен күрдем,
Намаз укып, кылдым догалар.
Аллаһ кабул итсен изге гамәлләрне,
Риза булсын барча туганнар.

Һәр кешегә тырышырга кирәк
Хаҗ гамәлен үзенә кылырга.
Аллаһ кабул итеп, ярдәм бирсен
Чын мөселман безгә булырга.

## Изге ай

Бисмилләһи, диеп башлыйм,
Укыгыз сез бу шигырьне.
Ислам динен зурласагыз,
Аллаһы зурлар сезне.

Бүген мөэминнәргә шатлык –
Рамазан ае керә.
Ураза тоткан кешегә
Аллаһы рәхмәтен бирә.

Игелек эшләү фарыздыр
һәр мөэмин мөселманга.
Намаз укып, ураза тотсак,
Әҗере булыр алда.

Рамазан ае кергәчтән,
Җиргә нурлар сибелә.
Тәравих намазын укысаң,
Ял булыр йөрәгеңә.

Бу айда, дин кардәшләрем,
Ифтарларны уздырыйк.
Ятимнәргә ярдәм итик,
Тик изге эшләр кылыйк.

Биш намазны калдырмыйча,
Укыймын Коръән-Кәрим.
Пәйгамбәргә салават әйтеп,
Дөньяга тынычлык телим.





## Сагыш

Сагынам, дуслар, туган авылымны,
Шарлавыклы инеш суларын.
Тагын сагынам туган мәктәбемне,
Гөрләп торган Сабантуйларын.

Сагынам әти-әни, туганнарны,
Яшьлегемнең барча дусларын.
Күп җиләкле яшел аланнарны,
Чикләвекле урман буйларын.

Яшәсәм дә мин хәзер чит җирдә,
Күңелем һаман туган авылда.
Кайткан саен гает бәйрәмендә
Җыелышабыз мәчет янында.

Намаздан соң каберлеккә барып,
Дога кылып әти-әнигә,
Искә алып дуслар, туганнарны,
Сүз бирәбез тагын килергә.

Онытмаска каберлекләр өстен
Вәгъдә бирсен барча кешеләр.
Шул вакытта яшәр туган авыл,
Шатланырлар әти-әниләр.

# “МИРАС” САМАРНЫҢ МӘДӘНИ ТОРМЫШЫНДА ЯКТЫ ВАКЫЙГАЛАРНЫҢ БЕРСЕНӘ ӘВЕРЕЛДЕ




***28-30 апрельдә Самарның «Чайка» Мәдәният сараенда IV «Мирас» Халыкара татар мәдәнияте конкурс-фестивале уздырылды.***

***Рәмис АЙМӘТ,*** *Татарстан язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрь, җырчы, Муса Җәлил премиясе лауреаты, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе.*

***Александр Массов*** *фотосурәтләре*





Самар шәһәрендә үткәрелгән IV “Мирас” татар мәдәнияте Халыкара фестиваль-конкурсыннан зур тәэсирләр белән кайттым. Әлеге күркәм чарада жюри әгъзасы сыйфатында икенче мәртәбә катнашуым. Ул 30 апрельдә “Акчарлак” Мәдәният сараенда гала-концерт белән тәгәлләнде. Быел «Педагог һәм остаз елы»на багышланып, онлайн һәм офлайн форматларда үткәрелгән фестиваль-конкурста барлыгы 500дән артык милләттәшләребез катнашып, үзләренең сәләтләрен күрсәттеләр.

Конкурс-фестивальнең географиясе елдан-ел киңәя бара. Быел анда Самар, Оренбург, Пенза, Ульяновск, Әстерхан, Свердлау, Чиләбе өлкәләре, Татарстан, Башкортостан, Чувашстан, Кырым Республикалары, Краснодар крае, Санкт-Петербург, Мәскәү шәһәрләре, хәтта Үзбәкстан, Казахстан, Италия, Франция, Америка Кушма Штатлары, Кытай, Төркия, Швеция, Чехия кебек чит илләрдә яшәүче милләттәшләребез дә катнашу бәхетенә ирештеләр.

“Мирас” Самарның мәдәни тормышында якты вакыйгаларның берсенә әверелде. Берничә ел эчендә әлеге конкурста 2500дән артык конкурсант катнашып, үзләре-








нең сәләтләрен күрсәтергә өлгерделәр.

Конкурста катнашучыларның иҗатларын Винера Ганиева рәислегендәге компетентлы жюри бәяләде. Вокал: Винера Ганиева, Идрис Газиев, Рөстәм Асаев; хореография: Таһир Латыйфуллин, Чулпан Закирова, Рәшит Гыйззәтуллин; музыка инструментларында башкару: Рәсим Ильясов, Евгений Афанасьев, Илфат Шәехов; нәфис сүз: Рәмис Аймәт, Зөлфия Нигъмәтҗанова, Әлфия Баһаветдинова; декоратив-гамәли сәнгать: Булат Гыйльфанов, Гөлнара Насыйрова.

Гала-концертта катнашучыларны Самар өлкә татар милли-мәдәни автономиясенең рәисе Әнвәр Горланов, Самар өлкәсе эчке сәясәт департаментының милли һәм конфессия сәясәте идарәсе җитәкчесе вазифаларын башкаручы Марина Купцова сәламләде. Самар өлкәсе Губернаторы Дмитрий Азаров конкурста катнашучыларга үзенең котлау телеграммасын юллаган. Бөтендөнья татар конгрессы Башкарма комитеты рәисе Данис Шакировның сәламләү адресын тамашачыларга укып ирештерделәр.

## Тарихи мәгълүмат

"Мирас" элек "Татар балалары җырлый" фестивале буларак үтә иде. Ул, 1997 елдан алып, Самар өлкәсенең "Туган тел" татар җәмгыяте һәм әлеге оешмага нигез салучыларның берсе – Мансур Ямалетдинов тарафыннан уздырыла башлый. Аннары "Татар балалары җырлый" фестивален оештыру эшләренең һәм чыгымнарының төп өлешен Самар шәһәренең татар милли-мәдәни мөхтәрияте үз өстенә ала. Бу оешманы "ВолгоПродМонтаж" фирмасының генераль директоры урынбасары Рифкать Хуҗин җитәкли иде. Самар өлкәсенең мәдәният министрлыгы, Халыклар дуслыгы йорты да үз ярдәмнәрен күрсәтеп тордылар. "Мирас" исеме астында исә фестиваль 2017 елдан бирле уздырыла. Директоры – Искәндәр Сәитов.



"Мирас" фестиваль-конкурсның иң зур бүләге - Гран-прига ике иҗат төркеме лаек булды. Алар: "Батыр егетләр" вокаль ансамбле (Казан) һәм "Асылъяр" җыр, музыка һәм бию ансамбле (Оренбург).

Татар халкының телен, мәдәниятен, гореф-гадәтләрен саклауны, милли мирасыбызны яшь буынга җиткерүне, сәләтле яшьләребезне барлау, аларны зур сәхнәгә чыгаруны максат итеп куйган әлеге проектның авторы һәм аның алыштыргысыз оештыручысы - тынгысыз җанлы милләттәшебез Сәетов Искәндәр Зиннур улы. Аеруча бүген, милләтебез алдында төрле катлаулы хәлләр, вәзгыятьләр туып торган бер заманда, татар халкы Искәндәр әфәндедәй шәхесләргә мохтаҗ. "Человек-оркестр" дигән гыйбарә нәкъ менә шундый кешеләр хакында әйтелә торгандыр ул.

Гала-концерт фестиваль гимны белән тәмамланды.

# Мидхәт ӘМИНОВ: «АЛАР БЕЛӘН МИН УТКА ДА, СУГА ДА КЕРЕРГӘ ӘЗЕР»

*30 елга якын гомер… Азмы әллә күпме? Үзешчән артистларны берләштергән иҗади коллектив өчен – бу бик озын юл, минемчә. Самарның «Идел» татар халык эстрада ансамблен өлкә халкы да, күрше төбәкләр дә бик яхшы белә һәм ярата.*

***Эльмира СӘЙФУЛЛИНА***




Коллективка нигез салучы һәм аның алыштыргысыз җитәкчесе Мидхәт Әминов ансамбль оештырырга карар кылган вакытта, бу проект шулкадәр озын гомерле булыр, дип уйладымы икән? Энергиясе ташып торган үзенчәлекле музыкант һәрвакытта да үз тирәсендә талантлы, тырыш һәм татар көйләрен, татар моңын яратучыларны туплый белгән. Еллар аккан судай узган саен ансамбльнең составы да үзгәреп торган. Әмма коллективта 26 ел дәвамында Мидхәт абый белән бергә утны да суны да кичкән артистлар бар. Сүз ансамбльнең профессиональ музыканты Лилия һәм сандугачтай моңлы солисткасы Миләүшә Хәлимуллиналар турында…

Элек бераз «Идел»нең тарихы белән танышып китү урынлы булыр, дип уйлыйм.

Кошки районы Иске Җүрәй авылы егете Мидхәт Әминов 1976 елда елга техникумына укырга керү теләге белән Куйбышевка килә. Әмма төрле сәбәпләр аркасында аның хыялы чынга ашмый. Шулай да, күпчелек авыл кешеләре кебек үк, егет аптырап калмый, «Кабельный» завод каршында эшләп килүче училищега урнаша. Тулай торакта бүлмәбирәләр, көненә өч тапкыр ашаталар, стипендия түлиләр – барысы да әйбәт. Әмма Мидхәтнең күңеленә нидер җитми. Ә төгәлрәк, балачактан җырга-моңга гашыйк булган талантлы егеткә татар мохите, татар көе, тальян моңы җитми. 1977 елда, шуны сизгән сыман, Мидхәтнең балачак күршесе Сания Нуретдинова аны «Ялкынлы яшьлек» ансамбленә чакыра. Егетне ансамбльгә биюче итеп алалар. Җиңел сөякле авыл егете талантын бик тиз таныта һәм 20 ел дәвамында бию труппасының солисты булып тора. Ул башкарган легендар «Муса Җәлил» ролен тамашачылар әле дә сагынып искә алалар.

- Миңа шундый әһәмиятле рольләр ышандырган, профессиональ нечкәлекләргә өйрәткәне өчен Альберт Закировичка бик рәхмәтлемен, - дип сөйли бүген дә Мидхәт абый.

Искәрмә рәвешендә булса да, әйтеп китмичә булдыра алмыйм: 1979 – 1982 елларда Мидхәт Әминов армия хезмәтен чик буе гаскәрләренең диңгез частендә үтә, ниһаять, хыялы чынга аша.

«Ялкынлы яшьлек» ансамблендә Мидхәт танылган якташыбыз, виртуоз гармунчы, музыкант Рөстәм Вәлиев белән таныша. Ул елларда әле Рөстәм гади, әмма бик
















талантлы һәвәскәр артист буларак кына билгеле булган. Менә шушы танышу Мидхәт Әминовта музыка коралларына мәхәббәт уята, бию-че егетне бүген без белгән уникаль музыкант итә.

- Рөстәмнең җирле оста (Киселев) ясаган гармуны бар иде. Аның шушы гармунда уйнаганын ишеткәч, бу инструментка мәңгегә гашыйк булдым, үземә дә шундый гармун алу хыялы белән яндым. Әмма, авыр заманалар булганлыктан, хыялым 1995 – 1996 елларда Хәбил һәм Илшат Бикташевлар ярдәмендә генә чынга ашты. Моның өчен бу егетләргә рәхмәтләрем чиксез. Бу гармун бүгенге көндә дә минем иң якын дустым булып кала. Аның моңы бернинди гармун тавышына да охшамаган, ул үзенә бер төрле, аерым, сихри, кыскасы, искиткеч, - дип елмая артист.

Озын сүзнең кыскасы, артист үсә, күпкырлы талант иясенә 20 елдан артык бер юнәлештә генә атлауның кызыгы калмый. Нәкъ шул вакытта Мидхәт Әминовның күңелендә үз коллективын җыю, ансамбль булдыру теләге туа. Ачык йөзле, аралашучан артистның күпсанлы танышлары арасында профессиональ оркестрда уйнаучы саксофонист Али Губанов та була. Ул Мидхәтнең идеясын хуплый, һәм 1996 елда «Идел» ансамбле барлыкка килә. Аның иң беренче составында Самарның иң талантлы һәвәскәр артистлары - Галия Мостафина, Раилә Сибгатуллина, Али Губанов, Искәндәр Әхмәтов булган. Ә җитәкче беренче көннән бүгенгә кадәр - Мидхәт Әминов. Соңрак коллективка Ринат һәм Халидә Вәлиевлар, Гөлназ Баһаветдинова, Рәфгать Фәретдинов кушылалар.

- Ансамбльнең беренче гастрольләре гел өлкә авыллары буйлап узды. Музыкантыбыз Али Губановның төп эш урыны белән ансамбль тормышын параллель рәвештә алып баруы кыенлаша башлады, безгә тиз арада тагын бер музыкант табарга кирәк иде, - дип искә ала Мидхәт абый.

Эзләнә-сөйләшә торгач, татарча сарафан радиосы бик тиз нәтиҗә бирә. Альмира Мингачева (автор искәрмәсе: бүген без аны хоккейчы Таһир Мингачевның әнисе буларак беләбез) училищеда музыка бүлегендә укучы дусты Лилия Абдул-




линаны тәкъдим итә. Мидхәт абый шәһәр читенә, «116 километр» бистәсенә талантлы пианистканы эзләп бара. Билгеле инде, татарлар, беренче чиратта, җитәкчене чәй табынына чакыралар, аннары сүз Лилия турында була. Кызның таланты һәм синтезаторда уйный белүе аңа бик ошый, әмма артистның бары тик 15 яшендә булуы бераз куркыта. Шулай да, Мидхәт абый Лилияне ансамбльгә ала һәм һәр репетициягә үзе барып алып, үзе илтеп куя башлый.

- Минем балачагым татар җырларына, гармун көенә төренеп үтте. Әнием Рәзинә һәм әтием Багзяр икесе дә матур җырлыйлар, әтием баянда да уйный. Шуңа күрә музыкага омтылышымны алар бик хупладылар, миңа профессиональ музыкаль белем бирергә тырыштылар. Мин башта музыка мәктәбен, аннары педагогика училищесының музыка бүлеген, аннан соң сәнгать академиясенең эстрада бүлеген тәмамладым. Ә балачак хыялым – синтезаторны миңа әнием Гарәбстанга командировкага баргач алып кайткан иде, - дип сөйли Лилия. – Мидхәт абый белән танышкан вакытта зур сәхнәдә чыгыш ясау турында уйлап та, кузаллап та караганым юк иде. Ничек курыкмыйча «Идел» ансамбленә килеп кушылганымны, миңа кадәр ничәмә еллар зур сәхнәләрдә җырлап йөргән артистлар өчен аккомпаниатор булырга ризалашканымны сизми дә калдым. Равил белән Альмира Мингачевларга миңа сәхнә тормышын бүләк иткәннәре өчен бүген дә рәхмәтләмен.



Озак та үтми, Мидхәт абый, Рәфгать Фәретдинов киңәше буенча, искиткеч моңлы, матур тавышлы Миләүшә Минбаева белән таныша һәм аны «Идел»гә чакыра. Ул Шенталы районы Татар Әбдекие авылыннан.

- Мин үземне белгәннән бирле сәхнәдә, - дип башлады сүзен Миләүшә. – Әтием Минәхтәм дә, әнием Дания дә - җыр-моңга гашыйк кешеләр, аларның бөтен күңелләре сәхнәгә, иҗатка бәйле иде. Әнием бик матур җырлый иде, клубта - сәнгать җитәкчесе, ә әтием - оста баянчы, 40 елдан артык, соңгы сулышына кадәр диярлек авыл клубында эшләде. «Идел» беренче гастрольләре белән безнең авылга килгән вакытта мин – үсмер кыз, кайчан да булса бу коллектив белән бер сәхнәдә чыгыш ясармын, дип уйларга да батырчылык итмәдем. Әле әтиемнең: «Минем кызымны да үзегезгә алыгыз», - дип шаяртканы хәзер дә исемдә. Тиздән Мидхәт абый мине ансамбльгә чакырыр, дип ул вакытта мин дә, ул да уйламаганбыз да. Минем өчен «Идел» артисты булу беркайчан да чынга ашмаслык хыял иде ул чакта, - ди Миләүшә.

- Әйе, чыннан да, шулай, - дип кушылды сүзгә Мидхәт абый. – Әбдекидә кунакта булган йорт, безнең булачак җырчыбызның туган йорты икән, дип кем уйлый бит. Безне якын туганнарыдай каршы алган Минәхтәм абый белән Дания апа шундый талантлы бала үстергәнне дә, Миләүшәнең җырлавын да безнең ансамбльгә килгәч кенә ишеттем. Аның беркемнекенә дә охшамаган тембры, бәрхет кебек, зәвыклы тавышы беренче ноталарыннан ук гашыйк итә. Бу талант аңа әти-әнисеннән күчкән, дип уйлыйм. Мин аларга безгә шундый артист үстереп биргәннәре, ә Рәфгатькә Миләүшәне безнең ансамбльгә китергәне өчен бик рәхмәтлемен.

- 1998 елда (кайсы айлар икәнне хәтерләмим инде) телефон шалтырады, трубканы алгач, Мидхәт Әминовның тавышын ишетүгә, йөрәгем ешрак тибә башлады, ә ул мине репетициягә чакыргач, аякларым калтырап, чак кына егылып китми калдым. Трубканы куйгач та, берникадәр вакыт



өнемме бу, төшемме, дип аптырап тордым, - дип елмая бүген инде Самар тамашачысының иң яраткан артистларының берсе булган Миләүшә Хәлимуллина (Минибаева). – Ансамбль коллективы белән беренче очрашуым бүгенгедәй исемдә. Лилия белән иң беренче ноталарны берләгәнебез хәтеремдә матур истәлекләр булып мәңге сакланыр.

- Шул беренче репетициянең азагында Миләүшә инде күптән безнең коллектив вәкиле булып тоелды, бер-беребезне әллә кайчаннан бирле беләбез кебек иде, - ди Лилия. – Миләүшәнең безнең коллективка килүенә барысыннан да ныграк мин шатланганмындыр. Чөнки калган артистлар миннән күпкә олырак иде, ә Миләүшә белән без икебез дә бер яшьтә, бик тиз дуслашып киттек. Бераздан туганлаштык та – килендәшләр булып куйдык, - дип елмая Лилия Хәлимуллина (Абдуллина). – Гастрольләргә барыр өчен, һәрвакыт автобус ялларга туры килә иде. Шулай, бер сәфәребезгә Оренбург өлкәсе Әсәкәй районы егете Ринат Хәлимуллин йөрткән машинага утырып барырга туры килде. Менә шунда алар Миләүшә белән танышып киттеләр, очраша башладылар. Бераздан алар мине Ринатның игезәк туганы Марат белән таныштырдылар...

Шулай итеп, дус кызлар, игезәк егетләргә кияүгә чыгып, килендәшләр булып китәләр һәм икесе дә бер фамилия йөртә башлыйлар. Миләүшәнең беренче баласы Салават туа, озак та үтми, Лилиянең Эльвинасы дөньяга аваз сала.

- Алар декрет ялына да тукталмадылар диярлек, - дип сөйли Мидхәт абый. - Биләүгә төргән сабыйларын алып, репетицияләргә йөрделәр, а балалар шул тавышта да урындыкта яки эскәмиядә рәхәтләнеп йоклыйлар иде.

- Шуңа күрә алар бераз тәпи йөреп, сөйләшә башлауга, сәхнәгә тартылдылар һәм бүгенге көндә дә сәхнәсез бер көн дә яши алмыйлар, - дип көлешәләр Хәлимуллиналар.

Эльвина Хәлимуллина Самар тамашачыларына - талантлы саксофончы, ә аның ике туганы - Салават Хәлимуллин җырчы буларак танышлар. Алар дуэт булып та бик матур һәм дәртле җырлар башкаралар. «Өлкәннәр» белән беррәттән, милли мәдәниятебезне саклауга күп көч куялар һәм аңа яңа, заманча агым кертәләр.



Эльвина Хәлимуллина да, энисе кебек, музыкаль белем алган, хәзерге вакытта Шаталов исемендәге музыка училищесында укый, киләсе елда тәмамлаячак. Сеңелесе - 12 яшьлек Алсу да саксофонда уйный, энисе белән апасы юлын сайлаган.

Салават балачактан җырлап-биеп үссә дә, музыкаль белем алырга омтылмаган. «Яктылык» мәктәбен тәмамлагач, армиядә хезмәт итәргә һәм югары белем алырга планлаштыра егет. Әмма соңгы бер ел эчендә аның планнары кискен үзгәрә, һәм ул үзен тулысынча иҗатка багышларга карар кыла. Хәрби хезмәт иткәндә вакытын бушка уздырмый, вокал осталыгы өстендә эшли, аранжировка серләренә өйрәнә башлый һәм үзе язган җырларны сәхнәгә чыгарлык итеп шомарта. Быел Салават Эльвина укыган Шаталов исемендәге училищега музыка режиссеры бүлегенә укырга керергә җыена. Әлеге һөнәр серләренә үзлегеннән генә өйрәнеп тә зур уңышларга ирешкән егет, һөнәри белем алып чыккач, иҗат җимешләре белән тамашачыларны тагын да сөендерер, дип өметләнәм. Аның энесе Илназ да бик матур җырлый. Малайның тавышы Минәхтәм бабасының тавышына охшаган, диләр.

- Салават белән Эльвина ике туганнар кебек түгел, ә бертуганнардай тату. Бөтен буш вакытларын бергә уздыралар, яңа җырлар өйрәнәләр, вокал өстендә эшлиләр, репертуарны кызыклырак итү турында уйлыйлар. Гомумән, аерылгысызлар, - дип сөйли аналары.

«Ни чәчсәң – шуны урырсың», дип дөрес әйткәннәр икән. Хәлимуллиннар гаиләсе - бу әйтемне раслаучы факт. Гомерләренең күп өлешен иҗатка, милли мәдәниятебезне саклап, аны яшь буынга тапшыруга багышлаган Лилия һәм Миләүшә Хәлимуллиналар - зур хөрмәткә лаеклы, күпләребезгә үрнәк булырлык аналар. Аларның тормыш иптәшләре Ринат






белән Маратка да, хатыннарының шөгыльләрен хуплап, аларга терәк һәм ярдәмче булулары, сабырлыклары өчен бик зур рәхмәт.

Ансамбльнең җитәкчесе — “Гали гармуннары”, “Җирнең бәллүр йөрәге” фестивальләре лауреаты Мидхәт Әминов та Хәлимулиннар гаиләсенә рәхмәтле.

- 30 елга якын гомер эчендә төрле хәлләр булды. Лилия белән Миләүшәгә мин үземә ышангандай ышанам. Олырак булсам да, мин алардан күп нәрсәгә өйрәндем. Сәхнәдә дә без бер-беребезне күз карашыннан аңлыйбыз. Ансамбльнең коллективы бер гаиләдәй тату, Аллаһыга шөкер. Алар белән утка да, суга да керергә әзер мин, - дип тәмамлады сүзен җитәкче.



# ГОМЕР ТАУЛАРЫ БИЕК



***Иске Усман авылына баргач, каләмдәшем Мәгърифә Мисбах кызы Гыйльфанова белән очрашып-сөйләшеп торырга туры килде. Әйтергә кирәк, бу Бөек Җиңүнең 78 еллыгын билгеләп үтәргә әзерләнгән вакытлар иде.***

*Нурсинә Хәкимова*

Мәгърифә апаның әтисе - Мисбах аганың сугышта булганын белә идем инде. Без шул турыда сөйләшеп киттек.

Мәгърифә ханым үзенең якты истәлекләре белән уртаклашты.

– Әтием белән мин бик горурланам, чөнки ул ачык күңелле кеше иде. Безгә сугыш еллары турында сөйли иде.

Бөек Ватан сугышы башланганда, аңа нибары унсигез яшь кенә булган.

Ул шушы вакытта башкалабыз Мәскәүдә электромеханика заводында эшли торган булган.

Сугыш башлануга, аны фронтка алганнар. Ул төньяк-көнбатыш фронтына эләгә. Бик каты барган сугышларда яралана һәм госпитальдә дәвалана.

Аннан соң аны дала фронтында бүлек командиры итеп билгеләделәр.

Курку белмәс егет кабат яралангач, аңа Алтай краендагы Бийск шәһәрендә дәваланырга туры килә.

Сугыш кызганнан-кыза бара. Әтиемнең чын солдат икәнлеген күреп алучылар аны Лепель шәһәрендәге хәрби училищега лейтенант белемен үзләштерергә озаталар. Укып, белем туплагач, Германиядә бик каты барган фронттагы артиллерия бригадасына ут взводы командиры итеп билгелиләр. Соңрак офицер дәрәҗәсенә тикле күтәрелгән әткәйне Маршал Жуковның адъютанты итеп куялар.

Биредә сугыш берөзлексез ике ел дәвам итә. Үзенең сөйләвенә караганда, әткәй бик тугры солдат булган, үз-үзен аяп тормыйча, фашист илбасарларын дөмектерү өчен, ул зур көч куйган. Ә 9 майда Бөек Җиңү салютында катнашкан.

Сугыш тәмамлангач, әтиебез бары тик 1946 елда гына туган авылына әйләнеп кайткан.

Аның күкрәген “За отвагу”, “За боевые заслуги”, “За оборону Москвы”, “За оборону Сталинграда”, “За Победу над Германией” орден-медальләре бизәгән була. Аннан соң инде бәйрәмнәр саен юбилей медальләрен кабул итә иде ул, - дип сөйләде Мәгърифә апа.

Хәзер мин Мисбах Гыйләҗи улы Гыйләҗев тормыш юлының сугышсыз чорын дәвам итәргә телим.

Язмам герое хезмәт юлын колхоз рәисенең урынбасары буларак башлап җибәрә. Биредә озак еллар эшләгәч, намуслы, эшчән ир-егетне авыл советы рәисе итеп билгеләделәр. Бераз алгарак китеп әйтәм, Мисбах абый заготконтора агенты һәм клуб мөдире булып эшләп, шуннан лаеклы ялга чыга.

Шушы кешенең якты истәлекләрен барлап, шуны әйтәсе килә: ул үз гомеренә кешеләргә ярдәмчел, аңлы, зиһенле кеше була. Өстәвенә, аның сәнгатькә, җыр-моңга гашыйк икәнлеге дә билгеле. Мисбах ага хөр күңелле, җор телле кеше булган. Төрле мәзәкләр сөйләп, авылдашларын көлдергән, күңелләрен күтәргән. Шулай ук ул, авылдашлары үтенече буенча, аларның фронтта хәбәрсез югалган якыннарын эзләп табуда һәм башка күптөрле эшләрдә булышкан.

Ә шәхси тормышына килгәндә, яшь Мисбах авылдашы Газыймәгә яратып өйләнә. Ипле, тормышның әчесен-төчесен җитәрлек татыган, басынкы-сабыр холыклы егетне Газыймә дә яратып кабул итә. Бераз вакыттан соң ул хәләл иренә кызлары Әбризәне бүләк итә. Җиде елдан соң Мәгърифә, Фәрит, Рәшит дөньяга аваз салалар. Йомшак күңелле әтиләре бер-бер артлы дөняга килгән сабыйларын күкрәгенә кысып: “Дәвамчыларым минем,” - дип сөя торган була. Чөнки фронт юлларын үткәндә күп сабыйларның вакытсыз вафат булганнарын күрергә туры килә аңа.

Гомерләр әкрен генә үтеп тора. Мәгърифәнең дә, башка туганнары белән берләттән, балачак еллары шаулап уза. Ул кече яшьтән авылдагы Мостай елгасы буенда каз бәбкәләре саклый. Көн кызуланып китсә, каз бибиләренә ияреп, елгада су коена, дус кызлары белән җиләк-җимешкә йөри. Бераз үсә төшкәч, әниләре Газыймә кызларын хатын-кызга тормышта кирәкле кул эшләренә, ризык әзерләү серләренә өйрәтә.

Авылдагы мәктәпне тәмамлагач, Мәгърифә Похвистнево районында хисапчы һөнәрен үзләштерә. Беркөнне яшь, чибәр кыз Богырысландагы туганнарына кунакка юл тота. Урам буйлап барганда гомерлек язмышын - биредә нефтьче булып эшләүче авылдашы Рөстәмне очрата. Егет, кыз белән исәнләшкәч, аның кайдан, биредә ни эшләп йөрүе турында сорый. Ә үзе шомырттай кара, озын чәчле, кызыл чиядәй иренле кыздан күзен ала алмый.

- Сеңелем, ничек итеп мин сине беркайчан да авылда күрмәдем икән соң? – дип әйтеп куя ул.

Аннан соң:

- Бигрәк чибәр икәнсең, - дип тә өсти.

Ә авылга кайткач, төнлә клубтан өенә кайтырга чыккан яшь кызны, йөргән егеттәннән аерып алып, үзе озата кайта.

- Ул вакытта транзистор модада иде бит. Аны теләсә кем сатып ала алмый иде. Рөстәм нефть өлкәсендә хезмәт иткәч, теләгенә ирешкән иде. Менә шушы транзистордан яңгыраган матур көйләрне тыңлап, ай яктысында серләшеп утыра торгач, Рөстәмгә гашыйк булганымны сизми дә калганмын. Бераз очрашып йөри торгач, без өйләнештек. Бер-бер артлы улларыбыз Рәмис һәм Шамил дөньяга килделәр, - дип сөйләде әңгәмәдәшем.

Бераз алга китеп әйтәм: кызганычка, Рөстәм абый белән Рәмис якты дөньяда юк инде. Мәгърифә ханымның хәтер төпкелендә бары тик алар турындагы матур истәлекләр генә саклана.

Ул гомере буе авылда хисапчы булып эшләп, лаеклы ялга киткән. Бүгенге көндә изге күңелле ак әби гыйбадәт кыла, табыннарда Коръән укып йөри.

Аның улы Шамил гаиләсе белән Татарстанда гомер итә. Тормыш иптәше Зөлфия һәм улы Рамазан, кызы Сәнифә белән бергәләп туган нигезгә кайтып, әниләренең бөтен эшләрендә булышып китәләр. Аны үзләренә кунакка алып баралар.

Мәгърифә апаның “Бердәмлек” газетасының штаттан тыш хәбәрчесе булып эшләвенә егерме биш ел тулып үткән. Аңа кадәр аның колхозда эшләгән уңган-булган, хезмәт сөюче кешеләр турындагы язмалары “Камышлы хәбәрләре” газетасында басылып торган. Ул, киләчәк буынны таныштырып өчен, үзләренең нәсел шәҗәрәсен төзегән.



Менә инде Мәгърифә апаның тормыш юлы турында язып чыктым.

Мисбах ага белән Газыймә апаның кызлары Әбризә апага килгәндә, ул тормыш иптәше Фуат абый белән яшьли Үзбәкстандагы Ташкент шәһәренә барып төпләнгән. Биредә күп еллар яшәгәч, яңадан туган авыллары - Иске Усманга кайтканнар. Бүгенге көндә Фуат абый вафат, Әбризә апа улы Илһам белән яши. Аларның кызлары Гөлшат Балтаева Мәскәү шәһәрендәге Останкино телевидениесендә мәдәният тапшыруын җитәкли, ә Рәйхан Ливатная биредә продюсер булып эшли.

Язмам героеның улы Фәрит Гөлсинә ханым белән уллары Илнар, Илнурга гомер бүләк иткәннәр. Кызганычка, Фәрит, ошбу дөньяны калдырып, мәңгелеккә күчкән. Бүгенге көндә аның тормыш иптәше Гөлсинә ханым улы Илнур белән авылда бик зур кибет ачып җибәргәннәр. Ә Илнар үзенең крестьян-фермер хуҗалыгын булдырган.

Тормыш югалтуларга бай бит ул. Мисбах ага Гыйләҗевның улы Рәшит тә якты дөньяда юк инде. Аның тормыш иптәше - Фәния ханым Гыйләҗева күп еллардан бирле Самардагы “Яктылык” мәктәбендә балаларга татар теленнән белем бирә.

Мин бу язмамны “Гомер таулары биек” дип атарга булдым әле. Чөнки минем аңлавымча, адәм баласы, җир йөзенә килгәч, гел яктылыкка, алга омтыла бит. Ә алда гомер тавы көтеп тора. Кешеләр яши-яши шушы тауның башына менәргә омтылалар. Барысына да өлгерергә тырышып, ары чабалар, бире чабалар. Ләкин көннәрдән беркөнне барысы да туктап калырга мөмкин. Әйтергә кирәк, Мисбах абыйның да гомере билгеләнгән вакытта туктап кала. Ни кызганыч! Аңа нибары алтмыш яшь кенә була. Чөнки ул фронт юлларын үткәндә, аның үпкәсенә дошманның снаряд кыйпылчыгы кереп калган. Кырык бер ел ул шушы кыйпылчык белән яшәгән! Аның, чын ир кеше буларак, сабырлыгына, түземлегенә сокланмый мөмкин түгел! Ләкин шушы хөрмәтле кешенең тормыш юлына күз салсаң, ул барына да өлгергән булып чыга. Шатлыкка, Мисбах ага белән Газыймә апа тудырып үстергән дүрт баладан унбер онык һәм унтугыз оныкчык дөньяга килгәннәр. Бүгенге көндә алар барысы да шушы матур, хөрмәткә лаеклы кешеләрнең нәсел дәвамчылары булып яшиләр. Ә сугыш юлларын үткәндә зур югалтулар кичергән, бернинди авырлыклар алдында югалып калмаган, кешелекле Мисбах бабайлары белән Газыймә әбиләре, моңлы бер җыр булып, мәңге алар күңелендә яшәр.



# ПУТЕШЕСТВИЕ ЭТНОНИМОВ

*В предыдущем номере рассказывалось о старинных племенах теле и о некоторых их потомках. В данной статье освещаются культурные особенности других потомков этих племен.*

*Михаил Кржижевский*

Ушла зима, унеся с собой снег и лед, холод и длинные ночи. Теперь повсюду можно видеть сочную зелень листвы и травы, яркие разноцветные цветы. Одними из первых насекомых появляются весной бабочки. Сначала их немного, совершающих робкие полеты над первой зеленью, затем всё больше и больше. Бабочки наших лесов и лугов бывают разного цвета – пестрые крапивницы, золотистые лимонницы, нежно зеленые пяденицы. Можно, если повезет, увидеть и махаона – бабочку с большими желтыми крыльями с темным окаймлением, красными пятнами и хвостиками сзади крыльев. Часто ее называют одной из наиболее красивых наших бабочек. Одни бабочки летают днем, другие проявляют активность в темное время суток. Их образ запечатлен во многих литературных произведениях. Вспомним, например, стихотворение Г. Тукая «Бала белян кубаляк» («Ребенок и бабочка»), где бабочка признается, что жить ей на свете суждено лишь один день. Действительно, некоторые бабочки живут лишь примерно такой короткий отрезок времени.



В традиционной родоплеменной структуре башкир присутствует род кубаляк. В этнокультурном плане он наиболее близок к роду теляу – оба они входят в состав объединения табын. В XVIII веке существовала Кубаляк-Табынская волость, которая располагалась по соседству с Телевской, по Яику и Мендяку. Впоследствии они образовали единую волость. Кубаляк – слово, которое не только означало бабочку, но и являлось мужским именем у тюркских народов.



Имя это присутствует и в исторических свидетельствах, и в фольклоре. Старинное башкирское предание повествует о том, что Кубаляк и Теляу были братьями. После смерти родителей они покинули родной Алтай и переселились на отроги Уральских гор. Здесь они женились, обзавелись потомством, стали разводить скот. Со временем потомки братьев основали целый ряд поселений. Жители одних сел считаются потомками Кубаляка, жители других – Теляу. Так в легенде отразились народные представления о родстве двух объединений и о приходе предков башкир с Алтая.



многом напоминающих традиционные верования других народов Алтая. Каменные кучи посвящаются духам-покровителям отдельных мест, во главе которых стоит Алтай кудай – владыка Алтая.

Музыке отводится весомая роль в традиционной культуре. Она сопровождает человека на протяжении всей его жизни. Колыбельные песни поют не только женщины, но также и мужчины. Основным музыкальным инструментом является топшур – струнный инструмент, напоминающий балалайку.

Указанному этносу посвящены различные научно-популярные



Исследователи, как отмечалось в предыдущем номере, возводят этноним теляу к древним племенам теле (динлинам). В Сибири это название, кроме телеутов, сохранили также теленгиты. Этот этнос в основном живет на Алтае. Указанный край, где есть горы и озера, а лес соседствует со степью, сегодня является регионом, где получили развитие разные виды туризма – в частности, функционируют конные маршруты, описанные в современной литературе.

Основу традиционного хозяйства теленгитов составило скотоводство – разводили лошадей (не зря конный туризм сегодня так развит в этих местах!), крупный и мелкий рогатый скот, а также верблюдов, яков, оленей. Активно за-



нимались охотой на разных зверей и птиц. Основной земледельческой культурой служил ячмень. Получили развитие такие ремесла, как вязание, выделка шкур, резьба по дереву. Как и соседние народы, теленгиты использовали в качестве жилища войлочную юрту или крытое корой сооружение, напоминающее чум. Как и у других народов, юрта делилась на мужскую и женскую половины. Позднее получили распространение деревянные срубовые избы, но по форме своей они зачастую напоминали традиционные юрты. Хозяйственный уклад обусловил и мясо-молочную основу традиционной кулинарии. К блюдам национальной кухни относятся борсоки – жареные колобки из теста, лепешки, жареное и вареное мясо, мясной суп, колбасы, из напитков – чай со сливками и ячменной мукой и кислое молоко.

Основу традиционной одежды составили длинная просторная рубаха, имеющая открытый ворот, штаны с широким шагом, шубы. Замужние женщины носили длинный распашной кафтан, украшенный мехом либо орнаментом. Женскую одежду дополняли украшения. В качестве головного убора использовались шляпы с узкими полями, шапки из пушных зверей.

Верующие в основном являются православными. В духовной культуре присутствует ряд элементов древних языческих верований, во

фильмы, а также мультфильм «Теленгиты. Небесная стража Алтая».

Известный исследователь народов Алтая Л.П. Потапов писал, что не следует отождествлять теленгитов и телесов. И, конечно, их совсем не следует путать с телугу – народом Южной Индии или тлинкитами – индейцами Северной Америки.

А в Сибири есть и другие народы, чья этнокультурная история имеет интересные параллели с народами Урало-Поволжья. Об этом будет рассказано в следующих выпусках журнала.

# НӘҖИБ СӘЙФЕТДИНОВ: “ЯЛКЫНЛЫ ЯШЬЛЕК” АНСАМБЛЕ – МИЛЛИ МӘДӘНИЯТЕБЕЗ ҖӘҮҺӘРЕ”

***Аллаһыга шөкер, Самар татарлары арасында милләтебез язмышы өчен янып-көеп йөрүче, ана телебезне, мәдәниятебезне, гореф-гадәтләребезне, динебезне саклап калуга һәм үстерүгә зур өлеш кертүче шәхесләр аз түгел.***

***Миләүшә Газимова.***

Самар Җәмигъ мәчетендәге “Диннәр тарихы” дип аталган музейның җитәкчесе – Якуб улы Нәҗиб Сәйфетдинов та - шундый күркәм кешеләрнең берсе. Ул шәһәребездәге татар-мөселман тормышында актив катнашып килә, милли, дини, тарихи-мәдәни җәүһәрләребезне, татар халкының гореф-гадәтләрен, йолаларын, бәйрәмнәрен тергезү, саклау һәм киләсе буыннарга тапшыру юнәлешендә, көчен, вакытын, малын кызганмыйча, зур эшләр башкара.



Күптән түгел Нәҗиб әфәнде тагын бер игелекле, мактауга лаеклы хезмәткә керешкән бит әле. Үз вакытында ул Самарның атаклы “Ялкынлы яшьлек” җыр, бию һәм шигърият ансамбле концертларын видеокамерага төшереп барган. Ә хәзер шушы видеокассеталарны цифрлы форматка күчерү белән шөгыльләнә.

- Мин, 1992 елдан алып, яраткан ансамблебезнең концертларын видеога төшереп килдем. Ул вакытта видеокамераларның хакы “Жигули” машинасы бәясенә тиң иде. Ә 1992 елга кадәр алар бөтенләй дә юк иде. Бүгенге көндә миндә “Ялкынлы яшьлек” концертлары төшерелгән йөздән артык видеокассета бар. Танылган ансамблебез тарих битләрендә уелып калсын, ә иң мөһиме – хәзерге һәм киләчәк буын вәкилләре “Ялкынлы яшьлек” турында белсен, аның белән горурлансын, искиткеч сәләткә ия булган үзешчән артистларыбызга соклансын, дип, әлеге видеокассеталарны цифр форматына күчерү эшенә тотынырга булдым. Бигрәк тә бүгенге яшьләребез арасында “Ялкынлы яшьлек”нең җырчылары, музыка коралларында уйнаучылары турында кызыксынучылар булуы мине бу эшкә илһамландырып җибәрде.

Әлеге хезмәтне бик кирәкле, дип саныйм, чөнки хәзер цифрлы технологияләр заманы бит. Бигрәк тә мондый форматтагы информациягә зыян килми, язмалар магнитсызланмый һәм, күпме генә копия ясасаң да, аларның сыйфаты югалмый.

Самар өлкәсенең “Туган тел” татар җәмгыяте президенты Ильяс Шәкүровка һәм журналист, тарихчы Шамил Галимовка Аллаһы Тәгаләнең рәхмәтләре яусын. Иң беренчеләрдән булып, әлеге идея буенча шушы кешеләр белән киңәштем. Алар шунда ук башлангычымны хупладылар һәм матди ярдәм дә күрсәттеләр. Шул акчаларга, оцифровкалау эшен башкарыр өчен, махсус җайланма сатып алдым. Яхшы компьютер һәм бу процесс өчен кирәкле калган нәрсәләр үземдә бар иде инде.

“Ялкынлы яшьлек” концертларының цифр форматына күчерелгән видеоязмаларын урнаштырып

барыр өчен, Телеграм челтәрендә “Чишмә башында” (“У истоков”) дип аталган махсус канал булдырдык. Бу исемне Шамил әфәнде Галимов белән бергәләп уйлап таптык.

Шатлыкка, төркемдә кешеләр







саны артканнан-арта бара. Кызыксыналар, сораулар бирәләр, фикерләрен язалар, рәхмәтләрен белдерәләр, берничә кеше матди ярдәм дә күрсәтте.

Әйе, башкача мөмкин дә түгелдер. “Ялкынлы яшьлек” – милли мәдәниятебез җәүһәре бит. Ул Самарда татар мәдәнияте үсешенә зур өлеш кертте. Шамил Сатдаров, Мидхәт Галимуллин, Илгиз Колючев, Камил Шамкаев, Әхмәт Нәфыйгин оештырган ансамбльгә хәзер 53 яшь.

1970 елда булдырылган “Ялкынлы яшьлек” 1977 елда “халык” исемен ала. 1985 елда Бөтенсоюз җыр, бию һәм шигърият конкурсында лауреат була. Ансамбль, сәләтле милләттәшләребезне бергә туплап, тамашачыларны моңлы җырлары, дәртле биюләре, ялкынлы шигырьләре белән куандырып яшәде һәм яши.

Күпме кешеләр шушында үз тиңнәрен тапканнар, матур-матур гаиләләр корып, балалар үстергәннәр. Хәзер инде аларның уллары һәм кызлары да “Ялкынлы яшьлек”тә үз талантларын күрсәтәләр.

Мин концертларны гына түгел, тәнәфес вакытында фойега чыккан халыкны да төшереп йөри идем. Ул чакларда аеруча күңелле иде бит! Кешеләр гармун көйләренә бииләр, күңел ачалар, бер-берсе белән аралашалар.

Рус шәһәрендә яшәп, туган телебезгә, җыр-моңнарыбызга, гомумән, татар сәнгатенә сусаган халык “Ялкынлы яшьлек” ансамбленең оешуын шулкадәр шатланып кабул итте! 70 - 80нче елларда концертларга халык ишелеп йөрде. Ул халыкчанлыгы белән алдыргандыр, дип уйлыйм. Һәркем концертка үзенең авылдашын, күршесен, туганын күрергә килә иде.

Күпләрдән, Исламда музыка тыелган, дигән сүзләрне ишетергә туры килә. Әмма минем шуны әйтәсем килә - “Ялкынлы яшьлек”тә катнашкан, ансамбльнең концертларына йөргән кешеләрнең күбесе мәчет бусагасын атлап керделәр. Баштан, ана телендә яңгыраган җырларны тыңлап, милли сәнгатебез белән кызыксынып, алар дингә дә килделәр. Шәһәребездә татар мәдәниятен үстерүгә зур өлеш кертkән шәхесләр, әйтик, Шамил Баһаутдин, Шамил Галимов, Радик Газизов һәм башкалар намаз укыйлар, гомумән, Ислам дине таләпләрен үтәп яшиләр. Илгиз абый Колючев белән без бергә мәдрәсәдә белем алдык.

Шуны да билгеләп үтәсем килә - Шамил Баһаутдин һәм Шамил Галимов мин җитәкләгән музейга бәһасез экспонатлар бүләк иттеләр, - дип сөйли әңгәмәдәшем.

***- Әлеге эш җиңел түгелдер инде, Нәҗиб абый,*** - дип сүзгә кушылдым.









- Өч сәгатьлек бер видеокассетаны оцифровкалау өчен 10 сәгатькә якын вакыт китә. Сыйфатларын яхшыртыр өчен, язмаларны дүрт программа аша уткәрәм. Эш башланды гына. Алда әйткәнемчә, миндә йөздән артык видеокассета бар. Шуңа күрә әле эшләргә дә эшләргә.

Телеграмдагы төркемгә өч сәгатьлек видеоларны биреп булмый, чөнки кешеләр андый озын язмаларны карап утырмаячаклар. Шуңа күрә мин аларны, 30шар минутлык итеп ясап, бүлеп-бүлеп урнаштырам.

Күп кенә видеоязмаларымны үз вакытында Илгиз абый Колючевка бирдем. Менә шуларны табасы иде дә бит.




Сүз уңаеннан, милләттәшләребезгә утенеч белән мөрәҗәгать итәсем килә. Әгәр дә кемдәдер “Ялкынлы яшьлек” концертларының видеога төшерелгән язмалары бар икән, миңа китерсәгезче, аларны, цифрлы форматка күчереп, каналыбызга урнаштырыр идем, - дип уртаклашты Нәҗиб әфәнде.

Мин дә Телеграм челтәрендәге “У истоков” төркемен карап барам. Милләттәшебез, чыннан да, игелекле эш башлаган. “Ялкынлы яшьлек”нең йөрәге тибә анда! Инде күптән якын кешеләребезгә әйләнгән артистларыбызның яп-яшь чакларын карарга шундый кызык. Сокландыргыч талант иянләре! Чыннан да, ялкынлы яшьлек, ямьле яшьлек, онытылмаслык яшьлек...

Нәҗиб абый башкарган хезмәт турында халык ни уйлый икән, дип, бернична кешедән фикерләрен сорадым. Аларны укучыларыбыз игътибарына да тәкъдим итәм.

Самар өлкәсенең “Туган тел” татар җәмгыяте активисты, кыз чагында “Ялкынлы яшьлек” концертларын алып барган **Наилә Сабирҗанова:**

“Телеграмда “Чишмә башында” исемле төркем пәйда булды. Бу – Самар халкы өчен искитмәле куанычлы хәбәр. Тарихыбызны торгызган, безне яшьлеккә “алып кайткан” өчен Нәҗиб абыйга Аллаһының рәхмәтләре яусын. Уникаль видеоязмаларны караганда, күзләргә яшьләр килә. Бу канал, һичшиксез, милләтебезне берләштерәчәк!”

“Ялкынлы яшьлек” ансамбле җырчысы **Айсылу Әбдиева:**

“Нәҗиб, ул чактагы катлаулы, әмма кызыклы һәм бик күңелле мизгелләрне саклап килүең өчен мең рәхмәт!”

Самар өлкәсенең “Туган тел” татар җәмгыяте директоры **Гүзәл Рамазанова:**

“Нәҗиб абый, сез барыбызга да бик кирәк булган эш башкарасыз. Үз вакытында яраткан ансамблебезнең концертларын видеога төшереп барганыгыз һәм хәзер аларны цифр форматына күчерүегез өчен зур рәхмәт сезгә.

Бөтен видеоязмалар да бик кызыклы. Кызганыч ки, күп артистлар хәзер якты дөньяда юк инде... Шул сәләтле кешеләрне исебездән чыгармасак иде”.

**Вәсимә Фәрдиева:**

“Искиткеч видеоязмалар ич бу! Шуларны безгә, яшьләргә, җиткергәнегез өчен Аллаһының рәхмәте яусын. Бу – безнең өчен истәлек, үрнәк. Шундый талантлы шәхесләребез булганга горурлык хисләре туа!”




**Раил Ходов:**

“Хәерле хезмәтегездә Аллаһы Тәгалә Үз ярдәмен бирсен. Бик кирәкле эш башлагансыз. Ахырына җиткерергә насыйп булсын!”

Өлкә “Туган тел” татар җәмгыяте активисты **Флорида Локманова:**

“Нәҗиб әфәндегә, шундый бәһасез видеокассеталарны саклап калганы өчен, афәрин, дип әйтәсе килә! Күпме кеше шушы язмаларда үзен күреп шатланачак, элеккеге елларны исенә төшерәчәк. Аларның балаларына, оныкларына да бу нинди яхшы истәлек бит”.

“Ялкынлы яшьлек” ансамбле җырчысы **Илнур Алтынбаев:**

“Хәзер кешеләр, бигрәк тә яшьләр, күп вакытларын интернетта үткәрәләр. Шуңа күрә Телеграмда шушындый төркем оештырылуы бик әйбәт. Егетләр, кызлар, ансамблебезнең эшчәнлеген күреп, гыйбрәт алып, милли сәнгатебезне сакларга, үстерергә омтылсалар, бигрәк тә яхшы булыр иде.

Нәҗиб әфәндегә Раббыбыз ярдәмен бирсен. Аңа булышучылар табылса, бу эш тагын да алгарак китәр иде, дип уйлыйм”.

Хөрмәтле укучыларыбыз, әгәр дә берәрегездә “Ялкынлы яшьлек” концертлары язылган видеокассеталар булса, Самар Җәмигъ мәчете музеена килеп, Нәҗиб Сәйфетдиновка мөрәҗәгать итә аласыз.

# «ПАРК ДРУЖБЫ НАРОДОВ» ПРИНИМАЕТ ГОСТЕЙ ИЗ СГЭУ

***В настоящее время большой популярностью пользуются туристские маршруты с этнокультурным компонентом, а также рестораны с традиционной кухней разных народов, гостиницы, построенные по типу традиционных жилищ. Поэтому студенты Самарского государственного экономического университета (СГЭУ), обучающиеся по специальностям «туризм» и «сервис», знакомятся с особенностями культуры народов нашего края не только во время аудиторных лекций, но и на выездных мероприятиях. Так, студенты 3-го курса данных специальностей этой весной посетили Дом дружбы народов, а недавно побывали в этнокультурном комплексе «Парк дружбы народов».***

***Михаил Кржижевский***

Места эти чем-то напомнили студентам родной университет – на его территории расположен пруд, в котором в теплое время плавают утки, а над водой летают стрекозы. Этнокультурный комплекс расположен в экологически чистом микрорайоне Волгарь, в окружении озер, где живут чайки и другие птицы – во время экскурсии даже удалось увидеть пролетающую цаплю.

Конечно, главной целью мероприятия явилось знакомство с подворьями, представляющими разные народы нашей многонациональной области. Каждое подворье — русское, мордовское, осетинское, казахское, татарское и другие – по-своему уникально. Одни представляют собой деревянные избы, другие – каменные дома, третьи – юрты. Вместе с тем в интерьере, в традиционных предметах быта присутствует немало общего.

Экскурсии проводили сотрудницы комплекса Вера Алексеева и Омуркан Пусурова. Они рассказали много интересного о традициях народов нашего края. Студенты получили возможность не только увидеть разные подворья снаружи, но и побывать внутри, проникнуться атмосферой этнической культуры. Каждое строение вызвало большой интерес.

Посетили студенты и татарское подворье. С интересом рассматривали они узоры на полотенцах, широкие деревянные нары, орудия труда, а также различные номера журнала «Самарские татары». Прозвучал рассказ о Волжской Булгарии, о современных татарских селах в нашей области, о Сабантуе и других традиционных праздниках.





Но вот знакомство с этнокультурным комплексом завершилось. Студенты отправились делиться впечатлениями с друзьями и родственниками, а в «Парк дружбы народов» прибыли новые посетители. Ведь этнокультурный комплекс «Парк дружбы народов» уже пользуется большой популярностью как у жителей, так и у гостей Самары. Его посещают и дети – как вместе с родителями, так и в составе школьных и иных групп. Кроме национальных подворий, комплекс включает и парк, предназначенный для семейного отдыха, что должно способствовать дальнейшему развитию детского туризма.

*Гөлназ Таипова әзерләде*

# ҖӘЙГЕ МИЗГЕЛЛӘР



Галимҗан Латыйп

## МИНЕМ ӘТИ - БАКЧАЧЫ

Минем әти - бакчачы,
Җиләк-җимеш үстерә.
Көньяк үсемлекләрен
Ул бу якка күчерә.

Мин дә әти янында
Еш буламын бакчада:
Кырау төшмәсен, диеп,
Чәчәкле агачларга.

Кичен төтен салабыз
Куакларның төбенә.
Ап-пак кардай чәчәкләр
Ак төтенгә күмелә.

– Тырыш бул син, – ди әти,
Бакча сөя тырышны.
Шунсыз һич тә бакчадан
Алып булмый уңышны.

Шәүкәт Ногманов

## ГӨЛБАКЧА

Гөлбакча ясадык,
Өй янын киртәләп;
Чәчәкләр үстерәм,
Су сибеп, иркәләп.

Үстеләр чәчәкләр,
Их, матур үзләре:
Резеда, георгин,
Күгәрчен күзләре...

Үткән бер кешене
Бакчага каратам;
Чәчәкләр үстерәм,
Чәчәкләр яратам.

Дусларым, килегез,
Килегез, күрегез,
Чәчәккә бизәлде
Безнең өй түребез.



Касыйм Тәхау

## ҮСЕГЕЗ, ҖИЛӘКЛӘРЕМ

Сыгылмалы көянтәм,
Чәчәкле чиләкләрем.
Йөгерә-йөгерә су ташыйм:
«Үсегез, җиләкләрем!»

– Алсу кояш нурында
Сез кызарып пешәрсез...
Әби белән икәү без
Җиләкләп чәй эчәрбез.



Мәрзия Фәйзуллина

## БАЛ КОРТЫ

Апам безнең бакчабызда
Матур бер гөл үстерде,
Ул гөл ап-ак чәчәк атты,
Бик матур төскә керде.

Апам лагерьга киткәч, мин
Шуны өзәргә булдым.
«Алам!» – диеп, гөлгә таба
Тиз генә кулым суздым.

Шулчак бал корты, безелдәп:
«Чәчәкне ө...з...ззз...мә! – диде. –
Сезгә тәмле бал җыярга
Кирәк ул безззззгә», – диде.



Хәкимҗан Халиков

## Җәйге буран

Җәйге кояш авыз ерып
Көлеп торганда –
Нинди буран икән соң бу
Безнең урамда?
Нишлим инде – кар күмә бит
Бакча гөлемне?
Әллә өстенә одеял
Каплап керимме?
Тышка чыксам – тал песие
Кышкы кабыгын
Салып аткан да очыра
Ап-ак мамыгын.



Шәүкәт Галиев

## Июльдә

Кара карга карый кырга:
Тагын тоташ ак кар яткан!
Бал корты әйтә:
– Ялгышасың,
Карабодай чәчәк аткан!



Абдулла Алиш

## Кемгә кирәк, кемгә кирәкми

Әтисе белән бергәләп Таҗи балык тотарга барды.

Көн әле бик иртә. Кояш та юк, ә шулай да якты. Су өсте тып-тын. Өф иткән җил дә юк.

Билгеле, мондый вакытта балыклар яхшы чиртәләр, кармакны бер дә тик тотмыйлар. Калкавычны томрып, су төбенә алып төшеп китәләр. Таҗиның әтисе балыкларны тарта да чыгара, сөйри дә чыгара, ялтырап торган ап-ак чабакларны, көмеш тәңкәле кызылканатларны, әрсез алабугаларны. Таҗи аларның барысын да чиләккә җыя бара. Менә инде аларның балык сала торган чиләкләре дә тулып килә. Балык бик шәп эләгә. Шуңа күрә вакытның үтүе дә тоелмый. Әнә инде кояш та күптән күтәрелеп килә. Таҗи аны сизмәде дә. Төшлеккә җитә башлагач, кояш бик нык кыздырырга тотынды, монысын Таҗи да тойды. Әтисе дә. Әтисе, кесәсендәге кулъяулыгын алып, маңгаендагы тирләрен сөртте. Ә Таҗи:

– Фу... Нәрсәгә кирәк булды инде бу кояш?! – дип, зәңгәр күктән елмаючыны тиргәргә тотынды.

– Кемгә кирәк, кемгә кирәкми, - диде әтисе, шуннан тагын ялгады, - кояш бер дә булмаса, һаман төн генә булыр иде, ә төнлә балыклар эләкми. Кояш булмаса, җир өстендә үсемлекләр үсмәс, син дә, мин дә булмас идек, – диде.

Кояш кыздыргач, балык та эләкми башлады. Таҗи кояшны ачуланып торганда, кинәт җил күтәрелде. Көзгедәй тигез елга өсте шадраланды. Дулкын кузгалды, калкавычлар бер күтәрелделәр, бер төштеләр. Дулкын кузгалды, балык чиртүе дә беленми башлады. Таҗи:

– Фу, нигә кирәк булды инде бу җил?! – диде.

– Кемгә кирәк, кемгә кирәкми! – диде әтисе.

Елга өстендә җилкәнен киергән көймә йөзде. Тау башындагы тегермәннәр, берсеннән-берсе узышып, әйләнә башладылар.

Әтисе Таҗига:

– Әнә күрәсеңме, җилкән белән җилне ничек җиккәннәр. Җил көймәне этеп бара. Җил әнә тегермәннәрне дә әйләндерә. Ул тегермәндә орлыклар онга әйләнәләр. Ә ул оннан әниең күмәч пешерә, – диде.

Шул арада җил күк читеннән болытларны куып китерде дә, кара-кучкыллы болытлардан яңгыр төшкәли башлады.

– Фу, яңгыр нигә кирәк булды инде, елгада болай да су күп ич! - диде Таҗи.

– Кемгә кирәк, кемгә кирәкми! – диде әтисе. - Ашлык сукканда, печән җыйганда, безнең кебек, балык тотканда яңгыр кирәкми. Ә менә бу болыннардагы үләннәр, урманнардагы агачлар, кырлардагы игеннәр үссен өчен, яңгыр бик кирәк, – диде.

Яңгыр астында алар аталы-уллы икәүләп кармакларын чорнадылар.

Шулчак яшен яшьнәде, күк күкрәде. Коеп яңгыр яварга тотынды. Таҗи әтисенең көчле сүзләре астында тәмам җиңелгән иде инде.

Ул:

– Яңгыр, яу, яу, чиләкләп-чиләкләп! – дип кычкыра-кычкыра, агач ышыгына йөгерде.

Бераздан әтисе дә килеп җитте. Ул:

– Табигатьтә барысы да кирәкле, улым, – диде, ачылып килә торган офык читенә күз төшереп. – Эх, яңгыр артыннан балык шәп эләгәчәк соң! – дип куйды.

# ТАБЫШМАКЛАР

Аяксыз, кулсыз капка ача.
(Җил)

Үзе шардай,
Эче кандай,
Тәме балдай.
(Карбыз)

Үлән араларында торам
ышеренеп,
Ашыйсың килсә, ал мине
өзеп.
(Җилак)

Бер кошым бар: тынмый,
Агачка оя кормый;
Өе – җирдә,
Җыры күктә.
(Тургай)

Чуар, йомшак күлмәге,
Тотсаң, уңа бизәге.
Тоттырмый. Китә очып,
Йә кала җирдә посып.
(Күбәләк)



Тызлый да бызлый,
Үпкән җире сызлый.
(Бал корты)



Күрер-күрмәс күзләре,
Челтәр бәйли үзләре.
Челтәрләре түгәрәк,
Эшли алар үрмәләп.
(Үрмәкүч)

Җәен суда шуа,
Кышын ятып тора.
(Көймә)

Сикерә белә, йөгерә белми.
(Туп)





# ЭНДӘШЛӘР

Яңгыр, яу, яңгыр, яу,
Иләкләп, чиләкләп,
Пәрәмәчләп, коймаклап.
Арышларның башагы
Ач булмасын, тук булсын,
Сыерларның сөтләре
Аз булмасын, күп булсын.
Табадан – коймак,
Ул коймакны этә бирдем,
Эт миңа камчы бирде;
Ул камчыны җиргә бәрдем,
Җир миңа үлән бирде;
Ул үләнне казга ашаттым,
Каз миңа күкәй бирде;
Ул күкәйне казанга салдым,
Багыр-богыр кайнарга.
Үзем киттем базарга,
Алтын-көмеш сайларга.
Ал чук, зәңгәр чук,
Монда торма, тизрәк чык.

Яңгыр яу, яу, яу!
Илдә уңыш мул булсын,
Үләннәр дә күп булсын,
Сыерлар да тук булсын,
Безгә эчәргә сөт булсын.









ГОД ОСНОВАНИЯ 1974

Кулинария

НА РЕВОЛЮЦИОННОЙ

- Праздничные торты и пирожные по индивидуальным заказам
- Готовые изделия из мяса, рыбы, птицы
- Салаты и гарниры
- Охлажденные и замороженные полуфабрикаты
- Большой ассортимент свежей выпечки
- Принимаем заказы на пироги
- Доставка горячих обедов в офис
- Обслуживание банкетов и фуршетов

г. Самара, ул. Революционная, 142
Тел.: 260-10-60, 260-15-60









ООО «АКТАШ» предлагает услуги по правовой защите граждан и организаций



**ОКАЗЫВАЕМЫЕ УСЛУГИ:**

- Юридическая помощь физическим лицам
- Юридическое абонентское обслуживание компаний
- Представительство в арбитражных судах и судах общей юрисдикции
- Услуги в области взыскания задолженности



За дополнительной информацией обращаться по телефону

**8 (927) 797-82-80**

либо по адресу: г. Самара, проспект Кирова, д. 206.